# Казан утлары

июль № 7
1965

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК ДҮРТЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

ИЮЛЬ **7**

КАЗАН 1965

## Бу санда:

### РОМАН, ПЬЕСА, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР


Ш. Маннур. **Муса**. Роман. Дәвамы . . . . . . . . . . . . . 3
Р. Гатауллин. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Х. Вахит. **Карлыгач канат кага.** Комедия . . . . . . . . . 49
Ә. Юныс. **Зур ашкыну, озын гомер турында җыр.** Шигырьләр . . 69
Ш. Бикчурин. **Кайту.** Хикәя . . . . . . . . . . . . . . 73


### ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ТАВЫШЫ


Д. Сирай, С. Гәрәева, Е. Уткин, Г. Камалов, Г. Рәхим шигырьләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 82


### ОЧЕРКЛАР


Г. Шәйхиев. **Матур туганда** . . . . . . . . . . . . . . 88

---

Г. Галиев. **Уртак теләгебез** . . . . . . . . . . . . . . 97


### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Г. Халит. **Яңа герой ничек туды** . . . . . . . . . . . . 99


### ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ


Р. Сверигин. **Фатих Хөсни** . . . . . . . . . . . . . . 111


### КИТАП КҮЗӘТҮ


Т. Насыйров, Г. Белялов. **Ленин һәм Татарстан** . . . . 119
Г. Иделле. **«Муса абый»** . . . . . . . . . . . . . . . 126
Ф. Хатипов. **Шигырь төзелеше турында җитди хезмәт** . . . 130
М. Рафиков. **«Изге хәзрәт тарихы»** . . . . . . . . . . 133


### ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР


Галимҗан Ибраһимов. **Нәшриятка хатлар** . . . . . . . 135
Х. Хисмәтуллин. **Гаделлек һәм мәхәббәт поэзиясе** . . . 144
**Дингә каршы әкиятләр.** З. Нури тәрҗемәләре . . . . . . 149

Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . . . . . 157


***Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый.***


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2-этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.

Шәйхи Маннур

# МУСА

## Роман

### III

Иртәгесен Муса күтәренке кәеф белән йокыдан уянды. Такта барак, балчык идән, салам түшәк һәм шул ук немец коллыгы булса да — күңеле көр, фикере ачык иде. Гүяки, ул бик матур бер төш күреп ятканда, кинәт күк капусы ачылып киткән һәм шул нур балкышында аңа бу каһәрле чокырдан сикереп чыгу юлы күренгән! Уянгач, шушы куанычны яңадан татып, үзенең алдагы ниятләрен күңел күзеннән кичереп ята иде ул. Юк, төшендә аңа бертөрле дә могҗиза капу ачылмады, күкләрдән бертөрле дә сихри аваз ишетелмәде. Кичәге авыр һәм озакка сузылган газаплы уйлар эчендә туды бу фикер. Кинәт яшен шикелле ялтырап, үзенең бөтен матурлыгы һәм куркынычлыгы белән, шул куркынычтан курыкмый торган кыюлык соравы белән балкып туды. Туды да, Мусаның бөтен дәртен, барлык рух көчен ияртеп, йөрәген үч һәм кайнар теләк белән җилкендереп, ут эчендә калган баланы кереп алу шикелле «хәтәр уен» белән мавыктырып, үз артыннан алып китте. Бу изге максат аның күңел күген яктыртып, офыкларын киңәйтеп җибәрде. Ул бүген үзен канатлары кинәт бәйдән ычкынган дала кошы кебек сизә иде. Менә, яңадан киң һәм биек күкләрдә йөзәргә, үзеңне үлем читлегенә бикләгән дошманның башына кадалып, рәхимсез үч кайтарырга мөмкин! Юк, үзеңне генә түгел, меңнәр-меңнәрне бикләгән һәм аларның җанын сатып алырга теләгән әшәке дошман белән, әнә шул асыл дусларыңа таянып, аяусыз тартыш башларга!..

Мусаның бөтен җанын-тәнен ярсу ут куыра башлады. Ул, каты сызланудан җанын кая куярга белмәгән кешедәй, сәндерәсеннән кинәт сикереп төште дә балчык идән буйлап ялан тәпи йөрергә тотынды. Куллары йомарланган, әле генә якты булган йөзен караңгы ачу баскан иде. Кинәт аның каршына күзләрен акайткан фюрер үзе килеп басты. Ул инде меңләгән әсир җилкәсе өстенә, «Бу минеке!» дигәндәй итеп, үзенең йөнтәс кулларын салган иде. «О, хөрмәтле фюрер! — ди Муса мыскыллы тавыш белән. — Сез минем халкымны ялчы итәргә уйлагансыз икән... Әмма, ялгышасыз, әфәндем! Сезне полководец диләр, Европаны тезләндергән империя башлыгы диләр... Ә менә мин даһи да түгел, полководец та түгел, сезнең канлы тырнакка эләккән тычкан баласыдай, гади бер солдат, бәләкәй генә Муса Җәлил. Сез мине, ата мәче шикелле, теләсә кайчан шытырдатып чәйни аласыз! Ә шулай да йөрәк өстемә кулымны куеп әйтәм: татар халкы сатыла торган товар түгел! Шәфи дигән адәм азгыны сезне мәкинә сибеп, чыпчык урынына алдаган. Сатылмый ул татар халкы! Сез, әлбәттә, аны мәҗбүр итәргә теләрсез, чөнки сезнең кулда корал. Ләкин мин дә карап тормам! Мин, менә шушы бәләкәй генә Муса, сезгә караганда мең тапкыр зәгыйфьрәк, әмма рухы белән мең тапкыр көчлерәк бер гади шагыйрь, үз тирәмә тугры дуслар җыеп, сезгә каршы яуга чыгам!

[1] Дәвамы. Башы 5—6 саннарда.

һәм башымны кисәргә бирәм: сез нихәтле көчләсәгез дә, татар солдаты үз туган иленә атмас!..»

Блоктагы унлап кеше бары да торып, юынып керде, ә Муса һаман йөренә, һаман пышылдый иде әле. Болар яңарак килгән кешеләр һәм Муса белән рәтләп таныш та түгелләр; әсирлек шартларында үз эчләренә бикләнгән дә булганлыктан, килеп эндәшергә дә кыймыйлар иде.

— Әллә бу абый акылдан шаша микән? — дип куйды берсе, әкрен генә. — Кайчаннан бирле зат-пирут йөрүдән туктамый, үзе нәрсәдер укына...

— Гаҗәп түгел монда берсе дә, энем,— диде икенчесе, зарлы тавыш белән сузып. — Бу каһәр суккан җылан оясында шашу гына түгел, үрле-кырлы сикереп үләрсең...

Блокның ярым ачык калган ишегеннән немец сакчысы күренде. Йөрүеннән һәм уйларыннан әле һаман бушанмаган Мусаның, түрдән әйләнеп килгәндә, кинәт аңа күзе төште дә сискәнеп китте: бу минутта Гитлер үзе килеп кергәндәй тоелды аңа. Чөнки ул аның белән бәхәс кылудан һаман туктамаган иде әле. Сакчы, дага һәм йомры башлы кадаклардан койгандай авыр итекләре белән зык-зык басып, урталыкка килде дә:

— Һумиарофф Мусза! Шеф Френцельгә! — дип кычкырды. — Шнеллер! — дип тә өстәде.

Муса, аптырап аңа карап торганнан соң, «тагын нәрсә кирәк икән боларга?» дип уйлый-уйлый, сәләмәләрен элэктергәләде дә сакчы каршына килде. Немец аңа атларга кушты. Үзе арттан автомат төбәгән килеш, блоктан алып чыгып китте.

Шеф Френцельнең вилласы ябык лагерьдан читтәрәк бер бакча эчендә иде. Мусаны сакчы шунда алып килде. Инде октябрь бетеп баруга карамастан, агачларда сыгылып утырган бурлат кызыл алмаларның, бик тәмледер кебек тоелган эре грушаларның һәм шәмәхә сыман төтен сыланган төсле симез сливаларның әле һаман да җыелмаган булуы Мусаны гаҗәпләндереп һәм кызыктырып куйды. «Рәхәт яшиләр, бирәннәр!..» — дип уйлады ул.

Эчкә кереп торасы булмады, күзлекле майор Френцель үзе чыкты.

— Һумиарофф? — дип сорады немец.

— Әйе, — диде Муса.

— Фрайлагерьдагы танышларыгыз сезнең белән күрешүне сорыйлар. Менә сезгә бер көнлек пропуск.

— Данкешөн, һерр Френцель[1], — диде Муса. — Әмма кем сорый мине? Кемне эзлим?

— Алишофф Абдуля, — диде шеф.

Муса үзен Нәзир Һадиев сорый торгандыр дип уйлаган иде. Күптәнге җан дусты бит. Шулай да куанычтан аның аяклары җиргә дә тимәде. Лагерьның чәнечкеле рәшәткә капкасын ачтырып чыгуга, җиде-сигез адымда гына Алиш басып тора иде.

— Муса! — дип кычкырды ул, бәгырьдән өзелеп чыккан тавыш белән, һәм аңа таба омтылды.

Муса да, кочак җәеп, аңа ташланмакчы булган иде, ләкин кинәт кенә, юлы кырт киселгәндәй, туктап калды. Әйтерсең, шушы урында аяклары алынды аның. Тик күзләре генә мөлдерәп һәм газаплы аңлашылмаучылык белән Алишка текәлде. Чөнки Алишның башында биек түбәле, каракошлы, свастикалы яшькелт-зәңгәр фуражка һәм өстендә коеп куйгандай немец формасы иде. Мусаның күз алдында сагынып омтылган Алиш түгел, ә бәлки Карип Ишбулдин, юк, хәтта бөтенләй таныш булмаган немец фашисты басып тора сыман тоелды. «Ничек

[1] Гүзәл рәхмәт, Френцель әфәнде.

болай!.. Алиш та шуны кигәнме?.. Нәрсә соң бу?..» — дигән мең төрле сорау башыннан узды. Ул хәтта артка чигенде, кире үз лагерена кереп китәргә теләде. Бу хәлдән каты борчылуга төшкән Абдулла моны бик тиз аңлап алды һәм елардай тавыш белән:

— Муса! Курыкма, җаным! — дип кабат кычкырды. — Дөрес, миңа дуңгыз тиресе кидерделәр, ләкин үзем әле дуңгыз сазына аунаганым юк! Мин әле Алиш!..

Муса үзен җиңде һәм, бу секундта үзенә буйсынмыйча кинәт ташып киткән нәфрәт тойгылары өчен үзен гаепле санагандай, борчулы елмаю белән җәһәт-җәһәт алга атлады.

— Алиш! Дустым! — диде ул, кочакларын җәеп. Абдулла аңа табан атлады. Алар икесе дә ирләрчә, дөресрәге, солдатча керсез күңел белән нык итеп, бер-берен кочып алдылар; кыска һәм кайнар үбешеп, йөзләрен бер-беренең җилкәләренә капладылар да, «Алиш!», «Муса», «Эх, дускаем!» — диешә-диешә, елап җибәрделәр. Телгәләнгән йөрәк тавышы белән өзеп-өзеп әйтелгән бу сүзләрдә, бер-беренең җилкәләренә тамган бу кайнар яшьләрдә, ничәмә вакытлардан бирле чигеп килгән газап һәм михнәтләрнең, җәбер һәм изүләрнең, әрнү һәм үкенүләрнең барлык ачысы бергә җыелган иде. Яндырып чыга иде ул яшьләр.

Ниһаять, алар, башларын калкытып, яшь аралаш бер-беренә караштылар да сабыйларча садәлек белән елмаешып куйдылар. Сөйләшәсе сүзләр, уртаклашасы кайгылар шул хәтле күп иде, хәтта, каян башлап җибәрергә белмичә, аптырашып тордылар. Әмма Алишның бәгырен яндырган хәсрәтләре, вөҗданын кимерә торган әрнү һәм үкенечләре көчлерәк, күбрәк җыелган булса кирәк, беренче булып ул башлап җибәрде сүзне.

— Үземнең нинди кыяфәткә кергәнемне күрмәс өчен көзгедән караганым юк иде. Беренче көзге син булдың, Муса, — диде ул. — Чиста күңелле кешенең мине күрү белән адымы киселү, хәтта артка чигенә башлавы минем никадәр кабахәт төстә икәнемне аңлатып бирде. Менә, күр инде, Муса, беткән баш, сатлык җан, фашист ялчысына әйләнгән Абдулла Алиш дигән язучы кисәге шушы була инде... Җирәнгеч хәшәрәт мин хәзер! Төкер син минем йөземә, төкер! Үпкәләмим. Рәхмәт әйтермен! Ничек үпкәлим? Мин аңа бик хаклы булган сасы көзән бит. Мине тудырган газиз анам бар, миңа гомер иптәше булган Өркыям бар, ике күз алмамдай Алмазым белән Айвазым бар — алар минем кабахәтлегемне ничек күтәрерләр, Алиш дигән бәдбәхет исем чыкканда кеше күзенә ничек карарлар? Эх, улларым, йөрәк кисәкләрем, нишләттем мин сезне, нишләттем! — Һәм Алиш тыела алмыйча үксеп, үзләре утырган эскәмиянең терәгенә капланып, яңадан елый башлады. Җан өзгеч авыр, газаплы елау иде бу. Муса, аны юатырга теләп, аркасына кулын сузды. Шул ук кулы белән башыннан сыйпамакчы булып үрелгән иде, ләкин, бик мәһабәт ялтыратып эшләнгән унтер фуражкасына күзләре тукталды да, күңеле бармады — кулын кире тартып алды. Чөнки бу минутта алар арасында ялган хисләр булуы һич кенә дә мөмкин түгел иде.

— Тукта әле, үз-үзеңне шул хәтле камчылама әле, — диде Муса борчылган тавыш белән. — Тынычлана төш. Син бая бик үк куркыныч әйтмәгән идең ич, ачыграк сөйләп бир.

Алиш, башын калкытып, елаудан кызарган күзләре белән Мусага карады. Ул күзләрдә төбе күренмәгән сагыш, кара язмышка буйсынудан туган өметсезлекнең куксел рәшә сыман болганчык пәрдәсе бар иде. Хәсрәт сарысы коелган боек йөзе каны качкандай күгәреп, суырылып калган; күз төпләренә, борын тирәләренә һәм маңгай аркылысына яткан сызыклар, әсир үткән гаҗизлек юллары шикелле, текә тирән һәм бормалы булып сузылганнар. Алишның кайчандыр калын булган чем-кара кыл чәчләре дә шактый юкарып, кырау сибелгән төсле

булып, ә чигәләре, кояш ашагандай, бөтенләй уңып калганнар иде. Муса боларның барысын да бик тиз аңлап алды һәм, Алишны тирән кызгану белән, баягы шикләнүен сиздерүе өчен үкенеп куйды.

— Әйдә, берәр аулаграк почмакка китик әле, — диде Алиш, тирән көрсенеп. — Монда бигрәк аяк өсте.

Алар берсүзсез кузгалдылар да агачларның куерак үскән ягына таба атладылар. Вак кына яфраклары, ут тигәндәй, юка гына булып саргая башлаган бер юкә төбендә яшел буяулы гади агач эскәмия күренде.

— Кара, боларда да юкә үсә икән, — диде Муса, гаҗәпләнеп.

— Бездәге күк, — дип елмайды Алиш. Һәм алар икесе дә шунда утырдылар. Икесенең дә күңелендә шушы юкә күләгәсе ниндидер ягымлы хис уятты, бу урын әллә кайларда калган туган җирнең уч төбедәй генә бер почмагы сыман тоелды. Юкәнең юан кәүсәсен каплаган караңгы кайрыларына, биектәге яфракларның таныш тавыш белән экрен генә җилфердәшүенә сокланып, үренә-үренә карап алдылар. Ниндидер бер минутлык рәхәт килде аларга.

— Без синең белән Казан вокзалында аерылышканга ел ярымлап бардыр инде хәзер, — дип сүз башлады Алиш. — Ул чакта рәтләп сөйләшә дә алмаган идек. Китү кайгысы, фронт кайгысы иде. Кәефләр кәкре, күңелләр бөкре иде, чөнки хәлләр шәптән түгел иде. Ә шулай да бер сүзең хәтердә: «Берлинда күрешербез... Гитлерның муенын боргач!» — дигән идең... Пәйгамбәр булгансың икән: күрештек... Тик Гитлер муенын гына... Әйе, ул безнекен бора!..

Муса эндәшмичә башын түбән иде. Гитлер муены безнең куллардан бик ерак иде шул әле... Алиш яңадан сүзен дәвам итте.

— Әйе, ул чакта әйбәтләп сөйләшә алмадык, ә хәзер менә сөйләшсәк тә, соңга калдык, бугай... «Күз каршымда хәзер үзгәрде эшьялар төсе...»

— Шулай ук соңга калдыкмыни? Шулай ук үзгәрдемени «әшьялар төсе», Алиш? Бик тирәнгә китә түгелме соң бу?..

— Ничек дип әйтергә, Муса туган... Мин сәясәтче түгел, элек тә мин андый мәсьәләләрне тирәнтен аңлый алмый идем, хәзер бөтенләй башым катты. Мин бит партиясез, мондый кошмарларны күрәчәгем башыма да килмәгән юаш бер Абдулла; өй арты бакчадагы шомырт ботагында хәйләсез генә сайрап гомер иткән гади бер кошчык кебек, үземнең кечкенә генә, гади генә хикәя һәм әкиятләрем белән балалар күңелен табарга теләп яшәгән бәләкәй бер язучы гына идем. Ул язучылык көннәрем искә төшкәндә, мин әле дә сиңа рәхмәт укыйм, Муса дус. Чөнки син миңа язган рецензияләрнең берсендә дә мине юкка чыгармадың, ә дусларча һәм белеп, һәйбәт киңәшләр бирдең, уңышларымны да күрә белдең. Ә бит ул елларда тәнкыйть — казакъ камчысы белән бер иде: чыжлап битеңә төшә дә чәчрәтеп күзеңне чыгара! Бер тәнкыйть мәкаләсе белән нинди генә атаклы язучыны да, кабат тормаслык итеп, сугып егалар иде. Явызлык бервакытта да онытылмый, диләр. Юк, яхшылык та һичкайчан онытылмый.

— Тукта әле, син мине юкка һәм бик соңга калып мактыйсың, — диде Муса, көлемсерәп. — Хәзер, үзең беләсең, ул эшләр сират күперенең теге ягында калды инде...

— Әйе, мин читкә тайпылдым бераз, — дип җавап бирде Алиш. — Синең сорауларга һаман килеп җитә алмыйм әле. Гомердә бер очрашкандай, сүз күп булганлыктан ул. Әйе, челпәрәмә килде без иман иткән эшьялар төсе. «Немец пролетариаты!» — дидек. Кайда ул? «Дошманны үз җирендә кыйнарбыз!» — дидек. Нәрсә булып чыкты?.. Жиздрада безне вагоннардан бушаттылар да Брянск тирәсенә хәтле җәяү алып киттеләр. Ул чагындагы фронт хәлләрен беләсеңдер инде: кайда алгы кырый, кайда фланг, кайда тыл — шайтанның да аңламаслык чуалчык

нәрсә иде ул... Поход килешли үк сугыша башладык. Сугышуның да рәте-чираты булмады, дүртенче көндә камалышта калдык һәм, чигенә-чигенә, әйләнеп чыгабыз дип йөри торгач, аждаһаның авызына ук килеп кердек. Ачыгып һәм талчыгып беткән, каңгырып йөрүче төркемнәрне боҗрага кысып алып коралсызландыру немецлар өчен кыен булмады. Ник шулай сугыштык без?.. Алып киттеләр безне сарык көтүе шикелле куып! Уникенче октябрь иде бу, моннан бер ел элек, эз генә артык... Шуннан соң, лагерьдан-лагерьга сөреп йөртә торгач, Чехословакиягә китерделәр, анда заводта шлифовальщик булып эшләргә өйрәндем, тамак та әз генә рәтләнә башлаган иде, ләкин аннан тагын алып киттеләр. Польшадагы Седельце лагерена Идел буе милләтләрен җыялар икән — мине дә шунда быргыдылар. Андагы карантин көннәрен — дизентерия, тиф, күлмәкне күтәреп китәрдәй бет мыжгысы, үрдәк күкәе хәтле булып укмашкан борча күче, — һәммәсе берьюлы кешегә һөҗүм итеп, аны кырмыска оясына салынган кәлтә еланы шикелле үрле-кырлы сикертә-сикертә талауларын — син сорама, мин сөйләмим. Төс-кыяфәтеңә караганда, үзең дә яхшы беләсең кебек күренә... — Алиш, биек түбәле немец фуражкасын күтәреп, кулъяулыгы белән маңгаен сөртеп алды. Аннары як-ягына каранды да, башын кысып торган ул картузны салып, ниндидер җирәнү хисе катнаш бер хәрәкәт белән эскәмиянең аргы башына таба эшереп җибәрде һәм сүзен дәвам итте. — Шул чакта үзенең әтүтәннәре белән Шәфи Алмаз дигән адәм килеп чыкты. Шома гына сөйләп бирде. Әйтерсең, җәмгыяте хәйрия; әйтерсең, эмиграциядәге бер татар бае немец лагерьларенда үлем газабы чигүче мөселман солдатларына шәфкать һәм мәрхәмәт кулын суза, изге эш эшли! Минем шикелле беркатлы һәм гомер буе сәяси сукыр булып яшәгән тинтәкләр алданмыймы соң? Иң элек аның янына Карип Ишбулдин чапты, каян белгән: «Габдрахман абый да Габдрахман абый!» — вак шайтан булып аяк астына сибелде. Нихәтле аңгыра булсам да сизеп торам: йомшак җәеп, каты утыртачак бу адәм, алдаячак! Ләкин үләсе килми. Ай, үләсе килми! Үзем инде өрәк төсле, үләт шәүләсе. Ачлыктан дистрофия башланган. Ә шулай да ничек кенә булса да котыласы килә...

Муса күптән түгел генә булган үз хәлен күз алдына китерде. Ул үзе дә нәкъ шундый ук хисләрне кичергән иде бит. Нәкъ шулай ук, Шпигель чокырындагы бет һәм җәбер корбаны булып үләсе килмәде. Котылу юллары юк иде, сукыр бер очрак тартып чыгарды.

Алиш озак борсаланып, күзнең сүрән кояшлы көне салкынча булса да, маңгай тирләрен сөртеп, каны качкан күмгәк иреннәрен теле белән чылата-чылата, үзе генә белгән авыр кичерешләр эчендә сүзсез торганнан соң:

— Менә, мин хәзер шушы кабыкта... — диде. — Мин Шәфигә ялландым, ә Шәфи мине өч тиен бакыр бәясенә немецка сатты. Мин хәзер фашист ялчысы! Шушы форманы өстемә кидерүләре белән газиз анамны да, багалмадай балаларымны да, туган җиремне дә кабат беркайчан да күрә алмаячагымны аңладым. Әмма соң иде инде һәм чарасыз идем мин. «Бетте көч, сынды кылыч, кайтмады уч...»не еш кына кабатларга туры килә хәзер. Ә немецлар Сталинград урамнарында сугышалар. Иделгә барып чykканнар. Аңлыйсыңмы, Муса, Идел-әнкә күкрәгенә басканнар! Казаннан кул сузымы җирдә бит ул... — Һәм Алиш ачыргалы үксү белән тагын елап җибәрде. — Казан, Казан... — дип кабатлады ул яшь аралаш. — Безне шушы кабыкка тыгып, шунда алып барырлар... Улларым каршына! Юк, мин моны күтәрә алмам! Хәзер үк инде бу каһәр суккан кием, тимер панцырь шикелле, тар миңа, кыса мине, буа, тын алырга ирек бирми! Менә кара әле: нәкъ күкрәк өстендә генә актан тегелгән каракош сурәте; ул свастикалы каракош җир шары өстенә баскан. Юк, җир шары түгел, ул — минем йөрәгем. Канатларын

як-якка җәйгән ерткыч каракош шул минем йөрәгем өстенә утырган да үткен тырнаклары белән чытырдатып кысып алган аны! Ул төн-көн минем йөрәкне шулай тырнап тора; кара кан тама ул йөрәктән, кара кан тама...

— Алиш! — дип кычкырып җибәрде Муса, аны кочагына алып. — Син минем иң якын дустым икәнсең! Юк, юк, син бу форманы Карип кигәнчә кимәгәнсең! Бүре — сарык тиресе ябынса да — барыбер бүре. Ә бәрәнне бүре тиресенә төрсәләр дә, барыбер шул ук сөйкемле һәм гөнаһсыз бәрән ул! Әйт әле, дустым: «...кайтмады үч»не кабатларга туры килә, дигән идең. Ә бармы соң үчең? Бармы соң көчең?

— Үчме? — диде Алиш, күкрәгенә тыны сыймагандай итеп. — Әллә нинди герметик капкачлар белән бикләп бетергән чуен казаннан атылып чыгарга торучы пар шикелле ярсый ул үч! Ә үче барның көче бар, диләр.

— Бик шәп, бик шәп, җаным!

— Андыйлар лагерьларда да тулып ята,— дип дәвам итте ул, ачынып. — Берәве килеп авыз ачса, эченнән хәсрәт сөреме бөркелеп чыга. Икенчесе килеп сулыш алса — үч һәм нәфрәт ялкыны тышка ыргыла... Ләкин ни кырасың ул үч белән? Немецлар Сталинградта бит! Күңел төшенке. Мораль терәк юк...

— Эх, туганкай, авыр көннәр шул,— диде Муса, тирән сулап. Бу минутта аның йөзен дә ачы хәсрәт баскан иде. — Бик кыен көннәр. Минем дә ул хакта уйлый-уйлый башларым авыртып бетә. Кай тарафка гына атласаң да, дөм-караңгы юлсызлык кына шикелле тоела... Ләкин менә эчтә: инә күзе хәтле генә ниндидер бер өмет чаткысы ята. Валлаһи, могҗизага ышанган шикелле! Нишләптер, шул сүнми. Һәм шул нәни очкын әйтә миңа: «Юк, синең халкыңны немец барыбер җиңә алмый, ул бердәм, аның әле потенциаль куәте бар, ул бирешмәс!» — ди. Менә шушы иман нуры мине көрәшкә чакыра, һәм минем күзләремә карап сорый: «Ә шул кан йотучы халкыңның хәлен җиңеләйтү өчен син нишли аласың?..» — ди.

— Туктале, Муса, — диде Алиш, түземсез тавыш белән. — Син нинди көрәш турында сөйлисең? Ни пычагым кырып була монда? Берлин урамына чыгып, немецларга атып йөрерсеңме? Коралың кая һәм ул нәрсә бирә? Ә үзең — сатылган баш бул тагы. Чөнки Шәфи, мине саткан кебек, сине дә, әлбәттә, сатачак! Кем ышансын синең көрәшеңә, кем ышансын?!

— Син, Алиш дус, йөз төрле сорауны берьюлы куясың, — диде Муса да, шул ук кызулыкка бирелә башлап.— Ләкин, боларга җаваптан бигрәк, сине иң ачындырганы — үлемнән коткарган булып кыланучы Шәфинең сине сатып җибәрүе. Әйе, мине дә сатар ул. Мин, Волхов фронтында әләгеп, Двина буендагы Шпигель «оҗмахы»нда яттым. Андагы фаҗигане оныту яки бет һәм үлем базына кире кайту — мөмкин түгел. Гомумән, ул лагерьлар турында, әгәр исән калсак, бөтен дөньяны тетрәтерлек итеп язар идек! Әмма бусы — киләчәктә. Ә хәзергесе болай: Шәфи дигәнең синең белән мине генә сатса бер хәл иде, без чүп кенә! Ә ул бөтен Идел буе халыкларыннан җыелган ничәмә мең әсирне сата ич!

— Седельценең бер үзендә генә дә егерме мең татар җыйдырылган, имеш, — диде Абдулла. — Әле һаман китереп торалар иде...

— Ә башка лагерьларда күпме? Шулай булгач, чамалап кара: күпме татар әсире сатыла икән? Шуның янына башкортны, чувашны, мари белән удмуртны һәм мукшыны куш. Ни чама булыр җәмгысе? Ничәмә-ничә дивизия килеп чыгар?.. Шәфиләр менә шул хәтле әсирне туган илгә атарга өйрәтсә — без нишләрбез? Әгәр шушындый коточкыч җинаять эшләнә калса, совет илендәге барлык кешеләр безнең халыкның битенә төкерәчәк түгелме? Һәм ул кара канлы тап, бөтен тарих буена

бетми торган ләгънәт мөһре булып, без яраткан татар халкының йөзендә калачак түгелме? Менә кайда ул трагедия!

Алишның йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Ябык йөзенә, тунгандагы шикелле, балаʼйоннар кабарып чыкты, хәтта аларның селкенгәне дә сизелә кебек тоелды. Шул ябык чырайлылыкны тагын да көчәйткәндәй, артык тирәнгә баткан күзләре караңгыланып китте. Калын кара кашлары, бер-беренә һөҗүм итешкән төсле, кара-каршы җыерылып килде. Муса сүзләре шундый хәлгә китергән иде аны. «Бәләкәй баш шул мин, бары үзем өчен генә кайгырам!» — дип, үзен эчтән тирги башлады ул. Чынлап та, хәтәр бит... Седельце лагеренда интеккәндә аның башына да томанлы гына рәвештә шушындыйрак фикерләр килгән иде килүен... Әмма фаҗигане бөтен тирәнлеген ачык күреп бетермәгән икән ул. Дөрестән дә, әгәр күп меңләгән әсир шундый җинаятькә мәҗбүр ителсә, Алиш бер үзе сөттән ак, судан пакъ булып калган хәлдә дә, туган иленә таза вөҗдан белән кайта аламы? Юк. Бер очтан аның да битенә төкерәчәкләр.

— Әйе, җан өзгеч фаҗига булачак, — диде ул, ниһаять, сүзгә башлап. — Нишләргә соң? Халыкны ярату — ансат; хезмәтенә хәзер булуыңны игълан итүе дә җиңел, әмма чын мәгънәдә аңа хезмәт күрсәтү — бик кыен эш. Нишләргә соң, без нишли алабыз, Муса? Бигрәк тә мин! Мин бит инде немец присягасын да кабул итеп өлгергән мәхлукъ!

— Ничек? — диде Муса гаҗәпләнеп. — Кайчан булды әле ул?

— Польшада, Едельняда; монда китерү һәм кабыкларын кидерү алдыннан... Мулла укыды, башкалар кабатлап торды... Бер сүзен кабатларга да күңелем бармады, тордым шунда эчтән сүгенеп. «Бөек Дойчляндка тугры булып...» — диделәр. «Анагызны эт оргыры!» — дип кычкыра яздым.

— Болай булгач, антың шәп икән! — дип көлде Муса. — Кайгырма, без әле башкачарак та ант итә белербез...

Аларга беркем дә комачау итмәде. Алиш үзенең таныш ике-өч иптәшенә, башта үзе каршылап, үзе генә сөйләшергә теләвен әйтеп куйган иде. «Мусаның кәефе ничек булыр бит. Берьюлы ябырылмаска кирәк, соңыннан үзем җайлармын очрашуны...» дип аңлатты ул. Шуңа күрә иркенләп сөйләштеләр. Бер фикер дә ашыгып әйтелмәде. Ике иптәш, һәммәсен дә ачык итеп, эчкерсез сөйләште. Муса үзенең төп максатын әйтергә дә бик ашыкмады. Алишны хәзерләп җиткерү кирәк иде. Һәм менә хәзер шул сәгать якынлашты кебек тоелды аңа.

— Алиш, ә син миңа ышанасыңмы? — дип сорады ул, кинәт кенә тавышын түбәнәйтә төшеп.

— Бәлеш тагы! «Өч көн торгач исәнме, кодагый» дигән шикелле син! — диде Абдулла, гаҗәпләнү катыш көлемсерәп. — Нигә алай дип сорыйсың? Әгәр ышанмасам, күз яшьләремне күрсәтеп, эч серләремне түгеп утырыр идеммени?

— Мин дә шулай тоям, һәм ышанам сиңа, Алиш. Ә шулай да кабат сорыйсым килде, күрешмәгәнгә озак вакытлар узды ич...

— Ышанам мин сиңа, Муса. Утыз дүртенче еллардан бирле ышанам һәм дус күрәм, — дип җавап бирде Алиш житди төс белән. — Тик үзенә генә әйткәнем юк иде. Минем күңел ничектер шулай корылган инде: кем яхшы ният белән яхшы сүз әйтә — мин аңа ышанам, аны яхшы кеше дип саныйм һәм дус күрәм. Тупас сүгенүне яратмаган кебек, ялган мактауны да яратмыйм. Кешеләргә үзем дә шулай булырга тырышам. Шушы дуңгыз тиресен бөркәнүдән башка, вөҗданым саф. Иң кыен һәм ачка үләрдәй авыр чакларда да вөҗданыма кер төшермәдем, мин аны сатмадым, син дә шулайсыңдыр дип уйлыйм.

— Шулай, Алиш туганым, бик шулай, — диде Муса, аңа кулын сузып. — Менә сиңа кулым, менә сиңа башым — алар синең ректә.

Ялганчы булып чыксам — өз башымны. Ләкин ант итеп әйтәм: өстемдә керем юк! — Алар бер-беренең кулларын кысыштылар. Аннары Муса тагын да җитдирәк төс белән яңадан дәвам итте.— Әмма мин үзем сафлык белән масаеп, тыныч кына ята алмыйм. Әнә шул үзебезнең меңләгән әсирләрнең җаны өчен, аларны Гитлерга бирмәс өчен көрәшкә чыгам! — Муса бөтенләй пышылдап диярлек сөйли башлады хәзер. — Ишетәсеңме, берсен дә бирмәскә! Аларны фашист агуыннан йолкып алырга кирәк. Бу көрәш бик кыен, бик яшерен һәм бик каты булачак. Немецның кем икәне безгә билгеле: бәлки ул моның өчен башны чабар, әмма шулай да максаттан чигенү юк! Туган илгә якты йөз белән кайту юлы — бары шушы гына, дип уйлыйм. Ләкин шунысы бар бит әле: «Ялгыз батыр — яу түгел», — дигән борынгылар. Мин хәзергә бер үзем. Иң беренче ышанычлы иптәшем итеп серемне сиңа чиштем. Кушыласыңмы миңа, Алиш? Тимер була алырсыңмы?

Мусаның фикерләре кая таба агылганын Алиш инде баядан ук аңлап утыра иде. Аның сүзләрен тыңлаганда ул үзе дә байтак нәрсәләр хакында уйлап алды. Муса әйткәннәрдә дөреслек ярылып ята: бер үзең чиста булу белән генә ни кырасың? Шәфиләр җибәргән кара томан, бәлки, чыннан да инде кешеләрнең күңел күзен томалап өлгергәндер... Иң куркынычы — аларның «татар легионы» булып немец ягыннан сугышка керүләрендә!..

— Кушылам! — диде ул, кайнар пышылдау белән кулын күкрәк өстенә куеп. — Кушылам! Һәм тимер дә була алам! Ни күрсәк тә — бергә!..

Аларның коры сөяккә калган коры куллары шытырдашып бергә кушылдылар. Аннары ике солдат бер-беренә каршы аягүрә басты. Икесе дә ике кулын яңадан бер-беренә бирде, икесе дә бер-беренең күзләренә туп-туры карады. Тирән тынлык урнашты. Бөек һәм изге көрәшкә чыгуның беренче минуты иде бу.

— Туган илебез өчен, туган халкыбызның якты намусы өчен актык сулышыбызгача көрәшербез!

— Татар егете туган иленә атмас!

— Үлсәк үләрбез, әмма дошманга серебезне ачмабыз!

— Шаһит бул, якты кояш, бу безнең изге антыбыз!

Бу сүзләрне алар, алдан өйрәтеп куйган шикелле, бер үк вакытта, бер авыздан, бер йөрәктән әйттеләр. Аннары кайнар кочаклашып үбештеләр. Икесенең дә йөзенә ниндидер сөенеч яктысы йөгерде, кыяфәт һәм хәрәкәтләренә ышанычлы җиңеллек һәм матурлык керде. Ике солдат, ике шагыйрь шулай ант итте.

# Өченче кисәк

## БЕРЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Муса бу зондерлагерьдан тиз генә чыгып китәргә ашыкмады. Башта мондагы хәлләр һәм гомумән бөтен обстановка белән яхшы танышып, үз ниятләреңне шуларга карата кырык кат дигәндәй үлчәп карарга кирәк иде. Ул Гумеров фамилияле әсир кыяфәтендә үз лагеренда гына түгел, фрайлагерьга да чыккалап, үзенә моңарчы бөтенләй таныш булмаган кешеләр белән аралашып йөрде, үзе дә сөйләде, аларны да сөйләштерде, каян килгән,ниләр күргәннәрен белде, кәефләрен өйрәнде һәм легион корып йөрүчеләрнең кемнәр булуын сораштырды. Ниһаять, аның күз алдында шактый ук тулы һәм катлаулы бер картина туды.

Безгә каршы башланган сугыш инде ел ярымга якын дәвам итә, үлем тегермәне һаман тарта тора, шулай да немец дивизияләре бик ерак киттеләр хәзер. Аларның бер канаты Сталинградка килеп чыкса, икенче канаты Дон, Калмык, Кубань далаларына җәелеп, Төньяк Кавказга үрләде. Әллә кайдагы Төньяк диңгездән башланып Кавказгача сузылган бу чамасыз озын фронт сызыгын нәрсә беләндер каплапарга кирәк иде. Шуның өстенә ничәмә-ничә Көнбатыш илләрендә дә, Россиянең басып алынган өлкәләрендә дә күпме немец гаскәрләре тотарга кирәк. Шулай итмәсәң, ул шомлы тыл, иске капчык шикелле, хәзер бөселеп төшәчәк. Ә Көнчыгыштагы немец дивизияләре һаман кырыла, һаман сирәкләнә бара. Яңа гаскәр каян алырга?... Немец командованиесе бу мәсьәлә белән ваш ватарга мәҗбүр була. Кайберәүләр моның практик чарасына да керешәләр. Оберлендер дигән өлкән лейтенант Көнбатыш Украина милләтчеләреннән «Нахтигаль» («Сандугач») батальоны укмаштырып, Львовтагы поляк белән яһүтләрне акылга утыртуда һәм, гомумән, шәһәр халкына тәртип өйрәтүдә зур гына хезмәтләр күрсәтә. Шул ук Оберлендер, соңга табарак «Бергман» («Тау кешесе») дигән яңа батальон туплап, Төньяк Кавказны коммунистлардан әрчи һәм яңа тәртипләр урнаштыра башлый.

Мостафа Чокай, Каюм Вәлиханов һәм Әхмәт Тимер дигән эмигрантлар да Розенбергта эшләүче Бройтигам әфәнде ярдәме белән «Төркестан легионы» оештыралар. Бу легион да эшкә ярап куя: Көньяк Россиядә һәм Калмык далаларында каратель булып йөри. Генерал Власов армиясен барлыкка китерүдә Гелен әфәнде искиткеч зур сәләт һәм акыллылык белән эш итә. Власов хәтта чамадан ашып китә: «Бирегез миңа бер миллионлы армия, — ди. — Барам да Ленинградны алам, баш министры үзем булган вакытлы хөкүмәт төзим һәм буйсынган Россияне аяк астыгызга салам! Шуның белән сугыш та бетә!» — ди...

Мондый уңышлы тәҗрибәләрдән соң фюрерның «Комиссар арляс» фәрманын алыштыру кирәклеге нык сизелә башлый. Ул фәрман буенча, әсиргә төшкән комиссарлар, политруклар, яһүтләр һәм азиатлар, — димәк, Россиянең ярты халкы, — кырып бетерелергә тиеш. Ә ничек аларны кырып бетерәсең? Яңадан уннарча Майданек мичләре корсаң да мөмкин түгел. Шуның өстенә, аларның эшкә ярап торуы күренә. Шулай да Гитлер ул фәрманны бөтенләй юкка чыгарырга теләми. Ничек юлбашчы үз фәрманын үзе юкка чыгарсын! Ярар, хәрби әсирләрне шулай файдалана аласыз икән, бик яхшы, ди ул. Әмма рус комиссарлары һәм иудалар турындагы өлеше үз көчендә кала! Аларга — капут!..

Шулай итеп, бу фәрман тормыш белән җайлаштырылгач, һәртөрле милли төркемнәр оештыру өчен күп кенә акчалар билгеләнә. Озак та үтмәстән, грузин, азербайҗан, әрмән, тау халыклары, «Идел-Урал» һәм башка легионнарны төзүче маклерлар, кисмәге белән бал тапкан чебеннәр шикелле, тыз-быз чабып йөри башлыйлар.

Берлиндагы кечкенә төркем татар эмигрантлары арасында төрле катлау һәм һәртөрле кәсеп кешеләре була. Аларның беришесе беренче сугышта ук әсир төшкән солдат, һәм шул чакта немкага өйләнгән дә төпләнеп калган. Андыйларны «шкафчы Мотыйк», «тегүче Мәхип», «водопроводчы Хәким», «шофер Хафиз» дип йөртәләр; икенчеләре исә революциядән һәм совет властыннан качып килгәннәр. Бу кешеләрне «маклер Габдрахман», «Усман мулла», «фабрикант Яушев», «шпион Идриси» диебрәк атыйлар икән. Ә инде Әхмәт Тимер дигән берәве бу катлауларның берсенә дә керми, ул башка сындагырак адәм. Әхмәт Тимер — Бөгелмә шәһәренең Рәшит мулла малае. Утызынчы елларда урта мәктәп бетереп, егет булгач, ышанычлы контрабандистлар өйрәткән юл белән Кавказ таулары аша Төркиягә качып чыккан ул. Әтисе биргән адреслар буенча Стамбулда үз кешеләрен тапкан да гимназиягә

кергән, аннары ниндидер акчага Берлин университетын тәмамлап, магистр исеме алган. Сугыш башлангач, Әхмәт Тимер Һеббельс әфәнде пропагандасында эшли башлый. Ләкин яшь һәм энергияле магистр өчен радио аша «үрдәк» очыру гына бик бәләкәй эш булып күренә. Аның башында бик зур планнар, еракка китә торган хыяллар йөри. Көннәрнең берендә казакъ эмигранты Мостафа Чокай, үзбәк качагы Каюм Вәлихановлар белән берләшеп, «Олуг Төркестан» дәүләте төзү һәм аның гаскәрен дә әсир солдатлардан хәзер үк оештыра башлау мәсьәләсен күтәрә ул. Шәүкәтле Алман гаскәрләре, һичшиксез, Урта Азия һәм казакъ сахраларына да барып җитеп, туган җирләрне урыстан һәм большевиклардан азат итәчәкләр. Менә шул чакта ил язмышын үз кулларына эләктерергә тиеш алар!.. Схема рәвешендә генә булса да, «Олуг Төркестан» мәмләкәтенең харитасын да төзеп, «Көнчыгыш министры» Розенберг әфәнде каршына килеләр.

— Һем-м... — дип суза ул, мәгънәле генә итеп. — «Гросс Тюркештан!» — шәп яңгырый. Бик зурдан селтәнгәнсез... Андый мәмләкәт киләчәктә үзе бер куркыныч нәрсә булып чыкмас микән соң?..

Әхмәт Тимер бик кайнар дәрт белән киресен исбат итәргә керешә. Шулай да Розенберг «Олуг Төркестан»ны аларга тиз генә тоттырып чыгармый. Хәзергә булачак олуг мәмләкәт легионына гаскәр тупларга, аны ныгытырга куша.

Шулай итеп, «Төркестан легионы»ның беренче батальоны кырык икенче елның февраль айларында ук төзелеп җитә. Аның эченә уйгурдан алып татарларга кадәр бөтен төрки халык әсирләреннән кешеләр тутырыла. Шул чуар төркемне күпмедер өйрәтәләр дә, немец киеме киертеп, немец коралы тоттырып, Көньяк фронтына озаталар. Моңарчы ач яңаклы, сәләмә киемле «студент» булып йөргән Әхмәт Тимер кинәт бөтәеп китә. Чокай белән Вәлихан әфәнделәр дә, яңадан тез чәнчеп утырып, сөяк кимерергә тотыналар һәм, туйганнан соң баскычлы-баскычлы итеп кикерә-кикерә, «Әлхәмделилла!» — дип куялар. Әйдә, сугышсын Олуг Төркестан уллары, изге җиһатта шәһит булсыннар!..

Бу яңалыкны ишеткән маклер Габдрахманның үкенүенә чик-чама булмый. Ничек соң ул, мәче шикелле бервакытта да сырты белән төшми торган Габдрахман Шәфи Алмаз, шушындый табышлы, күп акчалы эшне һәм киләчәктә, шайтан белсен, нинди бәхетле мөмкинлекләре булган эшне көпә-көндез кулыннан ычкындырды? Ни өчен ул сукыр торна шикелле муенын сузып, авыз ачып калды? Ничә әйтсәң дә, коры сәүдәгәрлек! Хәзерге заманда сәясәттән тыш яшәү ярыймы соң? Эх, хатыны белеп сүгә шул аны «кәләвәче» дип. Каеш түбәтәй — эче бәләкәй!..

Габдрахман Шәфиев Берлинның астын-өскә китереп чаба башлый, ничек кенә булса да шул майлы калҗаның үз авызына керүен тели ул. Һәм аның күктән теләгәнен ходай җирдән бирә. Төркестан легионыннан тама торган майны үз якташларының берсенә дә ялатырга теләмәгән Әхмәт Тимергә башка татар эмигрантларының да ачулары бик кабарган була. Бер көнне Шәфи янына Усман мулла килеп чыга. Сүз, әлбәттә, үзеннән-үзе шул тирәдә әйләнә. Мулла хәзрәт Әхмәт Тимернең «Олуг Төркестан» идеалларын тетеп сала. Тетмәслек тә түгел, чөнки Әхмәт Тимер аны бик каты җәберләгән. Радиода пропагандага кирәк булган Усман легион төзегәндә кирәк булмаган. Әхмәт аны читкә тибәреп, күпме табыштан колак кактырган. Ә үзе маңка малай!..

Кайчандыр Семипалат казакълары арасында зур сәүдә тоткан татар баеның укымышлы улы булган бу тәкәббер кеше, хәзер инде Берлин мәчете тирәсендә мәет юып, җеназа укып йөри торгач, чәчләре коелып, сәләмәләнеп һәм бөтенләй кыршылып беткән иде. Юк, аңа Әхмәт Тимернең «Олуг Төркестаны» һич ошамый. Шул хакта киңәшер өчен дә Шәфи якташына килеп чыккан ул.

— Барып чыга торган нәрсә түгел! — ди Усман мулла, юк чәчен артка сыпырып. Бу гадәте аның яшь чагыннан калган. Чөнки ул чакларда аның озын итеп җиткергән коңгырт кара чәче булган; ул матур чәчләр шушы нәләт төшкән чит җирләрдә коелып беткәннәр. — Булмый! — дип кычкыра ул сул кулын йомарлап. — Ике тәкә башы бер казанга сыймый, ә монда унлап тәкә булачак. Кем баш та кем муен? Русия мөселманнары моңа үзләре дә разый булмаячаклар. Ә инде безнең Идел буе татарлары — бигрәк тә. Чөнки безнең үз идеалыбыз бар: «Идел-Урал штатлары». Без ул идеал өчен инде көрәшеп тә карадык, ул тарихка кергән эш. Менә хәзер шул бөек идеалыбызны гамәлгә ашыру өчен яңа имкяниятләр туып тора. Олуг фюрер кумандасы белән җиңеп баручы Алман гаскәрләре Идел ярларына чыгып бастылар. Озакламый Казан өстендә милли азатлык тулары[1] җилфердәр. Менә шул көнгә без үзебез хәзер булырга тиешбез!..

— Менә, менә дөрес! — дип күтәреп ала моны Шәфи һәм кычкырып сөйли башлый: — Нәкъ мин уйлаганны уйлап йөрисең икән! Әйе, әйе, безнең үз Идел-Урал мәмләкәтебез булырга тиеш. Татар халкы үзе баш булуны теләр һәм аның кабилияте дә бар. Нигә аңа Төркестан ханнарына барып йөрү кирәк? Идел-Урал буенда башкорт, ар, чуваш, чирмеш халыклары беткәнмени, без алар белән идарә кыла алмыйбызмыни?

— Әлбәттә, шулай! Бу безнең мәдәни вазифабыз, — дип җөпли Усман мулла, күзләрен челт-челт йомып. — Теге бит ул — пантюркизм; анда төрекләр тыгылып, барлык тезгеннәрне бик тиз үз кулларына эләктерүләре ихтимал. Ә шәүкәтле Алман империясе моңа, әлбәттә, разый булмаячак, эш зурга һәм чуалчыкка китәчәк...

— Булды! — дип куя Шәфи Алмаз, фикерләрен яшен тизлегендә бер йомрыкка туплап. — Иртәгә үк шәрык министры Розенберг әфәндегә барып, «Олуг Төркестан»ны җимерәбез. Җимерү белән «Идел-Урал буе халыкларын азат итү кәмитите» төзибез. Шул кәмитит исеменнән, немес химаясендә «Идел-Урал» мәмләкәте төзү проектын Розенберг әфәндегә тапшырабыз. Ә мин: «Идел-Урал» легионы оештыру шикелле кыен һәм мәшәкатьле эшне бүгеннән үк үз өстемә алам!

— Син инде сәләтле кеше-е, — ди Усман мулла үкенечлерәк тавыш белән. — Әнә бит, күз алдында нинди планнар корып өлгерттең, баш эшли синең... Тик менә мин генә нишләрмен? Әхмәт кебек син дә мине төп башына утыртып калдырырсың микән, Шәфи дус?..

— Ни сөйлисез, Усман әфәнде? — дип нәразыйлык белгертә Шәфи. — Сез бит хөрмәтле кешебез. Сезгә хәзер үк эш тапшырам: легионның мөфтие булырсыз! Ә Казанга кайткач, аллаһе боерса, күз күрер. Бәлки, бәлки... дин-мәгариф вә тәрбия эшләре вәзире итеп куярбыз. Разыймы сез?..

Менә шушыларның барысы белән дә танышып алган Мусага хәзер инде мәсьәлә шактый ачык һәм барыр юл билгеле булып күренде. Үткән заманның бу өрәкләре, болай караганда бик көлке тоелсалар да, татар әсире белән сәүдә итүләре ягыннан куркыныч бәндәләр һәм аларны аяусыз көрәштә җимереп ташларга кирәк иде...

Колониячеләрнең «Бүлгәләп хакимлек ит!» дигән кагыйдәсе буенча эш йөртүче немецлар «Олуг Төркестан»нан өркеп калдылар. Андый зур мәмләкәт төзесәң, соңыннан нәрсә килеп чыгар? Үзеңә каршы сырт йоннарын штык итеп кабартмасмы? Әнә бит англичаннар нинди хәйләкәр: йөз миллионлы гарәп дөньясын дистәләрчә вак дәүләткә бүлгәннәр дә рәхәтләнеп хөкем йөртәләр. Имепме-имәләр үзләрен! Әнә шундый оста булырга кирәк!..

[1] Ту — әләм, байрак.

Шуңа күрә Шәфи Алмазның килүе бик урынлы булды һәм аның тәҗрибәле сәясәтчеләрчә вакыйгалар барышына таянып сөйләшүе дә Розенберг әфәндегә ошап калды. Барысы да хәл ителде, килешелде.

Шәфине шулай күзле бүкән итеп куйгач, немецлар татар-башкорт һәм Идел буе әсирләрен Польшадагы Седельце, Радом, Демблин, Крушино һәм башка лагерьларга җыйдылар. Карантин һәм башлангыч хәзерлек уздырганнан соң, сугышка яраклы солдатлар Едлино лагерена күчерелеп, хәрби өйрәтүләр, ант иттерүләр башланды. Солдатлар баштан-аяк немец формасында, аларның йөрәк өсләрендә каракош һәм свастика иде. Бу фашист билгеләреннән Идел буе егетләренең тыннары кысылды. Шуның өстенә милли эмблема да уйлап чыгардылар: борынгы Урал калканы өстенә аркылы чәкәштерелгән ике кылыч һәм аларның уртасына ук сурәте төшерелде, калканның югары башына латин хәрефләре белән «Идел-Урал» дип язылды. Бу билге солдат мундирының җиңенә тегелгән иде. Ай белән йолдыз төшерелгән яшел әләм дә булды. Шулай итеп, немец фашистлары бөтәйткән «милли гаскәр» барлыкка килде.

Картрак һәм саусызрак солдатларны аерым батальоннарга туплап, Голландия, Бельгия һәм Франциянең төньяк ярларына, «Атлантик вал» казырга җибәрделәр. Күрәсең, булачак «милли штатлар»ның чикләре шул тирәләрдән уза иде булса кирәк!..

Шәфи үз-үзен танымый башлады хәзер. Чөнки гомер буе «суктым-алдым», «кияүләттем» белән яшәгән кеше кинәт кенә «милли түрә» булып, «зур эшләр башкаручы» булып китте. Хәтта Кальвария, Сувалки, Демблин, Крушино шикелле ерак лагерьларга барып, татар әсирләрен үз ягына аудару нияте белән нотыклар сөйләргә кереште. Һәм ул үтә чыккан оратор икән ләбаса! Бигрәк тә Николай заманасын оста итеп сөйләгәндә бик зур уңышка ирешә ул. «Мамык мендәрдәй кабарып пешкән калач, кыссаң учыңа сыеп бетәсе, шуның гөрәнкәсе биш тиен бит, бары биш тиен!.. Шикәрнең кадагы унбиш тиен, аны ашаучы да юк, — кәнфит кенә суыралар! Сап-сары майлары укмашып-укмашып торган елкы итенең боты өч тәңкә бит! Аны үлчәп торган кеше дә юк, әллә тагы биш пот тартадыр ачуым килмәгәе... «Идел-Урал» мәмләкәтендә дә тормышлар шундый булачак!..» дигән ялкынлы сүзләрен ишеткәч, татар һәм башкорт әсирләре рәхәтләнеп көлеп җибәрәләр. Ә Габдрахман абзагыз юри тәмле итеп сөйли боларны. Ачның күзе икмәктә, диләр. Әйдә, ныграк кызыксыннар, селәгәйләре аксын! Тизрәк авышырлар аның ягына!

Менә иртәгә тагын да мөһимрәк эшләр белән Седельце лагерена китәсе ул. Чөнки милли комитетны яңа яшь кадрлар белән ныгытырга кирәк. Искеләрне якын да җибәрергә ярамый. Ул мәкерле шайтаннар хәзер үзеңне бәреп төшерүләре мөмкин!.

Муса һаман ябык лагерьда иде әле. Моннан тиз генә чыгып китү бер дә уен эш түгел. Ун тапкыр, йөз тапкыр уйларга кирәк. Моннан чыгу — сират кичү, диләр. Әмма шулай микән? Сират күпере кичә алган кешеләр туп-туры оҗмахка керәчәк, имеш. Ә бу бикле капканы ачып чыгучы кеше туп-туры тәмугка, шайтан кочагына ташланырга тиеш. Мусадан башкалар да бик ашыкмыйлар, уйланалар. Ничек уйланмасыннар: алда нәрсә көтә? Дөрес, алар әле бүгенгә хәрби әсирләр, ирексездән куып китерелгән бәндәләр. Немец эт урынына типкәләп йөртсә дә, алар әле һәрхәлдә кеше. Үз илләренең гражданы, вөҗдан чисталыгы саклыйлар һәм Ватан каршында ниндидер хокуклары да бар шикелле. Ә иртәгә ничек? Моннан чыгып киткәч, хәлләр бөтенләй үзгәрәчәк бит. Немец аларга ирек вәгъдә итә, ләкин икмәк вәгъдә итми. Чыбыклы лагерьдан чыккач, ачка үләсең килмәсә, син аңа ялланырга, аның хезмәтен башкарырга тиешсең. Ә хезмәте аның пычрак. Немец формасын ки, кулыңа ул биргән коралны тот һәм ул җибәргән тарафка

барып сугыш. Кемгә каршы соң бу? Анысы да сер түгел — илгә каршы. Ягъни үзеңнекеләргә ат син немец мылтыгыннан... Әйе, немец ирегеп алгач, моңарчы сиңа гәҗиз булган бөтен нәрсәләрдән ваз кичәргә, аларны онытырга, хәтта дошман күрергә тиеш син...

Дөнья бинасының һәм яшәешнең акыл җитмәс бөек һәм яшерен серләрен дин догмаларыннан түгел, «кара китап»лардан эзләгән Фауст, шул максатына ирешү теләге белән, шайтанга җанын саткан имеш... Муса алдында да хәзер шундыйрак кыен проблема тора. Аңа да Иблис кул куешырга тәкъдим итә, димли, кызыктыра, хәтта мәҗбүр итүе дә ихтимал аның. Нишләргә соң? Мусаның да менә монда килеп, мондагы яңа хәлләр белән танышкач күңелендә туган изге һәм бөек максаты бар. Ничек булыр икән соң? Фәкать шул изге максаты хакына Иблис белән кул куешса, аның төсенә керсә, теләгенә ирешә алырмы?.. Күп эзләнеп гаҗиз булган Фауст яшәүнең мәгънәсен, ниһаять, кешеләр ирке өчен көрәштә һәм төзүчел көрәштә тапкан. Муса, могҗизалар күрсәтә белә торган алхимик булмаса да, кайсы ягы беләндер шул ук Фаустка охшый кебек хәзер. Аның алдында да үз халкының меңләгән улларын кара һәлакәттән коткару, аларның вөҗдан һәм намусларын саф килеш саклап калу шикелле бик кыен эш тора. Ә моның өчен тик бер генә, бары бер генә юл бар. Ул юл — дошман белән килешеп, кул куешып, аның кыяфәтенә керү. Моннан да кыен һәм хурлыклы тагын нәрсә булуы мөмкин?.. «Сатлык җан» дигән сүзне ишетү — иң якын дустыңның сине атып егуы белән бер булачак. Уйланмый мөмкин түгел, ашыгыр урын юк. Чөнки тагын да кыенрак ягы бар әле: булдыра алырмы ул, иәртә алырмы кешеләрне? Ирешә алырмы шул изге максатына?.. Әллә йөзенә мәңгелек кара тап ягып, үзе генә пычранып калырмы? Җитмәсә аның бит мондый тәҗрибәсе дә юк. Идән асты эшен белгән карт коммунист булса, ичмаса, тагын бер хәл иде... Ә шулай да тотынырга кирәк! Һәрхәлдә, солдатның ятып калудан атып калуы яхшы...

Тик менә сөйләшкән кешеләрнең тел төбеннән бер дә өметле авазлар ишетелмәде әле аңа. Әллә бик нык сагаялар инде, әллә күңелләрендәге нәфрәт сүнеп киткән яки бөтенләй булмаган инде, һәрберендә диярлек гомуми сүлпәнлек, аермасызлык, беркая да омтылмаучанлык сизелә. Ахры, Шпигель лагере шикелле үлем чокырларында күп айлар буена интегеп, бу дөньядан тәмам өмет өзәргә мәҗбүр булган кешеләр, һич көтмәгәндә үлемнән котылып монда килгәч һәм әз генә җүнле шартларга куелгач, яшәү куанычы белән исереп киткәннәр. Гаҗәпмени, Муса үзе дә шундый хәлдә иде бит, тәмам үләргә җыенган иде. Әгәр аны меңләгән кешеләрнең иртәгә киләсе язмышы кинәт уятып җибәрмәгән булса, ихтимал, ул да әле бик рәхәтләнеп шул сәрхушлыкта йөргән булыр иде. Күрәсең, алар өчен яңа бер уяткыч кирәктер. Бәлки, тора-бара күзләре ачылыр. Әмма хәзергә тик бернichә егеттә генә ниндидер очкын барлыгын сизә алды Муса. Аларның берсе укытучы Мулланур, икенчесе инженер Әхәт һәм тагын бер-ике егет. Әхмәт Симаев белән дә яңадан сөйләшеп карады, теге көнге сүзләре өчен әрләп алды ул аны. Ә егет бөтенләй шаккатырды Мусаны.

— Туктале, Муса абый,— диде ул, гаҗәпләнгән тавыш белән.— Мин бит синдә сатылучыларга нәфрәт тусын өчен шулай сөйләштем һәм, үземчә, сине дә сатылудан саклап калырга тырыштым!

— Һи, чучка малае! — диде исе киткән Муса, дусларча ачуланып. — Минем өчен куркасың, ә? Ә мин шул көннән бирле синең өчен куркып йөрим. Кичә дә эзләгән идем үзеңне.

— Курыкма, кәбәм! — диде Әхмәт, мишәрлеген исенә төшереп. — Безнең күңел — гранит ташы! Мин фрицка сатылмыем, ә фрицның үзен сатарга могу!..

Егетнең күңел сафлыгы чишмә суыдай үтә күренеп тора иде бүген. Әмма шулай да Муса аңа кинәт кенә ачыласы итмәде. Әллә ничә төрле сораулар биреп имтихан кылдырганнан соң да:

— Ә сиңа, чынлап та, ышанырга буламы, Әхмәт? — дип кабат сорады.

Симай ачулы күзләрен күрсәтмәс өчен җиргә карады. Ике бит эчен һава белән тутырып, «пуф-ф-ф» дип куйды, озак сузып. Аның җәберсенгәне күренеп тора иде.

— Ә сиңа? — дип сорады ул, кабарынып.

— Кабарынма! — диде Муса, тавышын күтәрә төшеп. — Уйнап сөйләшмим, житди эш бар...

— Җитди эш! — Әхмәтне кинәт кызыктыру дәрте чолгап алды. — Алайса, бетте, Муса абый! Юкса үпкәләргә исәп бар иде. Җитди эш булгач, менә шушы карт имәнгә ышанган кебек ышан!

— Һе, — дип көлде Муса. — Карт имәнгә ышанам анысы, әмма аның белән һич ни эшләп булмый. Миңа кеше кирәк, ышанып эш итәрдәй кеше!

— Менә сиңа ике кул! — диде Әхмәт. — Үзеңә ышансаң, миңа да ышан!..

Һәм Муса аңа үз максатын сөйләп бирде. Авыр һәм яшерен көрәшкә чыгарга кирәклеген әйтте. Әхмәт Симаев куанычыннан хәтта сикереп торды, Мусаны кочаклап алды һәм:

— Шыбыртабыз Гитлерны! — дип кычкырып җибәрде.

— Үкермә, юлбарыс, — диде Муса. — Аучы колагы үткен була...

Алар лагерьның аргы почмагында иде. Якын тирәләрендә кешефәлән күренмәде. Муса аңа гомумән басынкырак булырга, тойгыларын бик гөрләтеп чәчмәскә киңәш итте. Аннары Алиш белән булган антлары хакында сөйләп бирде. Әхмәтнең тагын хәтере калган төсле булды.

— Сәер икән, — дип куйды ул, — беспартийный Алиш белән әллә кайчан сөйләшеп, эшне бетереп тә куйганнар, ә коммунист Симайга, күпме допрослар алып, чүт ли ни корьән үптергәннән соң гына әйтәсең... Юк, гаделлек түгел бу, кәбәм!

— Шаулама, Әхмәт, — диде Муса. — Андый «үтә кызыл» булырга ярамый. Монда вөжданы чиста һәм үз иленә тугры булган һәрбер кеше — коммунист! Онытма шуны, яме. Кешеләрне шул үлчәү белән танырга өйрән.

Шулай да кызык егет иде ул Әхмәт. Аның үз кирелеге һәм җиңел акыллылыгы аңа үз фикере булып күренә иде. Мусага аны байтак кына каезларга, шомартырга туры килде. Әмма оешмага керүгә бик дәртләнеп риза булды. Ул аннан бик зур эшләр көтә һәм үз башында да аяктан еккыч шәп планнар йөри иде...

Бер иртәне Алиш, Булатов һәм Шабаев Муса янына үзләре килеп чыктылар. Муса аларның өчесен дә кочаклап алды һәм бик гаҗәпләнде. Алиш сөйләп бирде. Моны алар үзләренчә бик кызык кына оештырганнар. Бер шешә кызыл аракы күтәреп, Алиш житәкчелегендә лагерь башлыгы Френцель әфәнде каршына килгәннәр дә әз генә кызмача кыяфәт белән бик ялынып үтенә башлаганнар:

— Хөрмәтле майн һерр! — дигән Алиш, кулындагы шешәне болгабрак. — Бүген минем туган көнем. Ә минем иң якын дустым Гумеров — ябык лагерьда. Рөхсәт итегез, зинһар өчен, аның янына кереп, берне генә чәкешеп эчәргә! Икебез бер каланыкы, бик дуслар идек, туган көннәребез гел бергә уза иде... Әгәр бөек Дойчландта да мин дусларым белән шул бәхеткә ирешә алсам, сезгә мең рәхмәтләр укыр идем!

Френцель әфәнде карап-карап торган да, немец формасын кигән шушындый кешеләр үтенеп сорагач, туган көн икәнен күрсәтә торган

шешә дә һәм әз генә кәгеп алулары да күренеп торгач, каршы килә алмаган, күрәсең. Часовоеннан капканы ачтырып, Муса торган баракка хәтле озаттырып ук куйдырган.

— Сез, егетләр, Гитлер хәзрәтләренең үзен дә бармакка чорнарсыз әле! — дип көлде Муса. — Яки дары тутырган мичкә өстенә утыртып, күккә күтәртерсез.

Муса торган блоктагы кешеләр төрле җиргә эшкә таралганнар иде, иркенләп көлешеп алдылар. Шешә башы да ачылды. Аннары әңгәмәгә керештеләр.

— Менә, — диде Алиш, — үзләрен алып килдем. Мин дә кылларын тартып караган идем каравын, әмма алай гына риза булыр сыман түгелләр, ишан хәзрәтнең үзен күреп кул бирәсебез килә, диләр. Соң, мин әйтәм, мин кем? Мин соң ишан малаеның малае түгелмени?.. Малаеның малае гына шул, диләр. Ягъни куян шулпасының шулпасы!

Фоат Булатов аеруча рәхәтләнеп, ничектер буш сыман тоелган авыз эчен гөмбелдәтеп көлде.

— Чынлап та, сәер бит, — диде ул, — синең исемнән эгитләп ята безне. Кая, мин әйтәм, кем соң ул, үзен күрергә мөмкин түгелме ул тау тишеге изгесенең?..

Муса аның әле үсмер егет чактан ук таныш булган йөзенә ярым елмайган хәлдә карап алды. Аның кайчандыр козгын канатыдай елкылдап торган куе кара шома чәчләренә хәзер ниндидер соры тузан сибелгән шикелле, шешенкерәк кабак астыннан карый торган элекке үткен кара күзләре дә ничектер әз генә уңган төсле, итләч зур борыны, коры кимерчәккә калып, шактый тырпаеп тора, элек тә очлы яңакләре хәзер бөтенләй кипкән чөй кебек убылып калган иде. Йөзендәге кызарып торган җөй эзе Фоатны бөтенләй ямьсезләп җибәргән. Күрәсең, болар һәммәсе дә аның әсирлек хикәяләредер инде. Муса бу хакта сүз кузгатырга теләмәде, кешенең ярасына кагылу нигә кирәк?.. Үзләренчә шаярып сөйләшкән булу яхшырак иң.

— Беләсезме, егетләр, — диде Муса, — бу бит безнең бокс буенча СССР чемпионы!

Алиш белән Шабаев Фоатның бөтерчек хәтле генә гәүдәсенә күз төшерделәр дә шаркылдап көлеп җибәрделәр.

— Булыр, булыр!

— Юк ла инде,— диде Фоат, хәтере калып. — Син бигрәк, Муса абый...

— Тукта, тукта, син миңа үзең язган идең иң!

— Бутыйсың, Муса абый, — ул бит йөгереш буенча, һәм СССРныкы ук булмаса да КИКС [1] чемпионы... А што, биш мең метрга йөгереп, вуз күләмендәге беренчелекне алып карагыз әле сез, шуткемени ул! Ә хоккейда безнең команда Казан беренчелеген алды! — Фоатта спортсмен дәрте уянып китте. Ул үзенең шул чакларын сагынып, спорт уңышларын сөйләргә, комарланып мактанырга тотынды.

Моңарчы ничектер тын гына елмаеп утырган калын коңгырт чәчле, биек маңгайлы, озынча йөзле һәм шулай ук очлайган иякле Гариф Шабаев күзләренә әз генә шаян очкын йөгертте дә:

— Аучы, балыкчы, шахматчы һәм һәртөрле спортчы нигә болай борчак сибәргә ярата икән? — дип куйды. — Ну мактаналар да соң!..

Тагын көлешеп алдылар. Әмма Фоат бирешергә теләмәде. Үзенең валлаһи-биллаһи дөресен генә сөйләгәнен әйтте дә Гарифның үзенә тотынды.

— Ай, Муса туганкай, мин бит онытып та җибәргәнмен,— диде ул, борчылган булып. — Таныш бул: бу безнең Гариф Шабаев дигән егет. Бик серьезный, бер дә шапылдык түгел. Үзбәкстанда үскән. Пылауны

[1] Казан коммуналь төзү институты.

бик ярата. Үзе зур финансист. Шәфи Алмаз әфәнденең малия вәзире[1] булачак кеше...

Шабаев, йөзенә караганда, Муса яшьләрендәге кеше иде. Шаяртуны, чынлап та, бик өнәп бетерми булса кирәк, күзләренең очы белән генә Фоатка карады да сыңар куллап кына җилтерәтеп этеп җибәрде. Аның эре сөякле гәүдәсе, озын торыклы куллары өчен бәләкәй генә түгәрәк Фоатны җилпеп җибәрү — балалар тубын чөю белән бер иде, күрәсең.

— Чамалап сөйләш, телеңне песи ашамасын! — диде ул, ярым ачулы тавыш белән. — Карга күтәреп китмәсен!

— Иллә мәгәр куәтле егет тә инде бу Шабай, — дип көлде Фоат. — Тау-ташыңны күтәрер, тик уен сүзне күтәрергә генә көче җитмәс!..

— Татылдама инде, саескан баласы! — диде Шабаев, бармак янап. — Тагын чөям бит үзеңне, тайяр бул!..

Алда утырган шешә шулай да әкренләп бушады. Җиңел эчемлек кенә булса да, лагерьда киселеп беткән бу егетләрнең башына менеп алды ул. Булатов тагын тел кайрарга тотынды.

— Кара әле син безгә, Муса абый, — дип башлады ул. — Кыяфәтләр нинди шәп! Ташла син бу хәерче сәләмәләреңне, киен безнең шикелле! Менә без хәзер Гитлерның турылыклы ялчыларына әйләндек. Фриц! Туган илгә кайта калсак, «һальт!», «цурюк!» дип кенә кычкырачакбыз. Ә хатыннар тирәсенә сырышкан тәти егетләрнең өстенә туры килсәк: «Һенди һох!» — дип плен алырга да булыр...

— Алай бик турылыклы булгач, илгә кайтып йөрүнең ни кирәге бар сиңа? — дип көлде Шабаев. — Немец итеген туздырып йөргәнче, мондагы немкаларны гына атаковать кылсаң, хуп мәйле имәсме?..

...Үзләренең шушындый хәлгә төшеп, вөҗданга хиляф эшкә мәҗбүр ителүләренә бу кешеләрнең эчләре яна, торфлы җирдәге шикелле, балчык астыннан ут пыскый иде. Шуңа күрә дә тыштан шат, гамьсез күренергә тырышалар. Уен-көлке сөйләшкән булып, тапкыр сүзләргә ташланып, бер-берсен тел белән сөзеп тә җибәргәлиләр. Һәммәсе дә эч пошканнан, һәммәсе дә ялган хәлдә калган җанны кая куярга белмәүдән иде болар. Ләкин, сабагыннан өзелгән гөл, никадәр генә салкын суда тотсаң да барыбер шиңгән шикелле, озак та үтми, бу егетләр дә шәлперәеп төшәләр иде. Әле генә дуамал тере, тапкыр сүзле һәм гамьсез күренгән Булатов та, дошман киендергән тәти формалары һәм дагалы итекләре аны баскан, кыскан кебек, ничектер сыгылып төште. Кесәсеннән немец сигареты чыгарып кабызды да:

— Без янганчы, тәмәке янсын әле, — дип куйды. Бар көче белән суыргандай, тирән итеп бер суырып алды. Иреннәренә, борын яфракларына сыланып, куе аксыл-соры төтен чыкты, бит һәм яңак сөякләре буйлап әкрен генә югары күтәрелде. Гәүдәсен ия төшеп, терсәкләре белән ике ботына таянды да сүзсез калды ул. Аның артык борчылганы әллә каян сизелеп тора иде. Моны бик тиз аңлап алган Алиш Шабаевка карады да:

— Әйдә, Гариф, һава алыштырып керик, — дигән булды. — Боларның оҗмахы нинди рәк икән, аны да күрербез...

Алар кузгалып чыгып киттеләр. Фоат, шуны гына көткән кебек, телгә килде:

— Эшләр кәкәй бит, — диде ул, тирән сулап.

— Ничек кәкәй?

— Әллә синеңчә кәкәй түгелме? Әллә син шуны да аңламыйсыңмы?

— Аңлаган да күк булам булуын... — дигән булды Муса, сүзне Фоат иркенә бирергә теләп.

[1] Финанс министры.

— «Булам булуын» белән генә пычагым да булмый шул. Күзләреңне гафләт ярысы баскан булса, тырнакларың белән ертып ташла! Күрмисеңмени — сатлык товарга әйләндек бит! — дип кыза-кыза, бер авыздан әйтеп ташлады Фоат. — Ничек котылырга? Ул безне, берәмлекләп кенә түгел, уптым сата лабаса!..

Аның эчендә ниләр кайнаганын Муса шушы сүзләрдән үк сизеп алды. Кызган тимерне нәкъ менә хәзер чүкечләргә кирәк иде.

— Ә син үзең ничек уйлыйсың соң? — дип сорады ул аңа төбәлеп.

— Минме? Уем бер: качам! Моның хәзер җае да бар. Бакчи бу форманы, менә дигән маскировка! Немецның үзе булып йөрергә мөмкин. Тел ягы бар минем...

— Һәрбер сабыйның хыялы — шул,— диде Муса, кинаяле тавыш белән. — Тиз генә кача да котыла, имеш. Кыланып караган идек без дә...

— Кылану гына җитми шул, — дип көлде Фоат. — Бер кач, ун кач, котылганчы кач! Нигә мин үземне эт итеп изгән явызларга хезмәтче булыйм? Бәлки сиңа тәмле ашлар әләкмәгәндер әле. Ә мине, менә кара, автомат төйтәсе белән сыйлаганнар иде! — Ул киң итеп авызын ачты: һәр ике яктагы урт тешләренең асты да, өсте дә кырылып төшкән, тик сынык төпләре генә тырпаеп тора иде. — Менә бу кылыч ярасыдай кызыл җөйдә алты кырлы каеш камчы очы әле дә чыжлап тора!..

Муса аны кызганудан сүз таба алмыйча торды. Тирән сулап куйганнан соң гына:

— Әйе, дустым, каты булгандыр шул... — диде.

— Әле мин сиңа аркаларымны күрсәтер идем. Анда минем биография язылган, — дип дәвам итте Булатов. — Күңел буйсынмый, җан түзми, мин һаман качам, алар һаман тоталар һәм аркага яза киләләр...

— Димәкки, син качуны яхшы күрәсең? Шуннан башка юл күренми?..

— Юк, Муса абый, күренми.

— Ә соң Алиш сиңа бер сүз дә әйтмәдемени?

— Әйтте ул әйтүе-ен, — дип сузды Фоат. — Ләкин мин ышанмыйм аңа. Балалар уены гына булыр. Үзең тоткын хәлдә тоткынны азат итү мөмкин эшме? Үзең Иблискә кул биреп, аның тиресенә кергәч, бүтәннәрне иманга өндәп маташу — көлке түгелмени? Юк, мин качам. Миңа качмыйча ярамый. Чөнки мин үзем өчен генә түгел, кызым Эсфира өчен дә, сөйгәнем Сәгадәт өчен дә үч кайтарырга тиешмен. — Һәм ул алар турындагы аянычлы хикәяне Мусага да сөйләп бирде. — Менә шулай булгач, монда сүз белән маташканчы, кулыңа корал тоткан килеш актык сулышыңача тартышып үлү — мең яхшы!..

Алар озак бәхәсләштеләр. Берлин хәтле тирән тылдан ялгыз качып азаплану бары тик һәлакәткә генә китерәчәген аңлатуы шактый кыен булды. Чөнки Фоат үз өстендәге немец формасына, тел белүенә һәм акыл хәйләсенә бик нык ышана иде. Янәсе, немец солдаты төсендә һич тоткарсыз фронт буйларына хәтле бара да, җай китереп, партизаннарга яки үзебезнекеләргә ансат кына чыгып китә.

— Әйт әле, Фоат, — диде Муса. — Сезнең Седельце лагеренда күпме кеше бар иде?

— Унсигез мең дип сөйләделәр...

— Ә Демблин, Радом, Крушино һәм башка лагерьларда күпме булыр?

— Гел шуның хәтлешәр булсын ди.

— Димәкки, ким куйганда, йөз мең чамасы татар һәм башкорт әсире бар икән. Ә инде шуларга чуваш, мари, удмурт, мукшыларны да кушсаң?..

— Я, шуннан нәрсә димәкче буласың инде син? — диде Фоат, ниндидер һөҗүмнән сакланырга җыенган төсле. — Уптым-илаһи санаганда, гел дә йөз егерме миңгә җитсен ди... Шуннан соң?..

— Шуннан соңмы? Шуннан соң... шул гына, — диде Муса. — Әйдә, мин дә немец формасы киеп алыйм. Тел ягы миндә дә бар, МГУ бетергән кеше бит. Бик ныклап хәзерләник тә бер дә тотылмаслык оста хәйлә белән качыйк! Беләсеңме, мин шулхәтле Чулпанкаемны сагындым, аны күз кырыем белән генә бер күрер өчен җанымның яртысын бирер идем! Ә бит исән-сау качып котылсак, мин ул бәхеткә ирешә алам. Бәлки, синең дә Эсфираң исәндер. Син бит аларны кемнеңдер фараз белән әйтүе буенча гына диңгез төбендә яталар дип уйлыйсың... Әйе, миңа Чулпанкаем һәм Әминәм белән кавышу, сиңа Эсфираң белән Сәгадәтеңне эзләп табу мөмкин булачак!..

Фоатның күзләрендә өмет яктысы кабынды. Ул бөтенләй җанланып киткәндәй көлемсерәп куйды. Муса аның шат йөзенә карады да дәвам итте:

— Һәм безне үзебезнекеләр дә яманламас. «Берлин хәтле җирдән качып кайткач, молодец!..» диерләр. Без дә «коммунист намусыбызга тап төшермәдек!» дип, күкрәк сугарбыз, шәп бит, малай, бир кулыңны, сүз шушы булсын, әйдә качыйк! — Фоат кулын сузды, әмма Муса үз кулын сузарга ашыкмады. — Ә моңарчы үзең әйткән йөз мең кешене эт авызына ыргытып китик! Гитлер аларның күзен томалап, кулларына корал бирсен дә безгә каршы җибәрсен! Безнең көч күп бит, барыбер җиңәрбез!

— Нәрсә бу? Тукта! — дип кычкырды Фоат, урыныннан сикереп торып. — Ура кычкырып башладың, каравыл кычкырып бетердең... Ник син мине мыскыл итәсең?..

— Мыскыл...— дип көлде Муса, чыннан да мыскыллы тавыш белән. — Ә син герой! Шәп юл тапкан, ә! Юк, әгәр син коммунист булсаң, әнә шул йөз егерме меңне сөйрәп кара! Бәлки, бу эш бурлакларның Иделдә баржа сөйрәвеннән дә авыррак булыр, әмма шулай да сөйрәп кара син аны! Аңладыңмы?..

Моңарчы үпкәле күзләре белән Мусага текәлеп торган Фоат, артындагы бүкәнгә яңадан утырды да, терсәкләрен ике ботына терәгән килеш сөяк учлары белән йөзен каплап, солдатча авыр сулкылдый-сулкылдый елый башлады. Моны күреп тору Муса өчен чиксез авыр иде.

— Эчкә сыймас кара сагышларым башыма суккан, ахры, Муса абый, — диде Фоат тотлыгып. — Кичер. Төптәнрәк уйлаганда, әлбәттә, мин сукыр...

Ул тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, ләкин ишек ачылган тавыш ишетелде. Анда Муса белән бер блокта торучы Габбасов дигән егет күренде. Фоат тиз генә артка борылып торды да үзен рәткә китереп алды.

— Тегеләр әллә кая югалды, — дигән булды Муса. — Әйдә эзлик әле үзләрен.

Алар һавага чыккач, лагерьның бер читеннән ага торган авыл инешенә таба юнәлделәр.

— Анда минем сердәш тирәк бар, — диде Муса. — Әйдә, шунда барып утырыйк әле, нәрсә сөйләр икән?...

Ә якынлашсалар — аптырап калдылар, чыбык ботакларын кәүсәсенә сыендырып үскән куе яфраклы ак тирәк төбендә, Алиш белән Шабаевны ике ягына алып, Әхмәт Симай утыра һәм кулларын бутап, көлдерә-көлдерә нәрсәдер сөйли иде.

— Әйдүк, кәбәм! — дип кычкырды ул Мусага. — Коткар тизрәк. Мине монда ике фриц плен алды! Бак, синең үзеңне дә каптырган тегелме, атаем?..

Көлешеп алган булдылар. Алиш Фоатны Симайга тәкъдим итте.

— Беләм, — диде Әхмәт. — Килгәч тә күргән идем мин Фоатны. Һәм безнең сүз дә килешә аның белән. Менә мин фриц формасын гына киеп алыйм, аннары: прощай, сез безне күрә алмыйсыз — качабыз!..

Бу сүз әле генә булып алган хәлдән соң нindидер усал бер мыскыл итү шикелле ишетелде Фоатка. Күзләренең агын әйләндереп, ярсу ачу белән Симайга карап алды ул.

— Бакылдама, сер тотмас үрдәк, төлке чәйнәр муеныңны! — дип куйды. — Итегемне җәллим, олтаны тузар, син инде, брат, үзең генә сыздыр...

Бу юлы ни өчендер Мусага карап көлештеләр. Алиш күзләрен дә уйнаклатып алды: борычладыңмыни, янәсе.

— Ярар, дуслар, уен-муен бетмәс, чуен муен бөгелмәс, дигәндәй, мин инде сезнең өчегезне дә беләм, — диде Муса. — Ә менә Гариф иптәш Шабаевны белмим. Аның уйлары нindирәк икән? Бәлки, ул безнең барыбызга да әйтеп бирер?

Шабаев аягүрә басты. Җыелышта сөйләргә җыенган сыман җитди төс белән, хәтта тамак та кырып куйды.

— Ә мин сезне беләм, яшьтәш, — дип башлады ул. — Күреп түгел, укып беләм... Хәтта, үзем финработник булсам да, шигырь белән шашынып йөргән чакларым да бар иде...

— Нигә, аның гаебе юк, — дип көлде Алиш. — Безнең литфондта Закиров дигән бухгалтер шагыйребез сул кулы белән чутласа, уң кулы белән яшерен генә шигырь яза иде!..

— Минем дә шундыйрак чаклар булды, — дип елмайды Гариф. — Гафу итегез, шигырьдән башлавым болай гына... Хәер, бик «болай гына» да түгел инде ул. Менә монда бәхетсез язмыш очраштырмаган һәм киләчәктә бергә эшлисе Мусаның үзен күрмәгән булсам да, рухын электән үк белә идем дигән сүзем... Минем уйларым да нәкъ сезнекечә, иптәшләр. Мактана дип әйтмәгез, үз эчемдә дә шундый теләк ята иде. Әгәр шундый эшне кузгатучы берәү дә килеп чыкмаса, үзем нәрсәдер кыланып карамакчы идем. Юлдашлар тапсам, янәсе. Ә хәзер, башлаучыбыз Муса кордаш табылгач инде, мин бик рәхәтләнеп сезгә кушылам! Дөрес, мин бертөрле басынкырак, йомыграк кеше. Бәлки, бик зур эш тә кыра алмам, әмма коммунистик бурычымны намус белән үтәрмен, иптәшләр.

— Шәп әйттең, Гариф дус, рәхмәт,— диде Муса, аның кулын кысып. — Димәкки, мәсьәлә ачык, дуслар? Димәкки, эшкә тотынабыз?

— Әйе, тотынабыз! — диде Алиш. — Мин шундый начар настроение белән килгән идем бу лагерьга: боек, өметсез, суярга алып барылган сарык хәлендә... Ә хәзер күз алларым яктырып китте... Тик эчне авырттырып торган бер генә нәрсә бар...

— Нәрсә ул? — дип сорады Муса.

Алиш уңайсызланыбрак җавап бирде:

— Мин бит партиясез, иптәшләр. Сез коммунистлар арасында мин бер үзем — «ак күке — ят күке» булып калмам микән?

— Ә син, Алиш, — диде Муса, — шушы изге көрәшкә чыккан көнеңнән алып үзеңне коммунист сана. Без дә сине шулай кабул итәрбез. Ничек уйлыйсыз, дуслар?

— Дөрес, дөрес! — диделәр бар да, җыелыштагы шикелле бер аваздан. — Бу хакта бәхәс булуы да мөмкин түгел!

— Алайса култыклашып алыйк, — диде Муса. Бар да аягүрә басып, тирәк төбенә тезелделәр. — Без хәзер бәләкәй бер түгәрәк булдык, алдагы зур көрәшнең беренче күзәнәге! Без әлегә бишәү. Һәрберебез үзенә ике генә тугры юлдаш тапса да, без булырбыз унбиш! Тик шуны онытмагыз: безнең бу эш — бик яшерен сер. Теләсә кемгә сөйләү юк! Югыйсә дошманга бик тиз барып җитүе мөмкин. Фикердәшегезне башта бик ныклап өйрәнегез. Тәмам ышанырлык булгач кына, без аны

үз арабызга алырбыз. Ул чакта да әле ул безнең бу комитетта кемнәр барлыгын тиз генә белмәскә тиеш.

— Дөрес әйтәсең, — диде Булатов, — конспирация — иң кирәге. Чөнки без аждаһаның урт тешенә басып, бугазына ут салабыз. Ул шуны сизми дә калсын!..

«Фоат таба инде ул!» — дип көлешеп алдылар.

— Ә хәзер, Алиш белән безнең кыска гына антыбыз бар, шуны кабатлыйк, — диде Муса.

Егетләр, тимер кыршаудай култыкланышкан килеш, Муса белән Алиш әйткән сүзләрне кабатлап бардылар:

— Туган ил өчен, туган халкыбызның тапсыз намусы өчен актык сулышыбызгача көрәшербез!

— Татар егете туган иленә атмас!

— Үлсәк — бергә үләрбез, әмма дошманга серебезне ачмабыз!

— Шаһит бул, якты кояш: бу безнең изге антыбыз!..

Биш кешенең эчке киеренкелек белән чыккан тавышы, никадәр генә тыелган булмасын, яр буйларын яңгыратып җибәргәндәй булды. Йокымсырап яткан көзге инеш тә, өянке тал һәм көмеш тирәк башлары да, бу кешеләргә чит булуларына карамастан, шул ук сүзләрне кабатлыйлар кебек тоелды. Тирәк төбенә килә торган сукмакларда берничә кеше күренде. Алар да бу тавыш чакыруына ашыгалар төсле иде...

Муса моны абайлап алып, тиз генә ике кулын күтәрде дә:

— Бер. Ике. Башладык! — дип дирижерлык итәргә тотынды һәм үзе җырлап җибәрде:

Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә, ватып ал.
Сөюләрең чынлап булса,
Хәлил бәгырем, җанкисәгем,
Тәрәзәдән тартып ал...

Беренче сүзләрдән үк башкалар да кушылып киттеләр. Бар да киң итеп елмаешты. Чөнки балалар уены кебек кызык тоела иде бу аларга...

## II

Шәфи Алмаз шулай да сүзендә торды. Беренче очрашудан соң өч атна дигәндә, Мусаны алмага үзе килде. Шәфи, үзенең кодрәтле һәм зур кеше икәнен Муса алдында күрсәтәсе килү белән бергә, Розенберг каршында да үзенең җитди кешеләр белән эш йөрткәнен исбат итәргә тели иде. «Менә, күрегез, татарның танылган шагыйре, Мәскәү университетын тәмамлаган кешесе Муса Җәлил — сезнең алдыгызда үзе басып тора! — дип әйтмәкче булды ул. — Бу инде әллә кайчан иленнән аерылып, оныгылып беткән иске адәмнәр түгел, бу инде бүгенге татар мәдәниятенең тере йолдызы, моның кулыннан бик күп эшләр киләчәк, әфәнделәрем. Бу — безнең горурлык түгелмени? Әйе, әйе. Шәфи Алмаз солидный деятель буларак, эшен дә солидный йөртә белә. Клиентурасы да ни җитте түгел аның!

Икенчедән, немеснең шундый зур хадимнәре белән сөйләшү Мусаның үзенә дә гыйбрәт булыр. Бозау кирелеге языла төшәр. Һаман бәльшәвик кураен гына сызгыртып тормас. Туганда ук ата камунис булып тумагандыр! Әз генә дөньяны күрә белергә кирәк. Европа бит бу!..»

Ул шундый фикерләре белән буталып Френцель өендә утырганда, чакыртылган Муса килеп керде. Урыныннан торып, күрешергә теләгән Шәфинең күзләре аңа төште. Ул ирексездән тукталып калды. Муса өстендәге уңып, тузып беткән яшел шинельнең умырылган итәкләре, әллә кайчангы канга каткан чабулары, ике терсәгендә чачакланып тор-

ган ертыклары, ә башындагы кайсыдыр миллэт гаскәренең ямьшәеп, катып беткән пилоткасы, аякларындагы тимер чыбык белән буылган ярык агач башмаклары, чалбар дигән нәрсәсенең тез күзләре бүре авызыдай ачылып торуы аның кәефен кырды да ташлады. Мондый товарны ничек күрсәтергә кирәк? Немесләр бит, кәбестә яфрагына яки мүккә никотин сибеп ясалган тәмәкеләрен дә алтын путаларга урап, Төркиядән китерелгән «зифир» итеп саталар. Ә монда чын товарның да тиешле упаковкасы юк!..

— Френцель әфәнде, — диде ул, үпкәле тавыш белән. — Бу нинди хәл инде? Ул безнең атаклы шагыйребез, ә сез аны нинди кыяфәттә йөртәсез? Без ике сәгатьтән Розенберг әфәнде янында булырга тиешбез — оят түгелме сезгә?

Френцель, Розенберг дигән сүзне ишеткәч, утлы табага баскан мәче шикелле чабулый башлады. Мусаны тиз генә җилтерәтеп алып чыгып китте дә егерме-утыз минут узуга киендереп тә кертте. Бу юлы инде аның өстендә ярыйсы гына күренгән совет хәрби киеме иде. Бу киемдә Мусаның үзенә дә рәхәтрәк булып китте: никтер аннан фронт исләре килгән сыман тоелды; үзе дә, әйтерсең, бүген генә шуннан китерелгән иде ул. Бу киемдә аның гәүдәсе дә турая, башы да күтәрелә төште, горурлыгы да артып киткәндәй булды. Кем җилкәсеннән булгандыр инде ул, кайсы мескен монда салып калдыргандыр һәм ничек калдыргандыр аны? Әмма һәрхәлдә ул туган ил киеме иде һәм анда шул туган җирләр исе дә бар кебек иде.

— Менә хәзер бераз рәтләнгән, — диде Шәфи, канәгать булып. — Рәхмәт сезгә, һерр Френцель.

— Битешө-ө-өн! — дип сузды лагерь башлыгы. Бу аның аеруча күңеле булганлыгын аңлата иде.

— Ә сезнең белән без хәзер Остминистр каршына барабыз, Муса әфәнде,— диде Шәфи, рәсми төстә канат астына алган тавыш белән.

— Гаҗәп, — диде Муса, җилкәсен куырып. — Нигә кирәк икән мин аңа... Миңа, мәсәлән, аның бер тиенгә дә кирәге юк...

— Муса әфәнде! — диде Шәфи, нәразыйлык белгертеп. — Сез шундый итеп сөйләшәсез: гүяки сез әсир түгел, мин әсир!

— Нигә, андый хәлнең дә булуы ихтимал...

— Юк инде, энкәш, булмас! — диде Шәфи, катгый тавыш белән. — Шәфи Алмаз — бәльшәвик кулына калмас!

Муса эндәшмәде. Бу кеше белән артык сүз көрәштереп торуның файдасы, әлбәттә, юк иде. Куелган курчак кына бит. Аның шулай булуы беренче очрашуда ук Мусага бик яхшы аңлашылган иде. Төп мәсьәлә — немецлар белән нинди тактикада булу. Нәрсә өчен чакырткан була икән соң бу Розенберг дигәннәре? Кыргый киек күрер өченме? Мин бит андый мөһим фигуралар өчен беркем дә түгел...

Шәфи Алмазның кыршылган эмальле, тәбәнәк сөйрәле бәләкәй генә машинасы дөньяны күп күргән булса кирәк: «кытыр-пытыр» килеп, сасы сөремнәрен таратмыйча, кузгала алмый торды. Шәфи Мусаны шуңа утыртып, көчкә ходка җибәрде дә алып китте:

— Сугыш комачаулый, җүнле машина да күреп булмый, — диде Алмаз, гафу үтенгәндәй итеп. — Шушы кылтыравык белән чикләнергә туры килә.

Муса бу юлы да аның зарын ишетмәде. Ул үзенең яңа уйлары, яңа планнары эченә чумган иде. Вустрауга ни өчен китерелүен әле ачык белмәгән Мусаның, беренче тапкыр Шәфи ясаган пычрак тәкъдимне ишеткәч, чәчләре үрә torгандай булды. Шунда ук бу кешене эт урынына тиргәп, йөзенә төкереп җибәрмәкче иде ул. Әйдә, теләсә нинди лагерьга озатсыннар, хәтта ассыннар, крематорийда терелэй яндырсыннар — барыбер! Остминистренә дә шул ук сүзләрне әйтәсе: «Коммунист башым белән бервакытта да сезнең алда ялчы буласым да, тезләнәчәгем дә

юк!» диясе иде... Әмма шул ук төлке Шәфи авызыннан ычкынган кайбер сүзләр аны бу кискенлектән тыеп калды. Ә инде мондагы хәлләр белән танышкач һәм иптәшләре белән күрешкәч, аның каршында бөтенләй башка дөнья ачылып китте, башка планнар туды. Хәзер инде бүтән тактика кирәк булачак. Хәзер алар яңа юлга чыгалар. Хәерле генә булсын бу юл, уңышлы гына булсын иде!

Алар, Берлин университеты артындагы тар гына Доротеештрассе белән килеп, кечерәк кенә бер мәйданга туктадылар. Муса, машинадан чыгу белән үк, каршысында өч биек платан агачы күрде. Ул агачлар астында, яңгырдан ышыкланган шикелле, гади генә постаментта бакыр бюст һәйкәл тора иде. Якынрак килеп карагач, Муса аның Гегель һәйкәле икәнен белде. Гегель, Гегель! Заманында аны өйрәнеп күпме баш ваткан иде ул. Менә кайда очраштылар. Немецның атаклы диалектик философы әнә ничек тыйнак кына монда посып калган. Әйтерсең, ул университетка алгы ишектән керә алмаган, аның киң залларына узарга көче җитмәгән билгесез бер магистр. Һәйкәле дә бөтен буйга түгел, бакыр бюст кына. Ә нигезе — дүрт почмаклы гранит өеме. Философның тирән мәгънәле сүзләреннән берәр өзек тә язылмаган, бары тик исем һәм дата гына. Күрәсең, немецлар өчен искитәрлек кеше булмаган ул. Шулай да мәйданчык Һигельплац дип атала икән...

— Остминистериум әнә шул йортта, — диде Шәфи, бармагы белән алга таба күрсәтеп. — Университет китапханәсенең бер корпусында.

— Зинадан туган баланың һәрвакыт шулай инде ул — үз бишеге булмый, — диде Муса, — кешенеке белән кештәкләнә.

— Һай телегез, һай телегез, әфәндем!— дип үтәләнде Шәфи Алмаз.— Һич булмаса, министр алдында тыя төшегез, үз файдагыз өчен!..

Ул, алдан йөреп, Мусаны бина эченә алып керде. Бераздан аларны кабул итү бүлмәсенә уздырдылар. Зур-зур тәрәзәле, калын стеналы, биек түшәмле кечерәк залга охшаган бу бүлмәдә яшел хәтфә белән ябылган берничә өстәл һәм алардан читтәрәк утыручы берничә кешене күрде Муса. Шәфи аларга «Һайль Гитлер»не әйтеп, кычкырып сәлам бирде. Аннары Мусаны таныштыра башлады:

— «Идел-Урал» комитетының зондерфюрере доктор Унгляубе. Татар халкының күренекле шагыйре Муса Җәлил...

Муса каршында торган чуар сипкелле, башына ут кабынырдай кызыл җирән чәчле, тук гәүдәле, озын буйлы кешегә рәсми төс белән сүзсез генә баш иде. Бу ничек «зондерфюрер» икән?.. «Зондерфюрер, зондерфюрер»... ничек аңларга? Димәкки, ябык лагерь булган кебек, ябык фюрер, негласный фюрер дә була инде?.. — дип уйлады ул.

Аннан узгач, Шәфи икенче исемне әйтте:

— Шәрык телләре галиме профессор Фон Менде...

Тагын шундый ук хәрәкәтләр һәм яңа исемнәр кабатланды. Аннары «Мария Карловна Кальтенер» дигән бер руслашкан немка белән таныштырдылар. Аннары Муса күрсәтелгән урынга килеп утырды.

Озакламый чаршаулы ишекләрнең берсеннән Розенберг үзе килеп чыкты. Шактый олы гәүдәле, тулы битле, кыскарак муенлы бу кеше Пруссиянең мал асраучы, сыр ясаучы фермер-бюргерларын хәтерләтә иде. «Һайль...» белән гомуми сәлам биргәннән соң, Мусага таба атлап, аның буй-сыны бик үк мәһабәт булмавын хуплап бетермәгәндәй елмаюын арттыра төште һәм, үзенең гомумән кече күңелле, ә Мусага исә, ихтирамлы икәнен күрсәтер өчен, күрешергә кул сузды:

— Сез безнең хөрмәтле кунагыбыз, исәнмесез, господин Муса Ялиль! — диде ул, немец акценты белән русчалатып. — Пожалуйста, сядитес, кунак булыгыз...

Муса исә сузылган кулны алырга мәҗбүр булды. Министрның кулы шешенке һәм суык иде; бәлки, шуңа күрәдер, ул кул Мусада бака тәненә кагылган сыман бер тойгы калдырды. Баягы немка бокал сымак олы

бүксәле, тәбәнәк аяклы тирән рюмкаларга бөкесе аркылы нечкә генә кәкре трубка уздырылган зур шешәдән унар тамчы чамасы коньяк салып чыкты, аргы баштагы түгәрәк өстәлдән конфет һәм печениеләр китерде. Шунда ук официанткача киенгән икенче бер кыз-ханым кечкенә генә чәйнек һәм чынаяклар белән кара кофе кертте. «Кара боларны, важный кылынган булалар», — дип утырды Муса эченнән генә.

Альфред Розенберг, наци партиясенең теориячеләреннән берсе булып, үзен әдәбият-сәнгать өлкәсендә дә белдекле кешеләрдән саный иде. Утыз җиденче елларда Совет иленнән качкан бер-ике әдәбиятчыны да үзе кабул итеп, аларны канат астына алды. Мусаны да, бәлки шундыйрак кешедер, җай китереп Сталин игосыннан котылгандыр, дип, үзе күреп, сынап карамакчы булды. Ул үзе дә егерменче елларда Совет җиреннән качкан немец булганлыктан, бу хис аңа аеруча таныш иде.

— Әфәнделәр, — диде Розенберг, яңадан аякка калкып. — без бүген кадерле кунак белән очрашабыз. Муса Ялиль әфәнденең әсәрләре хәтта Германиягә кадәр килеп җиткән. Менә аның җыентыклары, менә ул чыгарган балалар журналы. — Ул, үзенең папкасыннан алып, Мусаның сугышка кадәр латин хәрефләре белән чыккан кайбер җыентыкларын һәм бер «Октябрь баласы» журналын күрсәтте. Боларны, Карип Ишбулдин теге вакытта Гумеров дигән кешенең Муса Җәлил булуын кайтып әйткәч, Берлин университеты китапханәсеннән бик ашыгыч рәвештә эзләтеп, Шәфи белән профессор Фон Менде китереп биргән иде. Муса, әлбәттә, моны белмичә, бик аптырап утырды. «Каян тапканнар болар андый нәрсәләрне?..» дип гаҗәпләнде ул.

— Кызганычка каршы, мин үзем укый белмим, — дип дәвам итте Розенберг. — Әмма татарча укый белгән кешеләр дә әз түгел. Аларның әйтүенчә, Муса әфәнде — яхшы шагыйрь, популяр шагыйрь. Аның кебек Дейчлянд күләмендә дә популярлашуе өчен без, әлбәттә, көчебезне кызганмабыз. Ягез, әфәнделәр, кадерле кунак хөрмәтенә, аның белән танышу һәм дуслашу хөрмәтенә бер тост күтәрик...

«Кайсы яктан суктыралар!.. — дип уйлады Муса, башкалар белән бергә бүксәле рюмкасын күтәргәндә. — Егыл да кит!..»

Тамчылар авызларга капланды. Шушындый речь белән сугарылган немец коньягы аның тел очын ялкын шикелле көйдереп алды. Кара, нинди зәһәр икән! Мусаның күзләре һәм аңы житез хәрәкәттә иде. Тагын ниләр кыланырлар, дип көтте ул, сынаулы карашын министрдан алмады. Розенберг тагын дәвам итте. Аның кәефе гаять күтәренке, мөлдерәп торган шатлыгы тышка бәреп чыккан иде.

— Без бүген тарихи көннәр кичерәбез, әфәнделәр, — диде ул, күзләрен Мусага төбәп. — Хакыйкать ачы булса да әйтми хәл юк — Кремль актык сулышын тартып чапалана, ярга ташланган балык шикелле тыпырдый. Чөнки даһи фюрерның шәүкәтле гаскәрләре Русь йөрәгенең беренче кан тамыры булган Вольга елгасына чыгып басты. Русь йөрәге безнең итек астында хәзер! Сезнең өчен дә куаныч зур, хөрмәтле кунагыбыз Муса Ялиль әфәнде, һәм сезнең өчен дә, Шойфи Альмаз әфәнде! Чөнки Шталинград белән Казан арасын безнең немец пантерасы бер генә сикерәчәк. Ә Казанны алу белән татар халкына польный протекторат! Президенты — Шойфи Альмаз әфәнде; вице президент яки премьер-министр — Муса Ялиль әфәнде. Вольга буенда яшәүче бүтән вак-төяк халыклар «Идель-Урал» штатына баш иячәк. Бөек Дейчлянд аларның эчке эшенә тыгылмый, фюрерның бары тик бер генә резиденты күзколак булып торачак...

Бармакларын бер-берсенә аралаштырып җитди генә сыман утырган Мусаның йөзендә нечкә һәм нәзакәтле көлемсерәү күренде. Аның артында бәреп чыгарга торган киная һәм ачы нәфрәт барлыгы сизелә иде. Чөнки Розенбергның әлеге нотыгы артык шапырыну, җиңүче мактануы һәм буш декларация булып ишетелде аңа. Ә министрның җитди кеше

булуын, сүзләрен үлчәп кенә сөйләвен көткән иде ул. Шуңа күрә, никадәр тыенкы булырга тырышса да, аңа җавап бирмичә булдыра алмады. Бераз тамак кыргалап торды да:

— Гафу итегез, министр әфәнде, — дип, Розенбергның сүзен бүлдерде. — Илчегә үлем юк, шагыйрьгә хөкем юк, дигән безнең халык. Шуңар күрә сорыйсым килә: ит күргәнгә үпкә тансык булыр микән?..

— То есть ничек? Аңламыйм сезне, майн һерр, — диде министр, кашларын җыерып.

— Татар халкының республикасы бар, аңа башка төрле уенчык кирәк булыр микән?.. димәкче идем...

— Нинди уенчык? — дип, тавышын көчәйтте Розенберг. — Уенчык ул — большевиклар биргән республика! Марионетка! Ә протекторат — яңа Европаның иң демократик типтагы казанышы! Шәрык халыклары Европача эш йөртәчәк!

— Мәсәлән, Чехия протектораты шикеллерәкме инде ул, әллә «Польша губернаторлыгы» төслерәкме?.. — дип, тагын сүз кыстырды Муса гөнаһсыз гына төс белән.

— Һерр Мусза! — дип куйды Розенберг. Аның инде соры кашлары, кара-каршы очкан ике ук шикелле, бер-беренә килеп терәлгән, астан караучы күзләре очкынланган иде. Ләкин ул үзен тотып калды. — Сез моның белән ни әйтергә телисез? Аңлап җиткермәдем.

— Һични теләмим,— диде Муса, тыныч тавыш белән.— Кунак буларак беләсем генә килгән иде... Сез бик киң колач белән сөйлисез... Казан шактый ерак бит ул... Европаның аргы башында... Юллары да чокыр-чакырлы...

— Майн һерр, — диде министр, нервлы елмаеп, — сез анысы өчен хафаланмагыз, фюрер солдаты Африка чүлләренә дә барып җитә ала!..

— Шулай да һавадагы торнага караганда, кулдагы чыпчык яхшырак диләр бугай.

— О-о! — дип көлде Розенберг. — Тагын фольклор! Анысы ничек була инде?

— Соң менә Шәфи әфәнде белән миңа «Куцый-веци» президентлык вәгъдә итү — шул түгелме?.. Белмим, ул ничектер, әмма минем Казанга хәтле немец арбасындагы дегет чиләге булып сөйрәләсем килми...

— Хах-ха-ха! — дип көлде немец. — Ай-яй мактыйсыз үзегезне!

— Нигә, әллә безгә халык шуннан да артык бәя бирер дисезме? Теләсә, үз арасыннан да сайлый ала бит ул. Моңарчы шулай иде: үзе сайлый иде ул, яшерен тавыш белән!

Шәфи Алмазны бизгәк тотты. «Бөтен эшне харап итә бу. Үз башына да җитә, минем башны да ашый. Ышаныч юк сезгә дип, куачак хәзер Розенберг. Кулдан мал ычкына!..» — дип көенде ул. Чынлап та, Шәфигә Розенбергның уңай карашын казаныр өчен күпме угаланырга, күпме йөз суы түгәргә туры килде бит. Арткы тәпиләренә басып, күпме койрык болгамады, Унгляубе белән Фон Мендегә нинди бүләкләр ясарга мәҗбүр булмады ул. Ә хәзер шуларның һәммәсе дә җилгә очармы?.. Менә бит нинди кешеләре бар бу татарның, шайтан алгыры! Үзе ниндидер кечкенә генә бер киек төсле бу Муса, ә үзе шоп-шома гына итеп немец овчаркасының борынын тырный! Менә Иблисне!

Розенберг әфәнде дә шактый сагая төште; юк, бу шагыйрь кисәге ул көткән кеше булып чыкмады, ахры. Бик яшел күренә. Шулай да кулдан ычкындырмаска иде. Әсирләр арасыннан бер җүнле кеше килеп үзенең хезмәтен тәкъдим итми бит. Бу да баш тартырга чамалый кебек Ә кеше — кирәк, көчле кеше кирәк. Бу шагыйрь теләп эш итсә, чаң тавышлы була алыр иде, үз артыннан күпләрне ияртер иде... Министр әфәнде яңадан аңа мөрәҗәгать итте:

— Сезнең талантлы шагыйрь булуыгыз үткен сөйләшүегездән, халыкчан метафора һәм аллегорияләрегездән үк күренеп тора, — диде

ул. — Лэкин сез шактый дәрәҗәдә пропагандага бирелгәнсез. Без бит андый ук куркыныч җанварлар түгел, якынрак килеп карагыз, дөреслекне ачыграк күрерсез. «Не так страшен тшорт, как его малюют» диләрме әле руслар? Без дә шулай сезнең файда өчен тырышабыз бит... Сезгә киң колач җәеп җырларга кирәк хәзер. Хезмәттәш булыйк, Муса әфәнде!

Муса соңгы көннәрдә бик ачынып һәм бик ярсып йөри иде. Немецларның Сталинградка кадәр барып җитүе шулай ачындыра иде аны. Нәрсә соң бу? Нишлиләр безнекеләр? Ни өчен шулкадәр тирән тылга җибәрәләр? Күпмегә хәтле дәвам итәр? Чынлап та, бу бакыр башлар Казан хакында ук уйлыйлар микәнни соң? Ихтимал, булыр да. Шашынуларына бер дә чик юк ич. Болай да тәкәббер немецның борыны күккә барып бәрелгән хәзер. Җитмәсә, матбугатларында нинди кабахәт тел белән мыскыл итәләр тагы...

Мусаның эчке кесәсендә «Унтер мёншь» дигән журнал ята. Кичә лагерьда Әхмәт Симай биргән иде аны. «Ярты кеше» дигән мәсхәрәле исем белән немец хәрбиләре өчен чыгарыла торган бу сафсата журнал — Советлар Союзы халыкларыннан, бигрәк тә көнчыгыш халыкларыннан, иң кабахәт көлү, аларны хайванга, ишәккә тиңләү шикелле тупас мыскыл итүләр белән тулган. Бу язмаларны укыган немец солдаты, әлбәттә, үзенең кыргыйларга каршы сугышуына һәм аларны кыру хәләл эш булуына һичшиксез ышанырга тиеш. Анда язылганнарны укыгач, Мусаның төсләре күгәреп киткән иде. Менә хәзер аның шул ачуы яңадан кабынды да, кесәсеннән «Унтер меншь»не чыгарып, Розенбергка сузды.

— Хөрмәтле министр әфәнде, бик колач җәерлек түгел шул! Рәхим итеп шуны укып карагыз әле, — диде ул. — Менә бит безнең хакта нәрсәләр язалар! Ә сез хезмәттәшлек, дисез... Сездәге татар әсирләренең кимендә илле проценты урта мәктәп бетергән, кимендә егерме проценты вуз бетергән кешеләр. Белмимени алар немецчә? Укымыймыни шушы пычрак мыскыллауны? Җәберләмимени ул аларның намусларын?

Розенберг ала-кола төскә керде. Тиз генә җавап сүзе таба алмады, бу адәм белән вакланып утырырга мәҗбүр булуына ачуы да килде. Шулай да уенны ахырга кадәр җиткерү кирәк иде.

— Моны бит безнең коллега Һеббельс әфәнде чыгара, — диде ул, елмаерга тырышып. — Һәм ул журнал тукталачак. Чөнки җиңүче Дейчлянд Ост халыкларына карата бөтенләй яңа политика йөртә хәзер. Фюрер аларга мәрхәмәт белән карарга куша.

— Монысы бер хәл... — диде Муса, беркадәр басыла төшеп. Чөнки ул әйтәсе килгәнне әйтеп бетерде шикелле инде һәм аңа шушы урында борылыш ясау кирәк иде. Иблискә кул бирәсе булгач, гел кирегә сукалап булмый ич... — Безгә дә эшләве күңеллерәк булыр... — дип өстәде ул.

— Гевисс, гевисс[1]! — дип кабатлады министр, йөзе ачылып. — Без сезгә, Ялиль әфәнде, иң яхшы урыннар тәкъдим итәбез!

— Тәшәккердән гаҗизмен, хөрмәтле шеф, — дип җавап бирде Муса. Ул инде үзе дә уенга керешкән иде хәзер. — Әмма мин күләгәдәрәк хәрәкәтләнүне файдалырак санар идем. Чөнки сразы зурдан тотынсам, якташларымны өркетеп куюым ихтимал... Мин, мәсәлән, поэзия белән бер рәттән музыканы, гомумән сәнгатьне бик яратам. Германия нең шигъри титаннары алдында гына түгел, бөек композиторлары алдында да баш иям...

— Отшен приатно! — дип куйды министр. — Нindирәк эш теләр идегез соң?..

[1] Әлбәттә.

— Бар андый эш, — дип кычкырды Шәфи Алмаз. Ул Розенбергның «вице президент», «примьер-министр» дигән сүзләреннән куркып калган иде, чөнки андый претендентларның әледән үк янында йөрмәүләре яхшы. Юкса, үзеңне бәреп төшерүләре мөмкин. Шуңар күрә хәзер конкрет эш күрсәтү бик урынлы иде.

— Нинди эш? — дип сорады Розенберг.

— Безнең батальоннарда культвзводлар бар, анда музыкант, жырчы, артист халкы бар — шуларга житәкчелек итсен, лекцияләр укысын!

— Бик шәп булыр, бик теләп алынам, — диде Муса, куанып. Ул үзенең Берлинда гына ябылып ятмыйча, шушы эшеннән файдаланып, халык арасында йөри алачагын уйлап өлгергән иде. — Мин риза!

— Алайса, мин каршы килмим, — диде Розенберг куанычлы чырай белән. — Ләкин сезнең өчен бик кечкенә булмасмы, хөрмәтле кунак?

— Кечкенәдән башлыйк, министр әфәнде. Зурына өлгерербез. Альпинистлар өй түбәсенә менүдән башлыйлар, имеш...

— Үзегез тапкыр сүзле сез, — дигән булды Розенберг.

Моңарчы күләгә шикелле утырган Фон Менде, Унгляубе белән башкаларга да гомуми җанлану керде; әлеге кыз-хатыннар да, каяндыр пәйда булып, бокалларга яңадан унар тамчы коньяк тамыздылар, сельтерски сулар салдылар. Хәзер инде сүз чәкәше тынып, хрусталь чәкәше яңгырады.

— Безнең килешү өчен! — дип игълан итте министр...

Кунаклар таралыша башлады. Иң элек Муса чыгып китте. «Сатылу» мәрасиме аның күңелен тырнаса да, гомумән алганда, канәгать иде ул. Чөнки үзенең көчле нәфрәте, буйсынмыйча бәреп чыгып, бөтен эшне кырып ташлавыннан курыккан иде. Ярый әле, үз вакытында үзен тотып кала белде һәм эшнең дә төп максатны үтәү өчен иң файдалысы табылды.

Муса артыннан Шәфи чыкты. Ул да бик канәгать иде. Муса, әче телле булса да, молодец егет икән, аның өчен хәвеф-хәтәр тудырмады, эшнең бәләкәенә дә риза булды. Бәләкәй булса да Шәфи аңар бик һәйбәт мәгаш [1] билгеләр, өс-башын инәдән-җептән чыккан белән киендерер!..

Шушы куанычы белән кулларын җәеп, Муса янына килде ул:

— Әйдә, Муса әфәнде, алып килгәнмен икән, илтеп тә куйыйм инде үзегезне, — дип машинага кыстады. — Ай-яй, оста һәм кыю сөйләштегез. Ул-бу булмагае дип, бик курыккан идем, үзегез сәләтле тагы: нәкъ кирәк урында гына борып җибәрә белдегез. Шулай, шулай, җае килгәндә борыннарына чиертү ярый аларның, бик масаймасыннар!

Немецлар үзләре генә калгач, Розенберг кашларын җыерды.

— Күрдегезме нинди Вильде [2]! — диде ул. — Мәчкәй шикелле ташланырга тора. Тибеп очыра яздым үзен. Шулар белән эш итәргә кирәк диген, ә? Карагыз, күз-колак куегыз, чи коммунистлыгы әллә каян билгеле. Аның ул тинтәклеген кагып чыгарырга кирәк башыннан!

## III

Маһия ханымның туган көне якынлашты. Ул аны ел саен күңелле бер бәйрәм төсендә уздыра килә һәм бәйрәм саен нindidер яңа кунаклар, яңа куанычлар була торган иде. Быел да шулай истә калырлык булсын иде ул көн! Ни арада килеп җитә торгандыр тагын үзе. Күрми дә каласың, бер елың тәгәри дә китә. Эх, уза гомер, искән җилдәй уза! Ә гомер узган саен кеше ешрак артына әйләнеп карый, кайтмас яшьлеген сагына; шул яшьлегенең кадерле хатирәләрен, кыз чакта бәйлән-

[1] Эш хакы.
[2] Кыргый.

гән ефәк тасмалары сыман, сандык төбеннән алып кат-кат сүтәргә тотына. Маһия ханымның да шундый көннәре җитеп бара. Бер «ах!» итүдә Шәфи дигән «заграничный кияү»гә атылып чыккан тиле чаклар кайларга китеп югалды хәзер? Кайда икән ул Казан гимназисткасы, Мәскәү студенткасы Маһия? Дөресен әйткәндә, ул инде Маһия дә түгел бит хәзер. Ул күптән инде Фрау Мага Альмаз булып санала. Һәм аңа шул хәтле күнегелгән, әйтерсең, чынлап та, мулла хәзрәт кайчандыр аңа шундый исем кушкан һәм гомер буе шулай дип йөрткәннәр!

Маһия ханым, Берлинга килгәннән соң шундый зур йортның хуҗасы булып төпләнгәч, иң элек үзенең татарлыгын кырып ташлауны һәм аннан бөтенләй качуны кичектергесез кирәкле эш итеп санады. Шул ният белән солдат һәм турист өчен чыгарылган «сөйләшкеч»тән башлап, калын-калын сүзлекләр һәм цивилизацияле булуын күрсәтүче бик күп китаплар җыйды. Алар белән маташу аның куанычы иде. Европа үзәгендә яшәгәч, европача булырга тиеш бит. Синең әллә кайдагы татар дигән милләтеңне кем белә? Аның берәр цивилизациясе, атаклы кешесе, тарихта тоткан якты урыны бармы? Берсе дә юк бит. Киресенчә, монда ул сүзне әйтә дә белмиләр — «тартар» диләр. Берәүләре шул «тартар»ны ишетүгә: «О, беләм, беләм! Альфонс Додэ, «Тараскон Тартарены», бик кызыклы китап!» — дип шаккатыралар. Икенчеләре исә: «О, тартар! Бөтен Европаны басып алучылар, кан диңгезе ясаган Батухан!» — дип, сиңа күзләрен алартып карыйлар да артка чигенә башлыйлар. Син шул әллә кайчангы монголлар, җирдә сөякләре дә калмаган какой-то Батуханнар вәкиле булып, шул кыргыйлар өчен гаепле кеше булып йөре!

— Боже мой, как это страшно дико!

Килгән елларында Маһия ханым, яртылаш русча сөйләшкәнлектән, шулай дип кенә җилкәләрен куырып куя торган иде. Әмма Берлинда русчага осталык модасыз нәрсә булып калды, чөнки бары тик үз телләрен генә иң югары санаган немкалар өчен рус теле әллә бар, әллә юк иде. Шуңар күрә Маһия ханымга үзенең зирәк зиһене белән немец сүзләрен «сөйләшкеч»тән башлап ятларга туры килде. Күрше тирәләренә үзен «Фрау Мага Альмаз» дип танытты ул. Бөтен өй җиһазларын немецча итеп корып җибәрде, Шәфине дә немец теленә, немец гадәтләренә дүмбәсләп өйрәткәндәй өйрәтә башлады: «Ох и балбес же ты, чүлмәген абсолютно буш, круглый тинтәк!» дип мактый иде ул аны. Фрау Мага, гомумән, искиткеч кодрәтле һәм сөекле хатын булып чыкты, Шәфине тиз арада башмак астына салып, бик оста гына үтүкли белде. Аның киңәшеннән ире бервакытта да чыкмый иде. Фрау Мага үзенең бер-бер артлы диярлек туган кыз балаларына да Альбина, Шарлотта дигән немец исемнәре биреп, немец имезүчесе һәм немец нәнкәсе яллап, бишектән үк немецчә тәрбияләп үстерде. Әлбәттә, аның балалары татар теле шикелле «бер тиенгә кирәксез, тупас һәм чүп тел»не белмәделәр. Кайчакларда Шәфи ялгышып үз кызларына татарча эндәшсә, «без андый «каля-маля» җен телен белмибез!» — дип, мәсхәрәле җирәнеп, әниләре шикелле җилкәләрен генә куырып куялар иде.

Шулай бәхетле генә немецләшеп килгәндә, Мага ханымның бәләкәй генә, сай гына күңел күлен кинәт бер җил тирбәндереп, хәтта чайкалдырып ташлады. Ул җилнең исеме французча басым белән Скандéр, фамилиясе Яушéф дип әйтелә иде. Чөнки ул элегантный яшь кеше, сүзләрне сайлап кына, французча акцент белән генә сөйли торган ул сөйкемле егет Франциядән килеп чыкты. Килеп чыкты да Мага ханымның туган көнендә Шәфиләр өендә күренде. Һәм шул бәйрәм кичендә инде, шук малайлар яшел җәтмә корып песнәк аулаган шикелле, Мага ханымның күңелен аулап та алды. Шуннан соң Мага ханым яңа бер дөньяга чумды. Бичара песнәк әлеге малайлар кулында ничек пырхылдаса, ул да Скандерик кочагында шулай тетрәнә иде. Юк, мескен песнәк шикелле

ычкыныр өчен талпынып түгел, ә ниндидер азгын дәрт белән ярсыды ул...

Әмма бу «яшерен бәхет» озакка бара алмады. Мага ханым тәмам тилереп житкәч кенә Скандерик юкка чыкты һәм аның бер бай немкага өйләнүе, аннары завод хуҗасы булып китүе ишетелде. Хәзер Мага ханымның аны күрмәгәненә озакламый өч ел тула. Ә күрәсе иде, күзнең бер кырые белән генә карыйсы иде: шул немкасы, Маганы ташлатырлык «хур кызы», нинди нәмәрсә икән? Үзе ничек икән? Бөтенләй онытты микән инде ул аны?.. Тукта, туган көн бәйрәменә аларны да чакырсаң, нәрсә булыр икән?..

Мага ханым күрше бүлмәдән ирен дәшеп керттe.

— Кара әле, Шәфус, — диде, — бәйрәмгә кемнәрне чакырабыз?

— Нинди бәйрәмгә ул? — дип гаҗәпләнде Шәфи Алмаз.

— Менә тагы, хатыныңның туган көнен дә оныттың мәллә? Шул солдат арасында ышкылып, солдафон булып беттең инде. Уналтынчы ноябрьда минем туган көнем, хәзер ике көн калып бара!

— Ай, асылташым, гафу ит, бөтенләй хәтердән чыккан, — диде Шәфи.

— Синең шул булыр!

— Алай түгел инде, алтыным. Мин бит син дигәндә... — дип акланды Шәфи, ялынчак тавыш белән. — Ә бәйрәмеңне бик шәп итеп уздырабыз! Беләсеңме, яңа кунаклар чакырабыз!

— Да-а?! — дип сорады Мага назлы тавыш белән.

— Әйе, әйе, доктор-юрист Унгляубене, профессор Фон Мендене һәм... әгәр түбәнсенмәсә...

— Остминистр Розенбергны?

— Нәкъ үзен! Группенфюрер Альфред Розенбергны.

— Ах, нинди шикарно булачак! Алар белән аралашу минем күптәнге мечтам инде, Шафус!

— Минем дә шулай шул! Үзебезне милли яктан да күрсәтергә кирәк. Немец үз милләтен күрсәтүне бик ярата бит...

— Ә ничек итеп күрсәтергә?

— Минемчә, берәр төрле милли аш хәзерләсәң, деликатес итеп?

— Ах, искиткеч. Гөбәдия, бламажи пешерәм. Безнең Казанда бик шәп әзерлиләр иде.

— Бик шәп булыр. Ә үзең миллирәк итеп киенсәң, әйтик, калфакмы шунда?..

— Оригиналиш идея! — диде Мага ханым, күңеле тулып. Шәфи шул уңайдан файдаланып өстәп куйды:

— Алардан башка тагын берничә кунак...

— Алары тагын кемнәр?.. Шул кляузник эмигрантларыңдыр инде?

— Түгел, ефәк чәчем; алардан — бер Гани әфәнде генә. Ул инде мулла кеше, әйдә, бер фатиха бирер. Ә калганнары бөтенләй яңа кошлар, яңа хадимнәр.

— Шул бетле татариннарыңдыр инде, — диде Мага ханым, кылдан нечкә кашларын сындыргалап. — Ни шайтаныма кирәк шулар? Өеңә бет коеп, инфекция кертеп калдырсалар?

— Син инде бигрәк, энҗе тешем, — диде Шәфи, үпкәле тавыш белән. — Алар арасында әдип, шагыйрь һәм мөхәррирләр бар, инженер, экономист, финансист шикелле әгъля товарлар бар. Алар житәренчә мәдәни кешеләр. Шуларның берсен хәтта министр әфәнде үзе кабул итте, ә миңа инде бөтенләй оят булачак!

— Оят, имеш! Ә менә күптәнге дусыбыз, атаклы завод хуҗасы, Германиянең кирәкле кешесе Искандер Яушеф әфәнденең бездә булмаганына һәм без аны беспардонно чакырмавыбызга ничә ел? Өч ел тулып бара түгелме? Менә кайда ул оят!

Бу гайрәтле сүзләрдән соң Мага ханымның түфли үкчәләре артык еш һәм зәһәр шакылдый башлады. Искәндәр исемен ишеткәч, йөзен чытып булса да, Шафи, әлбәттә, аңа бик тиз ризалык бирде, хәтта бүген үк телеграмма җибәрәчәген әйтте. Шулай итеп, һәр ике якның да теләге булды һәм бу өйдә бәйрәмгә әзерләнү бизәге башланды.

IV

Җәй көне малайларның кайбер йөрәклерәге урманнан карчыга баласы тотып кайта. Оясыннан егылып төшкәнгә күрә генә кулга эләккән бу кошчык бөтен авыл малаенда соклану тудыра. Аның җирән-чуар каурыйлары да, матур кәкрәеп килгән томшыгы да, балык тәнкәсе хәтле генә яшел-соры кыргый күзләре дә, эләктергән нәрсәсенә тырнакларын шундук батырып өлгерә торган нечкә кыртыш аяклары да чын карчыга токымын беренче күргән малайлар өчен искиткеч кызык яңалык булып китә. Теге малайга, бер дә теләмәсәләр дә, сансыныбрак карарга мәҗбүр булалар. Һәм малай үзе дә, шундый сирәк эләгә торган киек кошы белән масаеп, авылның очыннан-очына очынып чапкалый башлый. Карчыга баласы аның кулларын тырнап канга батыра, битләрен, беләкләрен чукый, авызын ачыбрак торса, хәтта күзләрен дә эләктереп алырга чамалый, әмма малай нинди кыен булса да түзә, аягыннан эләккән асыл кошны ычкындырасы килми. Даны ни тора бит аның!

Шәфи Алмаз да Муса белән шул малай төслерәк мавыга иде. Җае килгән саен Муса аның битен-күзен тырнап торса да, аның наданлыгыннан һәм юкҗанлылыгыннан ачы итеп көлсә дә, Шәфи һаман ишетмәмешкә салыша, елмайган була, Мусага карата дуслык һәм яхшылык күрсәткән була. Чөнки аның кул өстендә шундый асыл кошның басып торуы — үзе бер горурлык бит!

Теге вакытта министр алдында сөйләшкәнчә, Шәфи аны Идел-Урал комитетының мәдәни агарту бүлегенә җайлы гына эшкә куйды. Муса теләсә кайда чыгып йөри ала, аның эше кәнсәләр сәгатьләре белән бәйләнмәгән, ул легиондагы мәдәни агарту, пропаганда һәм сәнгать-музыка эшләрен юлга куеп җибәрергә, алар белән житәкчелек итәргә тиеш. Шәфи аны, үтенүе буенча, хәрби форма белән дә бәйләмәде. Муса баштан-аяк цивильный киеменнән — тройка костюм, туфли, галстук һәм эшләпәдән йөри башлады. Дөрес, Шәфи аны үз акчасына киендермәде киендерүен, аны немецлар пакгаузыннан киендереп чыгардылар, әмма ләкин, Гаптрахман абзасы тырышмаса, хәрби әсирдән цивильныйга күчә алыр идемени ул? Кечкенә буйлы шагыйрьнең, кыргый тай шикелле, һаман тибенгәләп торуын да бик яхшы аңлый Шәфи — ул әле кулга ияләнмәгән, баш бирәсе килми, бәльшәвик шаукымы чыгып бетмәгән. Тора-бара һәммәсе дә рәтләнер! Бүген әле сугыш дигәнең Сталинградта, Төньяк Кавказда бара. Ә ярты елдан кай тирәдә булыр ул? Әгәр немес абзаңнар Казаныңны таптап узып, Кәтринбур тирәләрендә сугыша башласалар? — ул чагында Мусаң да, башкаларың да, иң гөнаһсыз куй бәрәннәре шикелле, яшел үләндә күшәп кенә ятырлар. Бәләкәй шагыйрьнең карчыга тырнаклары да мамык пирчәткә кигән кызлар бармагыдай йомшакка әйләнер. Алай гына да түгел, шул ярты ел, бер ел эчендә Шәфи Алмаз хәзрәтләре инде Сөембикә манарасы янындагы таш сарайда президент булып утырыр! Ә Муса Җәлил аның иң кирәкле кешесе — уң җилкәсенә кунаклаган акыл фәрештәсе булыр. Ә бер ел — күпме генә гомер ул, исән кеше өчен хәзер килеп житәчәк...

Шушы куанычлы хыяллары Шәфигә юмартлык бирдеме, әллә хатынына үч итепме, ул, Мусаның үзен генә түгел, ә «комитет» тирәсенә китерелгән байтак кына татар егетләрен дә кунакка чакырды. «Идел-Урал» газетасында эшләргә кушылган Абдулла Алиш белән Карип Ишбулдин да, Шәфинең шәхси секретаре итеп билгеләнгән Гариф

Шабаев та, комитетның экскурсияләр житәкчесе итеп куелган Фоат Булатов та, радио пропагандасына билгеләнгән Әхмәт Симай һәм башкалар да Шәфи Алмаз йортына беренче тапкыр мәжлескә килделәр.

Шәфи йортының өченче катындагы шактый киң кунак залы уртасына озын өстәл буйлап бай табын корылган. Биек-биек хрусталь вазаларга матур итеп тезелгән алма, йөзем, армуд, шәфталы, әфлисун, слива шикелле жимешләр һәм башлары ак кургаш белән төрелгән зур шешәле эчемлекләр табынны мул итеп күрсәтәләр, сый-хөрмәтләрнең барысы да житәрлек икәне күренеп тора. Монда әле жиңүчеләрчә кыланалар иде!

Залда иң элек Карип Ишбулдин күренде.

— Мин килеп тә життем, Гаптрахман абый,— диде ул, хезмәт көткән күзләре белән инәлеп караган килеш. Аннары Мага ханым алдында түбән бөгелеп баш иде дә, аның янга сузылып төшкән ефәк билбавы очыннан, иреннәрен очлайтып, үбеп алды. — Ихлас күңел белән, жантәнем, бар йөрәгем белән тәбрик итәм сезне, шәфкать фәрештәсе Маһия ханым, — дип яңадан сыгылды һәм кәгазь эченнән сыңар тюльпан чәчәге чыгарып бирде. — Бинниһая озын гомерләр, бәхет вә шатлыклар телим!

— Данкешөн, рәхмәт, Гарип әфәнде. Сезнең мондый нәзәкатьле булуыгыз бик күңелле! Онытмам...— Тиз генә иренә борылды: — Шафус, безнең Гарип әфәнде шикелле яхшы егетләр кесә акчасына йөдәмиләрме?..

Карип үзенең исемен бозып әйтүчеләргә бик тиз ачулана иде. Чөнки шул беренче хәрефне алмаштырып әйтү аркасында бөтенләй ямьсез мәгънәле икенче сүз килеп чыга. Бу юлы да аның Шәфи хатынына жен ачулары чыкты. Ләкин шундый матур калфак кигән мөлаем һәм текә холыклы, хужа һәм бай хатын алдында яман төс күрсәтеп буламыни? Ул, әлбәттә, ачуын йотарга мәжбүр булды, һәм Шәфи урынына Мага ханымга тизрәк үзе жавап бирергә ашыкты.

— Юк, юк, хөрмәтле Маһия ханым! Гаптрахман абый бервакытта да безне онытмый. Һәр даим үзенең мәрхәмәтеннән өзми!

Шул чагында ишектән тавыш килде. Шәфи Алмаз үз комитетына алынган солдатлардан икесен йортның тышкы ишекләре төбенә лакей урынына бастырган иде. Шуларның берсе кереп:

— Дәү кунаклар килде! — дип кычкырды. Бар да шул якка ташландылар. Иң элек ике кеше, зур катыргы тартмага салынган ниндидер авыр нәрсәне, тышыннан уралган ефәк тасмаларның чәчәкле бантын бозмаска теләгәндәй, иплән кенә күтәреп эчкә кертте. Аннары зал ишегеннән озын буйлы, соры каракульдән тегелгән немецчә кепкалы, завод хужаларыча яки циркта киек өйрәтүчеләрчә жыйнак, тыгыз киемле, сыек күк күзле кеше белән туп атыдай мәһабәт юан һәм сап-сары чәчле, ләкин бик матур алсу йөзле немка килеп керде. Мага ханымның бер секундка көнчелеге кабарып, гәүдәсенә салкын су сиптергәндәй булды. «Шушы икән инде миңа караганда кадерле хайван!..» Ләкин ул үзен шунда ук кулга алды һәм, битенә киң елмаю элеп, аларга кул суздьи:

— А, безнең иске дуслар! Сагындырдыгыз! Хуш киләсез! — Шундый нидалы тавышлар белән кунакларны түргә әйдәде.

Шәфи дә шундый ук ихтирам күрсәтүдә калышмады. Бу кеше, әлбәттә, еллар буе Мага ханымның үзәген өзгән Скандер Яушев иде.

Кайчандыр Троицки, Орски һәм башка калаларда шәп магазиннар тоткан Яушевларны Октябрь давыллары, ерак далалар буйлап «пәри арбасы» үләне шикелле тәгәрәтә торгач, Кытай жирләренә хәтле сөреп китергән. Шунда алар яңадан әүвәлге кәсепләрен торгызып жибәргәннәр. Элек Мәскәү гимназиясен алай-болай бетереп өлгергән Искәндәрне атасы Париж университетына озаткан. Шактый еллар буе университет коридорларын таптап, атасының алтыннары белән диплом асларын

түшәгәч кенә, Искәндәр инженер исеме алып чыккан. Париж тәрбиясе күргән нечкә гадәтле, цивилизацияле инженер, анда эш тапмагач, вак шпионлыкка ялланып, еш кына Германия шәһәрләрен һәм Берлинны таптый башлый. Шул чакларда Мага ханым белән флирт уйнаулары да бик күңелле була. Әмма Яушев, айнык башлы кеше булганлыктан, корыган курайга кунып, тиккә сайрау белән генә канәгатьләнми: Германиядә тиешле элемтәләр табып, Парижда җыйган информацияләрен Берлинда, ә Берлиннан элэктергәнен Парижга илтеп сата һәм шул көннәрдә инде нәфислекне нечкә сизүче мусье Скандер шактый бай мөлкәтле һәм, мәхәббәт мәйданы буларак, сөйкемле бәдәннәре дә ярыйсы ук мул булган мәһабәт фрау Мартага отышлы гына рәвештә өйләнеп тә куя. Дейчлянд гражданины булып китә, тора-бара Гитлер партиясенә дә язылып ала. Бу хәтле зур ышанычларга кергәннән соң хатынының Познань шәһәрендәге радиоприборлар заводына тулы хуҗа булып киту мусье Скандер өчен артык кыен эш булмый. Нечкә цивилизацияле татар эмигранты әнә шулай фашист фабрикантына әйләнә...

Ул вакытта Шәфи Алмаз, Яушевның бу уңышларына кызыгып, көнчелектән шартлар хәлгә җитеп йөргән иде. «Ничек соң мин шундый мөмкинлекләрне күрми калам?» — дип өзгәләнгән иде ул. Әмма ходай аны да онытмаган икән: тагын да мулрак итеп үзенә бирде. Ул хәзер Яушев шикелле заводчыларга бик тыныч күз белән өстән карый ала. Чөнки ул легион хуҗасы, алла кушса, президент буласы кеше! Шулай булгач, Шәфинең аңа ялынасы юк, ә Искәндәр ишеләрнең Шәфи абзаларына ялынычы тизрәк төшәр, бәлкем. Кайчандыр Маһия тирәсендә чуалганы өчен эчкә яшерелгән ачуын да менә шул чагында бик ләззәтләнеп кайтарырга мөмкин булыр! Ә хәзер исә, өлкән кешеләргә хас галиҗанлык белән югартын гына елмаеп кабул иткән бул үзләрен. Сизеп торсын, дуңгыз, кем табынында утыруын!

Шәфи аларны табынның түренә урнаштырды. Чибәр йөзле, мәһабәт гәүдәле фрау Мартага киңрәк һәм ныграк кресло куйдырды, аның белән ул аеруча ягымлы һәм хөрмәтчән булырга, илтифат күрсәтергә тырышты. Ә шул арада Мага ханым үзенең күптән күрмәгән Скандерыннан күзләрен ала алмый иде. Аның башкаларга сиздерми генә сирпелгән карашында уйнашчыл сагыну да, азгын дәрт кайнавы да һәм Скандерның ташлавы, онытуы өчен көйдергеч үпкә чаткылары да күренә иде. О, ул аны биетер әле! Җае гына туры килсен — кочагында килеш чеметә-чеметә җанын алыр!

Ишектә шау-гөр килгән кунаклар төркеме күренде. Муса, Алиш, Фоат, Гариф, Симай һәм башкалар, баш иемнәрен салып, залга уздылар да тутый коштай киенгән Мага ханымны тәбрик иттеләр. Алар хәзер ике дөнья кешесе булып, ике төрле уен уйнап яшәргә тиешләр иде. Шуңар күрә Алмаз әфәнденең үзе һәм кунаклары белән дә бик лояль төстә күрешеп чыктылар. Күрсәтелгән урыннарга утыру белән Муса мандолин тартып алды. Дөрес, залда кызыл агачтан эшләнгән кыйбатлы рояль дә бар иде. Ләкин аның капкачында бәләкәй сандык бикли торган ак йозак күргәч, байларны борчыйсы килмәде. Мандолинның кылларын чирткәләп, колакларын боргалап көйләде дә «Телеграм баганасы»н уйнап җибәрде. Башкалар аңа кушылып, калын тавыш белән җырлый башладылар. Бу көй сугыш алдыннан гына шаулап барган «Ташкыннар» драмасыннан солдат хатыны Гайнавал җыры булса да, фронт кешеләре аны үзләренә хас ир җыры шикелле итеп, яратып җырлыйлар иде:

«...Күз керфекләрем талганчы-ы-ы
Карыйсым калган икән...»

Муса кулындагы кылларның оста сызылып һәм ерак-еракларга китеп югалгандай сузылып, тирән бер моң белән тибрәнүе егетләрнең күңе-

лен әллә кайларга алып китте. Алар, вагон тәрәзәләреннән баш сузып, туган җир белән хушлаша-хушлаша фронтка киләләр. Бетмәс чакрымнарга киткән телеграм баганалары берәм-берәм артка йөгерәләр. Башларындагы әллә ничә рәт сузылган чыбыклар, шушы мандолин кылларын хәтерләткәндәй, моңсу гына зыңлап калалар. Аларның ниндидер үзләренә бер авыр хәсрәтле көйләре бар. Ә чыбыклар артындагы еракта, хәтфәдәй яшел яланнар уртасыннан назлы гына тулганып, соклангыч матур тугайлар ясап аккан инешләрнең шаян кызлар кулы белән юри борма-сырмаландырып җәелгән буй киндер шикелле кояшта балкып ятулары мәңге онытылмас булып күңелләргә уелган... Эх, кайда соң хәзер ул гүзәл җырлар! Тагын бер генә тапкыр шул газиз туган якларны күрү насыйп булырмы аларга?.. Уйлар һәм кичерешләр бергә кушылып, һаман җыр булып агыла:

«...Сагынасыңмы дип сорыйла-а-ар,
Сагынмаган кая ул...»

Әйе, сагынмаган кая ул! Туган аналарның, җан сөйгәннәрнең, күз нурыдай балаларның якты һәм зарыккан чырайлары бер генә минутка да күз алдыннан китми. Шуларны бер генә күрсәң, бер генә кочсаң, бер генә үпсәң, бер генә сөйсәң иде! Аннары инде үлсәң дә үкенмәс идең!..

Композиторның халык моңнарына нык бәйләнгән бу көчле көе хәтта акча копилкасы шикелле гипс йөрәкле Шәфи Алмазга да тәэсир итте булса кирәк: «Һай, бу көегез, сабый чакларны искә төшерде...» — дип, яулыгы белән керфек очларыннан нәрсәдер селкеп алгандай итенде.

Муса, ирекле аккордларга күчеп, Алишка таба башын борды да:

— Җитәр ахрысы, — дип пышылдады.

— Уйна инде, Муса җаным, — диде Алиш. — Күптән тыңлаганым юк иде бу көйне...

— Юк, җитәр, — диде Муса көлемсерәп. — Тимсах [1] яшь коя башлады. Тәме китте... — һәм ул мандолинын диван өстенә каплады. Бу пышылдашуны ишетеп калган Симаев белән Шабаев кычкырып көлеп алдылар.

— Әйе, әйе, — дип өстәде Муса, — әгәр кеше моңланганда тимсах та яшь коя башласа, көт тә тор: ул сине кабып йотарга җыена!

Мәҗлестә була торган шау-шу эчендә Шәфи моны, әлбәттә, ишетмәде. Карип Ишбулдин гына күзләрен елтыратып: «Нәрсә бар? Миңа да әйтеп көлегез әле», — дип елыша башлаган иде.

— Әнә, тәрәзәгә песнәкләр кунган, — диде Фоат.

Карип тәрәзәгә ташланды, ә болар тагын да юанрак тавыш белән кычкырып көлеп җибәрделәр.

Карипнең моңа хәтере калса да, сиздермәскә тырышты.

— Шаяртмагыз, майн һерр! — дигән булды ул, дусларча тел белән. — Без бит әле эчмәгән, айнык баштан шаяру кызык түгел... Әнә Гаптрахман абый тизрәк сыйлый башласа инде, анда бер хәл...

— Карагыз әле, Гарип әфәнде, куегыз әле шул «Гаптрахман абый» дигән сүзегезне! — диде Мага ханым, ачулы тавыш белән. — Сез «Гаптрахман абый» дигән саен, сыерга атланган мужик күз алдыма килә. Ф-фу!

Ишбулдинның йөзенә күкле-яшелле тимгелләр чыкты. «Ык-мык» килде, ни җавап бирергә белмәде. Ә егетләр, өстәл астына таба иелеп, тагын пырхылдашып алдылар. Тик бераздан соң гына Карип мыгырданып куйды:

— Яхшы, әйтмәм... Тик, гафу итеп, минем исемне дә бозмагыз. Мин

[1] Крокодил.

гарип түгел — Карип. Ә гарип — чулак, чатан, күзсез, саңгырау дигән шикелле сүзләр була ул. Ә минем бар җирем дә исән-сау!

Мусаларга тагын да күңеллерәк булып китте, алар кабат рәхәтләнеп көлештеләр. Бу хәл гамьсез, кайгысыз булып күренү өчен дә бик уңай иде.

Мага ханым күзләрен акайтып Карипкә карады. «Әле син шулаймыни, халуй?» дигән төсле ачулы иде ул күзләр.

Күп көттергәннән соң, ниһаять, Фон Менде һәм җирән Унгляубе дә җәмәгатьләре белән парлашып килеп керделәр. Фон Менде үзе, гомер буе китап чәйнәгәнгәме, элеп киптергән чабакка охшаса, хатыны моңсу чырайлы Мәрьям анага охшый иде. Унгляубенең хатыны исә ап-ак арий нәселенең кара буяулысы, тутырган тавык шикелле тук битлесе һәм астыртын гына бурлык итә торган песинеке төсле бәләкәй елтыр күзлесе иде. Аларны инде ишек төбендә көтеп торган Шәфи белән Мага ханым һәм Яушев белән чибәр Марта дәррәү куанычкүрсәтеп каршыладылар.

— Һа, кадерле кунаклар, хуш киләсез, битешә-өн! — дип, кунакларның бай киемнәрен салдырышып, түргә әйдәделәр. Озакламый Унгляубенең көнчыгыш министрлыгында кемдер булып эшләүче ниндидер туганнан тума сеңелесе Матильда белән тагын ике немец кызы килеп керделәр. Боларны Шәфи, егетләргә күңелсез булмасын дип, хатынына әйтми генә дәшкән иде. Киләсе кунаклар шулар белән бетте. Розенберг әфәнде, ниндидер мөһим командировка белән Берлиннан китәсе булганга, килә алмавын белдергән иде. Мага ханымның моңа бик эче янды, чөнки мәҗлес ул теләгән масштабта була алмыйча калды.

Зал шау-шу белән тулды, беренче бокалларга эчемлекләр салынды. Муса аңлавынча, моңарчы политик һәм хәрби темаларга артык катнашмаучан, бары тик телләр галиме булып кына күренүчән профессор Менде кинәт сүз алды. Ул үзенең Мисыр мумиясе төсле кипкән озын гәүдәсе белән аягүрә басты да:

— Хөрмәтле әфәнделәр! — дип кулына бокал күтәрде. — Безнең бу кичәгә бик зур куанычыбыз бар: бүген безнең данлы гаскәрләр Царицын шәһәрен алуны тәмам иткәннәр! Иртәгә Шталинградның җимерек урамнарында немец гаскәрләре җиңү парады ясаячак. Тәбрик итәм сезне! Батырлар өчен күтәрик!

Һәммәсе дә аягүрә бастылар. Рюмка чәкәшүләр яңгырады. Ишбулдин бу вакытта әлеге немец кызлары белән мәшгуль иде, аны-моны уйлап тормастан, немец туташларын кыстый-кыстый, эчеп тә җибәрде. Ләкин калган биш егетнең хәле шактый авыр иде. Мондый атамалы тостлар эчкәндә нишләргә соң? Сталинград китүе өчен ничек эчәргә?!.

Әхмәт Симаев радиопропаганда бүлегендә эшли башлаган иде инде. Аның эше немецчәдән русчага күчерелгән һәртөрле пропаганда материалларын, фронт сводкаларын татарчага тәрҗемә итеп, атнага бернничә тапкыр ана телендә тапшырулар алып бару һәм шул материалларны матрицага сугу, аннары бастырып, көнчыгыш эшчеләре арасында тарату иде. Бу эштә аңа радиотапшыргыч белән генә түгел, радиоалгыч белән дә эш итәргә кирәк була. Һәм ул, бүген иптәшләрен күрәсе булгач, совет информбюросының кичке тапшыруларына колак салып та өлгергән, ләкин мондый ук шомлы хәбәрне очратмаган иде. Шуңар күрә Фон Менде сүзләренә тиз генә чөй кыстырырга ашыкты ул. Бәлки, шулай итә торгач, Сталинградны югалту куанычына эчми дә узып булыр?..

— Ай-һай, профессор әфәнде, сез ашыкмыйсыз микән? — диде Әхмәт, рюмкасын тотып баскан килеш. — Мондый хәлләрдә ялгыш хәбәрләр булуы да бик ихтимал бит. Кайбер командирлар алмаганны да ал-

дык дип күрсәтергә яраталар, чөнки аларның тизрәк орден тагасылары килә...

— Юк, бу инде бәхәссез, — дип өстәде Унгляубе. — Точно.

— Кем белә бит аны?.. — дип җилкәләрен куырды Әхмәт бик ихлас күңелле кеше кыяфәтендә. — Мәсәлән, былтыр Һеббельс әфәнде дә шулай ашыгып хур булды түгелме соң? Ул бит, җиденче ноябрьда шәүкәтле фюрернең шанлы гаскәрләре Мәскәүнең Кызыл Мәйданында парад ясаячак, дип вәгъдә иткән иде. Хәлбуки, мондый куанычлы хәлнең, кызганычка каршы, әле һаман да булганы юк... Менә бит ул ашыгу!..

Бу сүзләр барганда башкалар арасында үзара сөйләшү китте. Бар да диярлек гаҗәпләнү һәм шигәю белән Әхмәткә карыйлар, ә Фон Менде белән Унгляубенең күзләре яшен ташлары кебек елтырый иде. Шушы моменттан файдаланып, Мусалар үз рюмкаларын кире куйдылар, кайсысы ялгыш түгелеп китте, кайсысының эченә ялгыш селедка төште, кайсын икенче савытларга бушаткаладылар. Әхмәт, үзенә юнәлгән утлы карашларны алып ташлау нияте белән, сүзен дәвам иттерде:

— Әллә ни генә булды шул чагында, кадерле әфәнделәр! Бик үкенечле хәл килеп чыкты, — дип пошынды ул. — Мөхтәрәм фюрернең Мәскәүне алуы ул чагында шулкадәр якын ихтималдагы эш иде, бездә инде бу хакта һичбер шик-шөбһә калмаган иде. Һәм шуның белән сугыш бетә дә, без инде өйләребезгә кайтып китәбез дип тора идек. Ни өчен шулай булмады? — һич аңламыйм.

— Русьларның Кыш генераллары комачау итте безгә, — диде Унгляубе. — Әмма быел инде алай булмас, без кыштан курыкмыйбыз хәзер!..

Мусаның күз алдына кинәт кенә Алыпкул бабай килеп басты. «Әйе, әйе, яза гинирал: Сыкы Суыгыч Салкынбайский!..» дип, күз почмакларын шаян җыерчыкландырып, карчыгы алдында көлеп тора иде ул.

Сүз, шулай итеп, әзме-күпме башкага борылды, хәл кадәренчә чөй сугылды һәм биш егет Сталинград китүе өчен эчми калдылар. Муса моны бик яхшы төшенеп алды һәм Әхмәткә дуслык күзләре белән карап, рәхмәтен белдерергә өлгерде.

Мондый куркыныч рәсми тост узып китүгә икенче бер «дәһшәт» килеп туды. Мага ханымның күзләрендә яшен утлары уйный иде. Ул урыныннан кузгалды да, «ах-ух» килеп еламсырап, истерикага ташланды.

— Сез барыгыз да солдафоннар! — дип кычкырды ул. — Бүген минем туган көнем, ә сез беренче тостыгызны ук шул солдатларыгыз өчен эчәсез! Ах, майн Гот! — Ханым үкси-үкси икенче бүлмәгә үк кереп китте. Бар да аның артыннан ташландылар. Чынлап та нинди зур хата, хөрмәтле даманы шампанский белән тәбрикләп, кулын үбәргә бөтенләй оныткannar бит! Чын күңелдән үкенеп гафу үтенделәр, аны табынга чакыру өчен ялыну-ялварулар китте, егетләр өчен мәзәк ыгы-зыгы башланды. Ул Ишбулдин инде, «Гаптрахман абый, Гаптрахман абый!» дип, утлы табага баскан мәчедәй йөгереп йөри иде. Моңарчы җиңүче кыяфәтендә, мыек астыннан гына көлеп утырган Симаев шул арада пышылдап өлгерде.

— Мин тыңладым. Корыч кала китмәгән: Әйдәгез, Корыч каланың корычлыгы өчен!..

Ләкин алар рюмкаларын күтәрүгә, Шәфинең тутый кошын теге яктан җитәкләп алып чыктылар. Һәркем борчылган, һәркем аны тынычландырырга тырыша иде.

— Без инде бокалларны һәм күзләрне мөлдерәтеп, әллә кайчан сезне көтеп торабыз, хөрмәтле Мага ханым! — диде Муса һәм иптәшләренә күз кысты. — Озак яшәгез, бәхетле булыгыз. Корычтай ныклык сез-

гә! — Ул эчеп җибәрде. Аның артыннан Алиш, Фоат, Симай, Гариф күтәрде. Башкалар да аларга кушылып өлгерделәр.

— Гали үз эшендә, Вәли үз эшендә, — дип елмайды Фоат, кулына әфлисун телеме тотып.

— Шулай булырга да тиеш, — дип куйды Шабаев. — «Не зевай!» — дигән изгеләр китабында.

Тутый кошның кәҗәләнеп алуы да ярап куйды, — куркыныч төс ала башлаган рәсми тостлар башкача кабатланмады, хәзер хатын-кызларга, аларның тәти күзләренә багышлап эчәләр иде инде. Мусалар өчен дә әйбәт булды бу. Чөнки гитлерчылар өчен күтәрүгә караганда, хатын-кызларның күлмәк итәкләре яки яңа башмаклары өчен эчү мең мәртәбә җиңелрәк ич. Шуңар күрә Муса: «Безнең милли калфагыбыз Европа үзәгенә дә килеп җиткән!..» дигән темага бик кызыклы гына сүз тотып, Маһия ханымның саф энҗедән генә чигелгән бик кыйбатлы калфагы өчен тост тәкъдим итте. Кунаклар һич карусыз эчеп җибәргәч, хуҗабикәнең бик кәефе килде. Караңгы чырае ачылып китеп, кунакларны үзе әзерләгән милли ашлар белән сыйлый башлады. Дөрес, Фон Менденең әлеге Мәрьям анасы бламажины, «бламанже» дигән булып, француз ашы итеп күрсәтергә маташкан иде маташуын, ләкин Мага ханым аңа бик җәелергә ирек бирмәде.

— Юкны сөйлисез, хөрмәтле фрау, — диде ул. — Бу безнең атабабадан, җитмеш буыннан килгән үз ашыбыз. Дас ист райн татаришес герихт! [1].

Шуннан соң бәхәс куермады.

Моңарчы тостларны төгәл эчү һәм ашау ягын төгәл җиренә җиткерүдә дәшми-тынмый намус белән эш иткән Искәндәр Яушев нәселдән килгән йола буенча сәер генә бер кикереп куйды да сүз башлады.

— Һөрмәтле месье,— диде ул Шәфи Алмаз белән Унгляубегә мөрәҗәгать итеп.—Минем сезгә киңәшем һәм үтенечем бар. Мәгълүм ки, минем Познаньдагы завод — хәрби фронт өчен мөһим әйберләр эшләп чыгара. Анда ышанычлы сакчылар кирәк. Поляклар бары да бандитлар, бер тиенлек ышаныч юк! Немеслэрдән куеп булмый — фюрергә солдатлар кирәк. Шуңа күрә, Шәфи әфәнде, сез миңа бик һәйбәт егетләр бирегез. Мин үз татарларыбыздан оештырмакчы булам завод сакчылыгын...

Шәфи Алмаз мәгънәле генә итеп Унгляубегә карап алды: «Бу үтенеч ярыйсы күренә, уңышлы коммерция ясап алырга мөмкин!..» дигән кебек иде ул. Ә чуар адвокат гомумән хәзер Шәфине бер караштан ук аңларга, хәтта Польшага-фәләнгә йөргәндә, Шәфи шикелле үк, чемодан эченнән сәүдә итәргә дә өйрәнеп килә иде. Шунлыктан, ул хәтта Шәфигә хәтле үк җавап бирә башлады:

— Бу идея начар түгел, майн һерр. Уйлашып карарга ярый...

— Әйе шул, — диде Шәфи дә, зондерфюрергә каршы килмичә. — Әгәр безнең кешеләребез тиешенчә тәэмин ителсә... әгәр «Идел-Урал» кассасына тиешле әҗере кертелсә...

Мусаның ачуы килде. Нindидер бер реплика кыстырырга теләде. Башына да бераз киткән иде. Шуңар күрә тагын да кызмачарак төскә кереп:

— Әгәр ул кешеләр, жандарм формасы киеп, завод полицае булырга ризалык бирсәләр?..— дип ялгап куйды ул шундый ук тавыш белән.

Бар да гаҗәпләнеп аңа карадылар.

— Анысын синнән сорамыйлар, егет! — диде Искәндәр әфәнде, тупас кына итеп. Бу җавап Мусаны тагын да үчектерә төште.

— Нигә сорамасыннар? — дип көлемсери төште ул.— Әсир — ишәк түгелдер ич?.. Алай дип уйлаучы — үзе тинтәк булыр иде!..

[1] Бу саф татар ашы.

— Телеңне тыя төш, малай! Тартып өзмәсеннәр! — диде Яушев тагын да төксерәк тавыш белән.

— Һи-и, — дип елмайды Муса беркатлы кешеләрчә генә, — юкка хафаланасыз, әфәндем! Фюрернең тимер капкалы Германиясендә кайбер француз шымчылары да бик рәхәт кенә гомер сөрә дип сөйләшәләр әле, хәтта аның партиясендә дә торалар, имеш. Шулай булгач...

Искәндәр Яушев, кызарып-бүртенеп, сикереп торды:

— Ах, млекосос! Силягай! Миссине... большевик! — дип кычкырды ул ярсып. Ләкин аның, оясыз күке шикелле, яшьтән үк чит җирләрдә үскәнлектән, русчасы да, татарчасы да бик зәгыйфь иде. Шуңар күрә вакыйганың иң җитди чагында гына егетләр аның чатак сүзләреннән көлешеп куйдылар. Муса да һич исе китмәгән рәвештә генә:

— Мин бит сезнең хакта әйтмәдем, әфәндем...— дип өстәде.

Бу сүзне Яушев мыскыллы киная дип аңлау сәбәпле (һәм Муса әйткәннең дөресе дә шулай иде) яңадан кыза башлады, әмма сөйкемле Мага ханым белән Шәфинең бу күңелсезлекне зурга җибәрәсе килмәде — немецлар алдында оят булачак бит — хөрмәтле завод хуҗасын тынычландырырга тотындылар. Хәтта Мага ханым җазибәле караш белән үтә ягымлы булырга тырышып:

— Скандерик!..— дип эндәште аңа һәм яңагыннан сыйпап куйды. Аннары Муса өстенә шелтә яуды; аннары кызларга «уйнарга-көләргә-җырларга» команда бирелде. Бая гына Искәндәр әфәнде алып килгән он лары хәтле зур радиоланы корып җибәрделәр. Күңелләрне чеметтерә торган пластинкалар әйләнә башлады. Иң башлап Ишбулдин бер немка белән залда бөтерелергә тотынды. Гариф белән Фоат та, үзләренә пар табып, алар артыннан төште. Инде күптәннән бирле читтән генә күз уйнатып утырган Матильда үткләгән озын керфекләрен түбән сузып, ялгыз кешеләрчә моңлы һәм мөлаем генә елмайгандай итеп, Муса янына килде. Аның бокалына һәм үзенекенә шампанский тутырды да: «Сезнең үткен телегез, канатлы сүзегез өчен, майн дихтер!» [1] дип, чәкәшергә тәкъдим итте. Аның кара буяулы кайма эчендәге сыек зәңгәр зур күзләре шундый итеп карый, үтә күренмәле капрон челтәр белән өртелгән тулы күкрәкләре шундый еш һәм дәртле тибрәнә, аккошныкыдай ап-ак муеннары шундый сөйкемле борылгалый, сүзләре шундый кайнар сулыш белән пышылдап кына, серле булып кына чыга, гүяки бу кыланышлар һәммәсе дә: «Мин сезне генә яратам, мин сезнең өчен генә!» дия иде. Муса Матильданың болай якын итүен төшенеп җитмәде. Ни өчен соң әле Унгляубе әфәнденең бу ерак сеңелесе шулай аңа бик игътибарлы? Бик гаҗәп хәл!.. Муса моны тирәнтенрәк өйрәнергә булды. Аның сүзләренә артык каршы килмичә, көлгәләп кенә утырды. Хәтта Матильда тәкъдиме буенча алар бер фокстрот та биеп килделәр. Кыз аңа мөмкин кадәр тыгызрак елышырга, тән кайнарлыгын ирештерергә, Муса күңеленә вәсвәсә салырга тырышты. Беренче очрашуда ук мондый кыюлык күрсәткән кыз Мусаны сагайта төште. Бәлки, немец кызлары гомумән шулай тәвәккәл буладыр?.. Бәлки... яратадыр?.. Ләкин аның башы әйләнмичә калды. Ниндидер эчке тавыш: «Бомба! Шартламасын!» дигән кебек тоелды.

Тәнәфес гөрләп дәвам итә иде. Табын янында беркем дә калмаган. Кайсылары киң залга чәчелеп биилəр. Кайсылары Шәфинең бай квартирасының төрле бүлмәләренә югалганнар. Һәр бүлмәдә кыйммәтле мебельләр, кечкенә түгәрәк өстәлдә эчемлекләр тора. Кешеләр, шул тирәгә төркемләшеп, әңгәмә коралар, эш йөртәләр. Тик Муса белән Матильда гына табынның бер башында утырган килеш бер-берен сынау көрәше алып баралар иде. Нәкъ шул чакта Карип Ишбулдинның:

[1] Минем шагыйрем.

— Гаптрахман абый, Гаптрахман абый! Карагыз әле! — дип ярым тавыш белән пышылдаганы ишетелде. Кешеләр шул якка борылдылар. Шәфи үзе дә ишеге яртылаш ачык торган зәңгәр бүлмәгә юнәлде, башкалар да ни өчендер бик тиз шулай таба якынайдылар. Әмма Шәфи шунда ук кире борылды да, ишекне ябып, читкә китәргә һәм кешеләрне дә үз артыннан ияртергә теләде. Ул ара да булмады, әллә каян гына килеп чыккан фрау Марта, туп атыдай пошкыра-пошкыра, ишеккә ташланды. Ишек киерелеп ачылганда, хәтта читтән генә карап торган Муса да Искәндәр Яушевның Мага кочагына шундый нык һәм котылгысыз булып кысылганын күреп алды. Ажгырып барып кергән фрау Марта белән Мага ханым арасында һәр обыватель өендә була торган гадәти җанҗал башланып китте. Француз тәрбиясе күргән Яушев, шул авыктан файдаланып, тиз генә халык арасыннан чыгып сызды. Аның элегант мыеклары шактый чуалган, йөзендә кызыл бизәкләр күренә һәм ул үзе дә, барыннан да бигрәк, шул тәртипсез күренешләр өчен көенә кебек иде. Мага ханым таянычсыз-нисез бер үзе калды. Бу фил хәтле немканың һөҗүменә каршы торырга да, бу рисвайлыкны күтәрергә дә бер ялгызы көч табарга тиеш иде ул. Кем уйлаган соң, кем уйлаган? Озак вакытлар күрешә алмаганга бик сагынган иде шул ул. Үпкә сүзләрен әйтеп бер әрлисе, сөясе һәм ичмаса бер онытылып үбәсе килде. Ләкин саклыгы җитмәде, шампанский сөремнәре аяктан екты ахры — хурлыкка калды...

Шәфи, яңадан барып, бүлмә ишеген япты һәм Карипне ашардай күз белән карап: «Ахмак!» дип кычкырды.

Муса үз иптәшләре белән бер тирәдәрәк тора иде.

— Әйдәгез, егетләр, сыздык! Монда балык базары башланды хәзер,— диде ул шыпырт кына. Һәм алар ыгы-зыгы вакытында, берәү күзенә дә чалынмастан, чыгып тайдылар.

Мага ханым кинәт кенә бик һәйбәт бер хәйлә тапты һәм, тырнакларын кабарткан фрау Мартага карап, елмая да башлады:

— Хөрмәтле кунагым, фрау Марта! — дип ялварды ул.— Ә сез юкка гына кызасыз. Мин бит алып килгән зур бүләгегез өчен һерр Скандергә бары тик рәхмәт кенә әйтә идем, аның артыннан шулай ук сезне дә кочып, рәхмәт белән үпмәкче идем. Менә кулымда шанпански бокалы да бар иде бит.— Һәм кулындагы хрусталь бокалны өскә күтәреп, уйнатып куйды.

Ирләр бу саламның тотынырга яхшы икәнен шундук сизеп алдылар.

— Чыннан да Мага ханым минем янга шул сүзләрне әйтеп килде,— дип куйды каяндыр пәйда булган Яушев.

— Чөнки мин җибәргән идем аны,— диде Шәфи,— бик зур итеп рәхмәт әйтергә кушып!

Шулай бер-берен йолдый торгач, бар да рәтләнде тагы. Бу күңелсезлекнең төзәлүенә хәтта сөенеп тә куйдылар һәм мәҗлес элекке шәплеге белән дәвам итте.

## ӨЧЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Иң авыр көннәр иде. Немецлар Сталинградны тулысынча алып, Идел юлын кисүләре, Кубань һәм Төньяк Кавказны узып китүләре, кызылларның каршылык көче бөтенләй җимерелүе турында рәсми рәвештә игълан иттеләр. Газеталары исә совет гаскәрләренең әле тегендә, әле монда тар-мар ителүе хакында язмалар белән тулы иде. Милли корал өстенлеген бик ярата торган немецлар өчен баш әйләндергеч ямьле бәйрәм иде бу көннәр. Ирексездән немец кул астында яшәүнең тәмен болай да җитәрлек татыган кешеләр башларын аска иделәр. Һәркемдә рух төшенкелеге, эчке изелү көчәя барды. Мусаның да күңеле эленке-салынкырак

булып китте. Әмма шулай да оешманы туплап җиткерергә, яңа кешеләр тартып, киң колач белән эшкә керешергә кирәк иде. Фронт хәлләре ничек кенә булмасын, барыбер көрәшми булмаячак... Бер кичне ул үзенә фикердәш була башлаган Рәфикъ Гыйльфанны иярттe дә Исрафилев дигән инженерны эзләп китте. Бу кеше белән Муса Вустрау лагеренда танышып, берничә тапкырлар сөйләшеп йөрде. Ул чагында аларның фикерләре дә килешер сыман, дуслык теле дә табылыр төсле күренгән иде. Ләкин Исрафилев Вустрауда артык озак юанмады. Шәфи Алмаз йомышларын үтәп беркадәр вакыт йөрде дә Хименс заводына эшкә керде һәм шул якка күчеп тә китте. Муса белән Рәфикъ аны Берлин читендәге Райникендорфта булган бер йортның кугәрчен оясыдай бәләкәй чарлагыннан эзләп таптылар. Сөйләве читен булган сүз авырлык белән генә башланып китте:

— Нихәл соң, Әхтәм? — диде Муса.— Син, ахры, җайлы урнаштың? Күзгә-башка күренмисең...

— Ерак торам бит.

— Тавыш-тының да чыкмый... Шушылай тыныч кына яшәргә исәп мәллә?

— Нигә, тыныч кына яшәү — начар түгел бит! — Исрафилев ниндидер мәгънәле караш белән Рәфикъ Гыйльфан өстенә күз ташлады. Аның башындагы биек түбәле немец картузы да, астыннан чигәләренә бүселеп торган чылгый чәчләре дә, өстендәге унтер-офицер кителе дә Исрафилевкә ошап бетмәде булса кирәк, ул кырыс күзләрен ялт кына Мусага таба борды да:

— Шалтай-балтай йөргәнче! — дип өстәде.

Рәфикъның кугәргән йөзенә бала йоннары кабарып чыкты, күзләренә усал ут кабынды, ул хәзер үк кутәрелеп бәрелергә тора иде, тик Муса, эшне алайга җибәрәсе килмичә, үзе сүз башлады.

— Ни әйтергә теләвең аңлашыла, Әхтәм,— диде ул, тату тавыш белән.— Әмма кеше формага карап кына эш йөртсә, ялгышуы да мөмкин. Чөнки кайчакларда форма белән эчтәлек бик нык аерылучан да була икән. Өстән караганда бөтенләй ят бер форма астында бөтенләй икенче төрле эчтәлек яшеренә. Һәм алар, тирән конфликтка кереп булса да, янәшә яшәргә мәҗбүр булалар. Ниһаять, конфликт үзенең югары дәрәҗәсенә җиткәч, әлеге шөкәтсез форманы җимереп ташлый...

— Рәхмәт, Муса туган, онтыла башлаган политграмота сабакларын искә төшердең. Вузда чакта күп баш ваткан идек,— дип елмайды Әхтәм ирония белән.

— Юк, Исрафилев, без сиңа саф күңел белән килгән идек,— диде Муса, хәтере калыбрак.— Син минем немец киендергән бу тәти костюмнарыма карап кына фикер йөртмә. Фронт разведчикларында маскхалат дигән нәрсә була. Солдатны табигать төсләре белән бер итә дә куя... Әз без җан аямас мөһим эшләр башлап йөри идек... Син безгә бик кирәк буласы идең. Син бит төгәл приборлар заводында эшлисең... Хәер, эш приборда гынамыни? Син үзең кирәк идең безгә, үзең кадерле!

— Ә нишләмәкче буласыз соң сез?..

— Эшләр идек әле... Хәлләрнең нинди авыр икәнен сиңа сөйләп торасы юк. Дошманның бүрек чөеп бәйрәм итүен үзең дә күрәсеңдер... Шушындый чакта ничек түзеп тормак кирәк?..

— Эх, Муса туган! — диде Исрафилев, кинәт үзгәреп.—Эшләр синең белән минем булышлыктан узган бит! Алай булгач, ачык сөйләшик. Мәсәлән, бик каты чир эләгеп, кешене түшәккә ега. Кешенең организмы ул чир белән көн-төн көрәшә, ә чир аның саен һөҗүмен көчәйтә. Кешегә докторлар дарулар биреп карыйлар. Ләкин булмый, чир, ниһаять, организмның каршылык көчен тәмам җиңә; кеше канындагы шариклар да, йөрәк тә, дарулар да һични эшли алмыйлар. Кешенең тәне әкренләп үлә бара. Бу хәлне күргәч, инде теге докторлар да катнашудан туктыйлар

Аның үлемен җиңеләйтү чарасын гына күрәләр... Хәлләр менә шундыйрак түгелме соң хәзер? Мин моңарчы, авыруның егәрләнеп китеп, аякка басуына ышана идем әле. Күңелдә шундый якты бер өмет бар иде. Ә хәзер?.. Немец инде Иделнең түбән агымын аркылы кискән, илнең иң зур кан тамырын өзгән, алай гына да түгел, Кавказ тауларына хәтле барып житкән... Шуннан соң нәрсә көтәсең?.. Юк инде, юк... Авыруның мәңгегә күзен йомуы көннәр, сәгатьләр эше генә хәзер. Ә син әйткән «мөһим эш» шул үлекнең маңгаена салкын сулы чүпрәк кую гына булачак. Андый компресстан ни файда?..

Муса аңа озак итеп, сүзсез карап торды. Күе кара чәчен артка тараган, тар маңгаен каплый язган зур, кара мөгез тирәчле күзлек кигән, борын яфраклары үтә күренердәй юка тиреле бу кеше ничектер вак инешләрдә яши торган олы күзле «ташбаш»камы, әллә ватаны Көньяк Азия булган «күзлекле маймыл»гамы охшап киткәндәй булды. Бу кешегә сүз кайтару, бәхәс кузгату кирәк түгеллеге дә күренде, чөнки ул көчсез һәм кызганыч иде. Аңа таяну мөмкин булыр дип, күрәсең, Муса ялгышрак уйлаган. Андый түгел икән... Саз каены булып чыкты ул... Кешеләрне тирәнтенрәк белү җитми икән әле. Сабак булсын бу...

Ниһаять, урыныннан кузгалгач, тагын бер тапкыр уйлап алды: «Туган ил — түшәк өстендә яткан үлек. Аның маңгаена юеш чүпрәк куеп маташуның файдасы юк хәзер...» Кирәк бит, ә?

— Ярый, Исрафилев, бигайбә! — диде Муса. Без ялгышрак килгәнбез. Монда сөйләшкән — монда калсын. Без сине белмибез, син безне белмисең! Килештекме?

— Ярар килештек,— дип җавап бирде Әхтәм, үзе дә кузгалып.— Тыныч булыгыз, мин кешеләрне сатмыйм...— Һәм, ишек ачарга узганда, баягы төсле үк күзләре белән тагын да Рәфикъка карап куйды: «Миннән курыкканчы, менә моннан курык син!» — ди төсле иде ул.

Муса тышка атлады, аның артыннан чыккан Рәфикъ олы күзләренең агын күрсәтеп артка борылды да яндыргыч нәфрәтле пышылдавын җилкә аша гына тегеңә ыргытып калдырды:

— Ә шулай да сволочь син! Капитулянт! Сатуың да бик ихтимал!

Исрафилев, чамадан тыш җәберсенеп һәм гарьләнеп, тешләрен шыкырдатып кысты. Ниндидер үтергеч һәм бу яланы юкка чыгаргыч сүз белән кычкырасы килде аның. Ләкин кунаклар тар караңгы баскычтан төшеп тә югалдылар инде. Ә коридорда кычкырып, йөрәк яраңны ачарга ярамый иде...

Муса җимерек кәеф белән бүлмәсенә кайтып керде, аның артыннан Рәфикъ та эчкә узды һәм, янган күзләре белән тирәне айкап, зар кыларга тотынды. Муса Шәфи Алмаз йортыннан өч бүлмәле квартир алып яшәүче фрау Вальдесның бер бүлмәсендә тора иде. Хәер, үзе генә түгел, монда алар Абдулла Алиш һәм Фәтхи Баянов дигән кеше белән өчәүләп яшиләр. Фрау Вальдесның кайчандыр урта кул чиновник ире һәм рейхсверда ике малае булып, хәлле генә кешеләрдән саналганнар. Хәзер исә ире үлгән, ә малайлары сугышта...

Рәфикъ ярсый башлау белән, Муса фрау Вальдес ишегенә колак салды. Ул яктан куркыныч бәрлыгы сизелми, хуҗа карчыкның бары тик аргы бүлмәсендәге кушеткада гырлап йоклавы гына ишетелә иде. Алиш белән Фәтхи Баянов та өйдә юк, газета чыгаралардыр, күрәсең.

— Шулай да син бик ярсымыйчарак сөйлә,— диде Муса,— фрау йокысы — эт йокысы. Егетләрнең кайтып керүе дә ихтимал.

— Ярсымыйчарак, дисең син! Мөмкинме соң ул! — диде Рәфикъ, шытырдатып кыскан йодрыгын күкрәк өстендә калтыратып.— Күрдең бит, күрдең! Ышанмыйлар безгә! Күзләре белән нинди итеп сөзде мине? Әйтерсең, мин ата сатлык!—Һәм ул башындагы шәп картузын идәнгә атып бәрде дә өстәлгә капланып үкси башлады.— Каһәр суксын моны кигән бу башны! Каһәр суксын!..— Шулай бер тын өзгәләнеп алгач, яшь бе-

ләп чыланган йөзен өстәлдән күтәрде.— Күрә торып монда да ышанмыйлар икән инде, еракта калган илдә ничек ышансыннар безгә. Күрмәгән-нитмәгән көйгә, безнең коры сүзгәме? Һи-и, анда кайткач герой булып сөйләүчеләр күпме табылачак! Аларның барысына да ышана китсәң!.. Хәер, анда кайту да бит әле икеле безгә. Кем кыяфәтендә кайтасың? Әгәр болар, чынлап та, җиңеп чыксалар, сарык булып сөрелергә генә кала безнең башларга!.. Юк, Муса абый, миңа таянма син. Булмый миннән. Тегендә, Сталинград якларында, ил, бәлки, чыннан да актык сулышларын аладыр, ә без монда вак-төяк пропаганда белән маташыйк, имеш. Че-пу-ха!

Муса аптырап калды. Рәфикъның Исрафилевкә ярсуы табигый иде, әмма аның ышанмавына карап кире нәтиҗә ясавы, әле генә ялкынланып йөргән егетнең чигенә башлавы һич аңлашылмый иде. Каян килә соң шушындый сыек кешеләр?.. Шулай да ул үзен ярсытмаска тырышты.

— Нишләр идең соң? — дип сорады тыныч кына.

— Утка ташлана торган чак хәзер. Иленнең актык сулышында актык солдат булып үләргә!

— Матур сүзләр,— диде Муса.— Тик эшләве генә мөмкин түгел. Моннан торып ни кырасың?

— Җаен табармын. Шәфи мине гәзит редакторы итәм дип йөри. Итсен. Ризалык бирәм. Аннары редакциясен күккә күтәрәм дә качам! Үлсәң дә хәзер, бомба кебек шартлап үләргә кирәк!

Муса елмайды һәм бу юлы да кызмады, Исрафилев белән бәхәсләшмәгән күк, Рәфикъ белән дә сүз көрәштермәде. Алар китергән сәбәпләрне пыран-заран туздырып ташларлык ялкынлы сүзләре булса да, тыелды. Чөнки аның үзенә дә бик кыен һәм, таш баскандай, авыр иде. Башка иптәшләрендә дә шушындый ук эчке җимерелеш туса, нишләргә? Ул чагында бу изге максатның күктә генә асылынып калу куркынычы бик зур. Фронтлардагы хәлләр, чынлап та, шулай чамадан тыш дәһшәтлеме соң? Чынлап та, без шулай һәлакәт түшәгендәме?..

Ул битараф салкын кан белән фикер йөртте. Дөрес, дошман кул астында һәм аның да ерак эчке тылында калган кешегә фронттагы хәлләрнең ни дәрәҗәдә куркынычлыгын ачык белү һич кенә дә мөмкин түгел. Ә немецлар һаман җиңү турында, олы Россиянең, аннан-моннан гына өелгән олы салам эскерте шикелле, ишелеп төшүе турында кычкыралар. Мондый шартларда саташмас җиреңнән саташырсың! Исрафилевнең шундый сүзләр белән чарлагына посуы гаҗәп тә түгел. Көрәш күрмәгән кеше булса кирәк. Ләкин менә Рәфикъ та тиз чыгымчылый торган коры бунтарь гына икән. Аны яшерен көрәшнең романтик ягы гына кызыктыра, күрәсең. Авырлыгын бил сөягенә салганда — шырт сынуы бик ихтимал. Тик эш, кызганычка каршы, аңарда гына түгел. Алиш белән Фоатның да, Гариф белән Әхмәтнең дә күңелләре салпы күренә. Кыйналудан канатлары салынып төшкән каз бәпкәләредәй боек йөриләр. Муса моны бик яхшы сизеп тора, әйтмиләр генә үзләре... Әйе, хәлләр авыр. Илнең язмышы, чынлап та, кыл өстендә. Ә шулай да Мусаны икеләнүдән саклаучыниндидер эчке бер тавыш хәбәр бирә: «Юк,— ди ул,— алтмыш куллы Алып батырдай алтмыш телле халык алай гына бирешергә уйламый. Ул әле, яраланган-яндырылган булса да, җиргә нык басып тора: алтмыш колач җилкәсендә җир күтәрер егәр бар. Алтмыш тармак кулларында алтмыш батман чукмар бар. Ул әле соңгы сүзен әйтмәгән!..»

Мусаның Рәфикъ ярсыганда тыныч елмаюы шушы эчке ышанычтан да иде. Һәм шулай тыныч кына ул аңа җавап та бирде.

— Ярый, Рәфикъ,— диде ул,— без әле синең белән нидер эшләмәкче булып кына йөргән идек. Мин сине, яшь комсомолец дип, үзем бу эшкә димләгән идем. Бер төрле дә көчлек юк. Ачык сөйләшү, әлбәттә, яхшырак. Соңыннан үкенече булмасын... Син бая теге кешегә бик каты сүзләр әйткән идең, ә хәзер үзең дә шул эзгә төштең, ахры...

— Юк, алай түгел, монда бик зур аерма бар! — диде Рәфикъ, Мусаның сүзен бүлеп.— Ул, тамак хакына булса да, немецка һөнәрен саткан, сугыш приборлары ясый һәм шул күгәрчен оясында шыкланып калмакчы була. Ул әле немец подданные да булыр. Ә мин сатылмыйм! Ялгыз солдат булып, үләргә китәм!

— Мин сине тотмыйм да, гаепләмим дә, Рәфикъ. Үз ихтыярың. Үзең белгәнчә хәрәкәт ит. Монда берәүне дә көчләп булмый.— Муса, үзен тыярга теләгәндәй, чәчләрен артка табарак сыпырып куйды.— Тик, кайда гына булсаң да, иманыңны югалтма! Ил җиңәчәк. Без әле синең белән Казанда кочаклашып күрешербез, исән генә булыйк!

— Бирсен ходай,— диде Рәфикъ, урыныннан торып. — Ләкин, не осуждай! Матур итеп үләсем килә!

«Бунтарь идем,
Гөнаһ-фәлән диеп тормадым.
Зәңгәр төндә күрше карчыгының
Ак әтәчен кереп урладым!»

Чорт возьми, үзе шәп шагыйрь булмаса да, әйбәт юллар язып калдырган шул Такташ. Күпме романтика!

— Ә син аны бозып укыйсың,— дип көлде Муса.

— Ничава! Мин — үземчә.

— Шулай инде син. Үзең шагыйрьне танымыйсың, үзең шигырьләрен күңелдән беләсең, гәрчә бозып булса да...

— Нишлисең бит, ошый. Мин булсам, әлбәттә, шәбрәк язар идем!.. Ярый, сау бул, Муса абый!

Мин үземчә телим көләргә,
Мин үземчә телим үләргә!

Гыйльфанов җилтерәп ишеккә атлады. Ул шушындый матур хәрәкәтләр белән артистларча гына чыгып китәргә уйлаган иде, ләкин аны Муса бүлде.

— Бер генә минут...— диде ул, тавышын экренәйтә төшеп.— Ә менә дәҗҗал муеныңнан буып алса, ничек сайрарсың?

— Курыкма, әйтмәм. Дәҗҗалның мин үзен буармын!

Польша урманнары күрер әле
Казанның бу бунтарь егетен!

Шул сүзләр белән, шулай да артистларча матур хәрәкәт ясап, Рәфикъ Гыйльфан чыгып китте.

— Абау, хәтәр син! — дип калды Муса дусларча көлеп. — Юлың уңсын!

*(Дәвамы бар.)*

*Рәдиф Гатауллин*

## Түземлелек

Кеше — түземле дә...
Табигате бунтарь булса да,
Көтә белә.
Мине дә күпләр көттерделәр...
Көттерде — үсмер чак.
Мәхәббәт көттерде.
Сүз куешкан урынга — көттереп
килде сөйгәнем,
Көттереп үптерде.
Көттерде өлгергәнлек аттестаты,
Өлгергәнлек үзе.
Автобуслар, самолетлар,
атлар,
Хатлар көттерде.
Көттерде бәхет, акыл, тәҗрибә.
Көтәргә өйрәндем.
Инде — сез —
моңа кадәр
Мин белмәгән — картлык,
Кайгы,
авыру — килсәгез,
Көттерсәгез,
үпкәләмәм.
Чөнки мин көтә беләм.

## Без күрмибез

Без күрмибез —
Болытның
су парларын ничек алганын.
Күрәбез —
коеп яңгыр яуганын.
Без —
хәтта иң якын дусларның
Ни белән яшәвен белмибез.
Белмибез —
берәүнең
Төннәр буе йоклый алмавын,
Эш өстендә ничек янганын —
рәхәтен, газабын.
Шагыйрьнең эзләнүен күрмибез.

Ләкин, без
Сокланабыз —
яңа ачышларга,
Башваткыч эшләргә,
Хисле җырларга,
Көчле образларга —
сокланабыз.
Алар ничек туа? Без белмибез.
Табигать яраткан талант бу! —
дибез.
...Без —
Болытның су парларын —
җыюын күрмибез.

## Кеше—гашыйк

Җир кешене мәңге ашыктырган:
Гасыр, еллар буе.
Ашыгып сөя кеше, аннан ашыгып
Уза диләр туе.
Мин дә ашыгам — алга, елларыма
Колач ачып менә...
Ашыктыра кояш, йолдыз мине,
Җилләр ашыктыра.
Я суыта дөнья, я тирләтә,
Яки ачыктыра.
Кузгалырга, алга юл алырга
Форсат ачып тора.
Нинди бәхет. — Һәрбер көне белән
Дөнья ашыктыра.
Яши ала шулай ашыгып,
җирдә,
Бары гашыйк кына!

## Яратам бугай...

Аның турында уйланып,
мин
Йокысыз үткәрдем төнне бүген,
Яныл чыктым.
— Әгәр дә шушы минутта,
Ул авырып ятса,
янса утта?!
Әгәр дә ул каты сызланса?!
Маңгаен тотарга да кеше
булмаса —
Шушы минутта?! —
Төне буе мин янып чыктым.
Әгәр дә ул бүген юлда булса?
Бәлагә очраса?
Караңгыда калса, һәм уты сүнсә?
Әгәр дә ул — юлда булса?!
Төне буе мин янып чыктым.

Әгәр булса ул бүген диңгездә?
Шторм кубып, чайкалса дулкында?
Давыл белән көрәшсә бу төндә
Диңгездә?!
Төне буе мин янып чыктым.
Мин авырыйм,
Мин — саташам
бугай.
Ләкин, гомеремдә беренче кат,
авырганда
Үз хәлемне мин оныттым,
Мин уйладым
һәм кайгырттым
аны шулай.
...Мин авырмыйм... һәм яратам
бугай.

## Ятлар бирде, ятлар алды

Башта сине мин сөймәдем әле,
Тик, ошадың миңа.
Ятлар: «Син сөясең аны», — диде,
Һәм ышандым моңа.

Бернәрсә дә сиздермәдем сиңа,
Сиздерделәр ятлар.
Һәм синнән дә бер көн «сөям» сүзен
Китерделәр ятлар.

Бер дә кавышып серләшмәсәк тә без,
Сөю истә калды...
...Ятлар бирде безгә бу сөюне,
Ятлар кире алды.

## Роль биргәннәр...

Бала чакта уйнап роль бүлештек:
Син тау кызы, мин — бер көтүче...
Син сөясең... аннан онытасың,
Ә мин — мәңге янып сөюче.

Зурайдык та, чынлап сөештек без;
Картлар моны—«язмыш» дигәннәр...
Син ташладың мине.
Ә мин — сөям...
Безгә рольне белеп биргәннәр.

## Исемнәр

Мин исемнәр яратучы.
Гаҗәпләнмә, нигә? — димә.
Байрон исеме, Пушкин исеме,
Гейне исеме ошый миңа.

Гаҗәпләнмә — Эдиссоннар
Һәм Колумблар миңа якын...
Җәлил исеме! — һәрберсеннән
Әллә күпме мәгънә таптым.

Мин исемнәр яратучы!
Минем йөрәк —
Йолдызларны үзенә җыйган
Күк шикелле! —
Мең-мең исем белән тулган.

Мин исемнәр яратучы...
Һәм,
Шулай ук — яратмаучы.
Гаҗәпләнмә, нигә? — димә.
Күп вакытта үз исемем дә,
Киң бушлыкта очып йөргән
Йондай җиңел тоела миңа!

## Биекләкләр

Мин үзәндә туып,
үзәндә үстем.
Биекләргә тартты йөрәгем.
Мин тауларга мендем.
Чикләнмәде
Таулар белән генә теләгем.
Һаман биек илтә мине юллар,
Һаман күтәреләм —
Нилектән?!
Ә бит, биектәге үзе аска төшә —
Йолдыз атылып төшә — биектән.
Җир, күк...
Ахры һаман бер-берсенә
Җибәрәләр шулай илчеләр.
Күктән метеорлар төшә җиргә,
Җирдән күккә менә
Кешеләр!

## Шикләнүең нигә

Нич-ә еллар сөеп,
күзләреңә
Туры карамадым.
Үпкәлисең: — Болай кылануың
Әллә яратмавың?!

Шикләнүең нигә инде синең,
Әй, күземнең нуры! —
Мин кояшны сөймиммени?
                    ә бит
Карый алмыйм туры...

## Шат күңелләләр җыры

Безнең көлү — башка төрле көлү.
Гариплектән, бәхетсездән көлмибез
                    без.
Мыскыл итә белмибез без.
Кабахәт көлүе түгел безнең көлү
Безнең көлү — кемдер елаганнан
                    түгел,
Мәхәббәттә яшь кыз алданганнан
                    түгел,
Кемдер бәхетен таба алмаганнан
                    түгел,
Безнең көлү — башка көлү.
Без көләбез — кояш елмайгандай,
Гөлләр тибрәнгәндә.
Без көләбез — уйнаганда,
Көлке тыңлаганда,
Башка кешеләр көлсә,
Һәм көлүнең кадерен белсә.
Без көләбез — яшь бер кызның ап-ак
                    булып
Тезелгән тешләрен күрсәк,
Дуслар белән саф һавада йөрсәк,
Аруларны, авырлыкны җиңсәк...
Күп вакытта сәбәпсез дә без
                    көләбез.
Ләкин җитди була белмибезме?
Юк, беләбез.
Тормышны без әллә белмибезме?
Юк, беләбез!
...Яшәү күңеллерәк булсын өчен,
Әйләнәдә һәркем көлсен өчен,
Күп вакытта —
          бик елыйсы килгәндә дә —
Без көләбез.

*Хәй Вахит*

# КАРЛЫГАЧ КАНАТ КАГА

**ЖИТДИ КОМЕДИЯ, ӨЧ ПӘРДӘДӘ**

КАТНАШАЛАР:

Ильяс Гаязович Айтуганов — вакыйга башланганда совхоз директоры, 40 яшьтә.
Бәнат — яшүсмер. Ильясның кызы. 15 яшьтә.
Шамил Саттарович Хәсәнов — вакыйга башланганда совхозның бүлекчә управляющие, 42 яшьтә.
Мәрьям — Шамилнең хатыны.
Диләра Хәсәнова — Шамилнең бертуган сеңелесе. 26 яшьтә. Агроном.
Җәүдәт Мингалиев — механик. 24 яшьтә.
Марсель — яшүсмер. Җәүдәтнең энесе. 15 яшьтә.
Лемара — хисапчы. 20 яшьтә.
Кәүсәрия — 35 яшьләрдә.
Гыйләж — Кәүсәриянең ире. 35—40 яшьләрдә.
Сәрьян — карт.
Карчык — Сәрьянның хатыны.
Низами— бригадир. 50 яшьләрдә.
Мәйсәрә — сыер савучы кыз. 18 яшьтә.
Альберт — участковый.
Сәгыйт Баймурзин — журналист.

Вакыйга бүгенге көндә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

(БЕРЕНЧЕ КАРТИНА)

Юллар!.. Төрлесе була юлларның. Кайберсе аларның туры була, олы була, үз өстеннән зур йөкләр, күп кешеләр үткәрә, кайберсе исә, боргаланып тыкрыкка илып керә дә шунда чикләнә. Һәрберсенең үз юнәлеше бар, шулай да юллар юллар белән кисешмичә тора алмыйлар, үтүе авыр булган елгаларны алар бергә кичәләр. Юллар күпердә очрашалар.

Күпернең безгә бер ягы гына күренә. Аның култыксасына башын салып диярлек каен үскән, калкулыкны әрәмәлек каплаган. Чылтырап чишмә ага.

Бирегә йортлар да, төзелешләр дә юк. Авыл бу калкулыкны әйләндереп утырган. Күз карашына бирегә ерак офыклар ачыла. Менә ни өчен бу калкулыкка күтәрелгән кеше тирә-якка күз ташламыйча үтә алмый.

Яз. Айлы төн.

Ерактан мандолина тавышы ишетелә. «Кайдан бу моң?» дип уйларга да өлгермисең, яр өстендәге юлда бер кыз күренә. Ул салмак кына атлый. Аның артыннан, беркадәр ара калдырып, егет килә. Кулында мандолина. Ул кызны озатып килә, әйтерсең, ул аның җан сакчысы. Менә яр астыннан икенче егет күтәрелә. Кулында гар-

монь. Ул беренче егетне терсәге белән генә читкә этәрә дә, шулай ук беркадәр ара калдырып, кыз артыннан үзе китә. Кыз борылып кына карый да, боларга игътибар итмичә, атлавын дәвам иттерә. Ул моңа күнеккән, күрәсең, шулай тиешлегенә ышангандыр. Матур кыз. Аларның юллары сулга үтеп безнең күздән күмелеп тора да күпер өстеннән әйләнеп чыга. Алар күперне үтүгә, каян килеп чыккандыр, өченче бер егет — сакал үстергән егет — кызның каршына килеп баса. Егет ярсу күренә. Кызның йөзендә дә горурлык кабына. Күзгә күзләр текәлә. Сүзләр әйтелми. Кыз кискен хәрәкәт белән читкә борыла да юлын дәвам иттерә. Сакаллы егет, беренче егетнең кулыннан мандолинасын тартып алып, кыз артыннан үзе атлый. Кыз моңа риза түгел. Кинәт туктала, сакаллы егетнең үз артыннан баруын теләми. Сакаллы егет ярсынып мандолинаны җиргә бәрмәкче була, әмма тыелып кала, хуҗасына тоттыра да күпер аша китеп югала. Матур кыз, аның артыннан беркадәр ара калдырып, гармоньчы белән мандолиначы егетләр юлларын дәвам иттерәләр.

Тынлык. Берәү дә юк. Кайдадыр, кемнеңдер җырлаганы гына ишетелеп тора. Бераздан Мәрьям күренә. Борчулы, кемнедер эзли. Икенче яктан килгән ирен күреп алып, каршысына ашыга.

Мәрьям. Шамил, Диләра китмәде бит.

Шамил. Ничек китмәде? Кичке поездга машина бирдем ич.

Мәрьям. Китмәде. Ул икеләнә булса кирәк.

Шамил. Бу ниткән эш тагын?

Мәрьям. Мин аны бөтенләй аңламый башладым. Соңгы вакытта әллә нишләде ул. Әнә үзе. Нәрсә эзли, кемне эзли, белмим. Шамил, аңа синең киңәшең кирәк. *(Кычкыра.)* Диләра, Диләра дим!

Диләра күренә.

Шамил. Диләра, нишләп йөрүең бу?

Диләра. Мин, абый...

Шамил. Әйдәгез, кайтыйк әле.

Диләра. Мин иптәш кызыма кереп чыгармын дигән идем.

Шамил. Йоклаган кешене уятыпмы? Диләра, син уйлап эшлисеңме? *(Диләра дәшми.)* Тарас Бульба малаена: «Мин сине тудырдым, мин сине юк итәм», — дигән. Мин алай димим. Мин сине тудырмадым, мин сине юк итмим. Мин синең әтиең-әниең урынына калган кеше, бертуган абыең. Тәрбияләп үстердем, укыттым. *(Басым ясап.)* Мин сине кеше иттем, мин сиңа акыл бирәм. Күңелеңне азындырма, кызый, икеләнә торган чагың түгел. Сине Казанда Сәгыйтең көтә. Газета работнигы. Журналист. Үсә торган кеше. Иртәгә ЗАГСка барырга дип көтә.

Диләра. Беләм, барысын да беләм.

Шамил. Шулай булгач?! Нигә соң Казанга китми калдың?

Диләра. Соң... Өлгермәдем. Җыенасым бар иде. Иртәгә китәргә булдым. Бары шул гына.

Шамил. Алай гына булса... *(Өйгә табан кузгала.)* Бу нәрсә тагын? *(Җиргә кадалган тактаны күрә, аңа язу ябыштырылган булып чыга. Укый.)* «Мууу... Сыерлар сүзе бууу.. карусельдә әйләнәсебез килә. Карусельдә әйләнсәк, сөтне бушка бирер идек. Мууу...» *(Сүзсез кала.)*

Мәрьям. Бала-чага эшедер шунда.

Шамил. Канга тоз салалар, билләһи! *(Тактаны тибеп очыра.)*

Диләра. Мин озакламам.

Шамил белән Мәрьям китә. Алар күмелүгә каяндыр яшүсмер Марсель килеп чыга. Тактаны ала да күздән югала. Күпер өстендә Ильяс күренә. Диләра аның каршына атлый. Каен янында очрашалар.

Диләра. Ильяс абый!

Ильяс. Диләра?

Диләра. Нигә шулай гаҗәпләндең?

Ильяс. Казанга китәргә тиеш идең түгелме соң?

Диләра. Ах, димәк, син минем китәргә җыенганымны белә идең?

Ильяс. Ишеттем.
Диләра. Ни өчен китәсемне дә ишеттеңме?
Ильяс. Анысын чамаладым гына.
Диләра. Чамалагансың, ә шулай да...
Ильяс. Нәрсә — шулай да?

Бәнат килә.

Бәнат. Әти! *(Әтисе белән Диләра арасына кереп баса. Әле берсенә, әле икенчесенә карап ала.)* Диләра апа, ә сез беләсезме, минем әти әни белән шушы каен төбендә очраша торган булган.
Диләра. Белми идем. *(Китә.)*
Бәнат. Әти, сөйлә әле, әни белән бервдә ничек очраша идегез, нәрсәләр сөйләшә идегез. Барсын да, барсын да беләсем килә.
Ильяс. Элек бервдә басма гына иде. Хәзер күпер. Үзгәргән. Менә бервдә басып тора идек. Мин сукмакка, ә ул — ул миннән тәбәнәгрәк булганга — калкурак урынга басар иде.
Бәнат. Тагын?
Ильяс. Хыялга бирелүчән кеше иде синең әниең. Ул киләчәк турында сөйләргә ярата иде, туган авылының киләчәге турында! Очынып яши торган җан иде. Әнә күрәсеңме, бу якта калкулык китә — таулар тезмәсе. Бу якта да калкулык сузыла. Әниең боларны, беләсеңме, нәрсәгә охшата иде? Карлыгач канатларына! Безнең авыл карлыгач кебек, ди иде ул.
Бәнат *(тәэсирләнеп)*. Әйе, әйе, әнә ике канаты җәелгән. Әнә башы, койрыгы! Карлыгач! Минем әниемнең туган авылы — карлыгач!
Ильяс. Карлыгач канат кагар, күккә күтәрелер, дип авылының үсәчәгенә ул ышанып яши иде.
Бәнат. Әйе, карлыгач очарга җыенган, әнә канатларын җәйгән, ул күккә күтәрелергә тели!
Ильяс. Аның үз җыры да бар иде. Әниеңнең яраткан җыры. *(Авыз эченнән генә шыңшый, Бәнат та кушыла.)*

Яз димисең, көз димисең,
Эзләнүдән өзелмисең.
Кая болай ашкынасың,
Һаман шулай ни эзлисең,
Күңелкәем — карлыгачым,
пар канатым!
Һаман шулай ни эзлисең?

Шул чакта күпер өстендә әлеге сакаллы егет күренә.

Бәнат. Ләкин...
Ильяс. Ләкин шушы көнгә кадәр карлыгачның канат какканы, күккә күтәрелеп киткәне юк әле.
Бәнат. Нигә күтәрелми ул? Ни өчен карлыгач канатын җәеп күккә очмый, нигә аның канатлары салынган, әти?
Сакаллы егет. Ни өчен карлыгач күккә күтәрелеп китә алмыймы? Чөнки аның канатларын каерганнар.
Бәнат *(егетне яңа гына күреп алып)*. Кемнәр?
Ильяс. Кем?
Егет. Эш өчен кем җаваплы булса, шул!
Ильяс. Монда иң җаваплы кеше мин. Совхоз директоры. Димәк?
Егет. Димәк, сез!
Бәнат. Әти, кем ул?
Ильяс. Кем булсын, очраган бер җирдә, кирәккә дә, кирәкмәгәнгә дә, керпе шикелле инәләрен тырпайтучы... Җәүдәт булмыйча, кем булсын. Исәнме!

Җәүдәт. Исәнмесез, Ильяс Гаязович.
Ильяс. Сакал үстерә дип ишеткән идем.
Җәүдәт. Менә хәзер күрдегез дә.
Ильяс. Кубалылар сакал үстерә иде. Анда аның мәгънәсе зур. Куба җиреннән соңгы американец табан ялтыратканчыга чаклы алар сакалдан йөрделәр.
Җәүдәт. Минем дә шулай. Карлыгачның канатын каеручылар туган авылымнан табан ялтыратканчыга чаклы үстерәчәкмен.
Ильяс. О, синең сакалның да мәгънәсе бар икән. Әгәр дә озак үстерергә туры килсә?
Җәүдәт. Күпме кирәк булса, шул чаклы.
Ильяс. Җиргә җиткәнче?
Җәүдәт. Сез чалынып егылганчы.
Ильяс. Егет кеше, яшь булу тупас булырга хокук бирми.
Җәүдәт *(өзгәләнеп)*. Нигә сез ул тупас Җәүдәтне судка бирмисез, ә? Совхозның двигателен урлап сатып җибәргән кеше икән, аны инде күптән төрмәгә утыртырга кирәк иде. Нәрсә көтәсез?!
Ильяс. Ашыкма, тиеш булса бирерләр.
Җәүдәт. Бирмиләр шул. Куркалар. Үзләре фаш ителүдән куркалар. Менә шуның өчен дә сакал үстерәм. Үстерәм! Судка биргәнчегә кадәр үстерәчәкмен. Хәтерләренә төшереп торсын. *(Китә башлый, туктала.)* Бөтен авылга яман атымны тараттылар. Кешеләр хәзер минем турыда нәрсә генә уйламый торганнардыр. Мин андый түгел дип, һәрберсенең колагына әйтеп йөреп булмый бит. Менә судта бер әйтермен, берәгәйле булыр. Кемнең кем икәне ачыкланыр.

Гыйләҗ күренә. Исерек. Башта бер юнәлештә атлый, туктала. Икенче якка китә, тагын туктала. Утыра.

Җәүдәт. Гыйләҗ, ни булды сиңа? Нишләп утырасың?
Гыйләҗ. Бөтен дөнья әйләнә. Карусель диярсең. Өем әйләнеп килмәс микән дип, көтеп утырам. *(Торып китә, тагын утыра.)* Кил әле, кил. Син миңа шуны әйт, Гыйләҗ кайда тора монда?
Җәүдәт. Һе, дус кеше, син бит үзең Гыйләҗ.
Гыйләҗ. Беләм. Үземнең Гыйләҗ икәнлегемне белмәскә ни. Бик беләм. Гыйләҗ кайда тора дим? Ә? Өемне таба алмыйм ләбаса.

Бәнат көлеп җибәрә, аны атасы туктата.

Ильяс. Гыйләҗ, нигә инде шул кадәр?.. Исергәнсең.
Гыйләҗ. Ни өчен исерекме? Хатын закуска бирмәде. Кем эшләми — шул ашамый, ди.
Җәүдәт. Әнә хатының үзе килә. Бар, кайт та ау.

Кәүсәрия килә.

Гыйләҗ. Ә Кәүсәрия... Әйтәм бит, җир әйләнә дип. Менә хатынны да әйләндереп китереп каршыма бастырды.
Кәүсәрия. И... теле ачылган икән сандугач баласының.
Җәүдәт. Алып кайт, өен таба алмый йөри.
Кәүсәрия. Исерсә шул аның, өйләрне буташтырып бетерә. Ярый әле, күршедә тол хатын юк. Ни дип шулкадәр эчкәнсеңдер инде.
Гыйләҗ. Сыек булганга, әнкәсе, сыек булганга. Каты булса, ашаган булыр идем.
Кәүсәрия. Я, телеңә салынма, шушы исерсә бер. Әнә директор үзе, Ильяс Гаязович бар.
Гыйләҗ. Ә? *(Кинәт айнып китте диярсең, әйтәсе сүзен дә ымлап кына аңлата.)*
Кәүсәрия. Әйдә, әйдә. Гаеп итмәгез инде, Ильяс абый. *(Кәүсәрия Гыйләҗне алып китә.)*

Җ ә ү д ә т. Кайчандыр алдынгы кеше иде. Атаклы кеше. Әнә хәзер эчә. Ни өчен? Белмисез. Ә белергә кирәк иде. Хушыгыз. *(Китә.)*

Б ә н а т. Абау, нинди усал кеше.

И л ь я с. Усал түгел, ачулы. Әйдә, бүгенгә җитәр.

Китә. Шул чакта тагын Марсель күренә. Бәнатны күлмәгеннән тотып, туктата.

Б ә н а т. Сез кем? Каян килеп чыктыгыз?! Җибәрегез, сезгә нәрсә кирәк!

М а р с е л ь. Мин Җәүдәт абыйның энесе. Мин сезнең сүзләрегезне тыңлап тордым.

Б ә н а т. Шәп иткәнсең икән. Шуның белән мактанмасаң?! Кара, нигә арттан киләсең?!

М а р с е л ь. Нишләп синең арттан барыйм ди. Мин өемә кайтам ич. *(Үзе кызны туктата.)* Ә мин теге җырны, әниең яраткан җырны беләм бит. *(Шыпырт кына җырлый.)*

Яз димисең, көз димисең,
Эзләнүдән өзелмисең...

Син кем исемле? Мин Марсель.

Б ә н а т. Бәнат.

М а р с е л ь. Исемең бик матур түгел икән. Иске исем.

Б ә н а т. Әле тулысы — Хәербәнат. Миңа әни исемен биргәннәр. Мине тудырганда ул үзе үлгән.

М а р с е л ь. Телисеңме, бер сер әйтәм.

Б ә н а т. Очраган бер кешегә әйтә торган булгач, ул нинди сер булсын.

М а р с е л ь. Ә ул тактаны кем язган дип беләсең?

Б ә н а т. Син.

М а р с е л ь *(аптырап кала)*. Каян белдең?

Б ә н а т. Үзең әйтеп торасың ич.

М а р с е л ь. Әйдә, күл буйларын күрсәтеп йөримме?

И л ь я с т а в ы ш ы. Бәнат!

Б ә н а т. Әнә, әти дәшә. Кайтып йокларга кирәк.

М а р с е л ь. Алайса, мин дә кайтам да ятам.

Бөтенләй икенче якка чыгып китә. Бәнат аның артыннан күлеп карап кала да әтисе артыннан китә. Ерактан Марсельнең җырлаганы ишетелеп тора.

Булырмы бер тынар көнең,
Тагынниләр уйлыйсыңдыр.
Ничек шулай бер туктаусыз
Җилкенүдән туймыйсыңдыр...

Диләрә килә. Ерактан таң беленә башлый. Әтәч кычкыра.
Диләрә артыннан Мәрьям килә.

М ә р ь я м. Нишләвең синең, акылың бармы?! Кем белән очрашырга теләп йөрисең син?!

Д и л ә р ә. Юк ла, җиңги, мин бит болай гына. Мин бары... туган авылны ташлап китү җиңел дип беләсеңме? Мин бит агроном. Әнә, шул җирдән ничек аерылып китмәк кирәк. *(Авыз эченнән генә Марсель җырына кушыла.)*

Күңелкәем — карлыгачым,
пар канатым!
Тагын ниләр,
Тагын ниләр уйлыйсыңдыр.

М ә р ь я м. Ай, кызый, шикләнәм мин синнән. Әллә инде... аны ташлап китә алмыйсың дисәм?

Д и л ә р ә. Кемне, аны?

М ә р ь я м. Аны!

Диләра. Юк сүз. Минем аңа нигә кирәгем бар?! Әгәр мин аңа кирәк булсам, ул мине җибәрер идемени?! Ул бит минем бөтенләйгә китәргә җыенганымны белә. Ул мине беркая да, беркемгә дә җибәрмәскә тиеш. Көрәшергә, тартышырга, әмма җибәрмәскә. Ә ул?.. Ул җибәрә. Димәк, миңа китәргә кирәк. Кирәк. Иртәгә үк китәм.

Мәрьям. Шулай, дөрес. Барсы да сөйләшенгән, барсы да хәл ителгән бит инде.

Диләра *(ирония белән)*. Шулай. Барсы да хәл ителгән. Әйдә, кайтыйк. Кайтыйк. Юлга әзерләнергә дә кирәк. *(Китәләр.)*

Эчке пәрдә төшә. Җыр һаман да ишетелеп тора.

Бер талпынып китә алсаң,
Болытларга җитәр идең,
Күк дәрьясын айкап чыгып,
Йолдызларга китәр идең.
Күңелкәем — карлыгачым, пар канатым,
Белмим кая китәр идең...

Нинди юллар, нинди җырлар
Дәшеп тора сине алда.
Белсәң иде, нинди өмет
Көтә икән сине анда.
Күңелкәем — карлыгачым, пар канатым,
Ниләр көтә сине алда...

Пәрдә ачыла.

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Контора. Урамнан күрә торган һәм ике якта ике бүлмәгә чыга торган ишекләр. Управляющий өстәле, телефон. Стенада плакатлар, радио-репродуктор. Зур тәрәзәләрдән киң урам, каршы яктагы йортлар күренеп тора. Вакыт иртә белән. Бүлмәдә Гыйләҗ утыра. Кәүсәрия бүлмә ишегеннән чыга.

Кәүсәрия. Управляющий озакламый килергә тиеш ди. Бригадир белән эшне йөртеп булмый, үзенә кер.

Гыйләҗ. Ә...

Кәүсәрия. Түбә ябарга диген. Дүрт фестметр.

Гыйләҗ. Ә...

Кәүсәрия. Буш түгел, бәясен түлибез диген.

Гыйләҗ. Э...

Кәүсәрия. Э дә э. Шуның бер, айныса, авызыннан сүз алып булмас. Башкасына саран булсаң да, сүзгә саран булма син. Бу дөньяда сөйләп алдыралар. Ярар, үзем сөйләшермен, синнән булмас.

Гыйләҗ. Э...

Кәүсәрия *(үчекләп)*. Мә! Бир әле берне, көйрәтим, нервларым зырылдарга тотынды. *(Иреннән папирос алып каба, тончыга. Сәрьян картның килеп кергәнен күреп ашерә. Гыйләҗгә.)* Бар кайт. Бар дим.

Гыйләҗ. Э... *(Чыгып китә.)*

Сәрьян. Фу, ашыгып килеп ятам тагын. Шамил юк ахры?

Кәүсәрия. Чыгып киткән. Инде унбиш минутлап ди.

Сәрьян. Ярый әле ашыкканмын, югыйсә ярты сәгатькә соңга каласы икәнмен. *(Читтәге урындыкка утыра.)*

Кәүсәрия. Сәрьян абый, очратуым яхшы булды әле. Үзең беләсең, өй түбәбез салам.

Сәрьян. Беләм, беләм. Аңа үземнең дә кәеф кырылып йөри. Килешми, хәзерге заманда салам түбә бер дә килешми.

Кәүсәрия. Әзрәк тактабыз бар, җитәрлек түгел. Янына кушарга булмасмы икән дигән идек. Начальствоны күндереп булмый.

Сәрьян. Булмас. *(Кул селтәп.)* Булмас. Безнең гозерне аңлый торганнардан түгел алар. Булмас. Тукта әле, нигә миңа сөйлисең аны? Миңа сөйләдең ни, шушы таякка сөйләдең ни.

Кәүсәрия. Олы кеше итеп, авылның атасы итеп. Казакъларча әйтеп җибәрсәк, ак сакалы. Сәрьян абый, нишлим икән, әллә берәр кыйтылык эшләп ташлыйммы икән?

Сәрьян. Кырт кисеп кенә булыр микән?

Кәүсәрия. Әй, булса шул кырт кискәндә була да инде ул.

Ашыгып Шамил керә.

Шамил. Директор күренмәдеме? Кайда йөри бу? *(Өстәл янына уза.)*

Кәүсәрия. Шамил абый, мин сезнең янга килгән идем.

Шамил. Бүген прием көне түгел.

Кәүсәрия. Прием булмаганга килдем дә, югыйсә кеше күп була.

Шамил. Нинди йомыш, совхоз өчен файдалымы, үзең өченме?

Кәүсәрия *(уйлабрак торгач)*. Совхоз өчен!

Шамил. Шулайменi? *(Игътибар белән.)* Я, тыңлыйм.

Кәүсәрия. Йомышы инде аның, дөресен әйткәндә, үзем өчен файдалы. Ә мин совхоз өчен файдалы. Шулай булгач, йомыш та совхоз өчен файдалы булып чыга түгелме соң?

Сәрьян кеткелдәп куя.

Шамил *(утыра, кәгазьләренә кумелә)*. Әйт йомышыңны.

Кәүсәрия *(бераздан)*. Бу ни, безнең авыл социализмда утырып каламыни, иптәш Хәсәнов?

Шамил. Ни дигән сүз.

Кәүсәрия. Безнең өйнең түбәсе салам ич. Аның белән коммунизмга кертмәсләр безне.

Шамил *(көлеп җибәрә)*. Хааа... сезнең өйдә музей ясыйбыз. Авылда гына түгел, тирә-юньдә бер өй — салам түбәле. Искелекнең калдыгы. Музейның үзе инде. Киләчәк буынга күрсәтү өчен.

Кәүсәрия. Ха-ха... Сез минем күзгә төтен җибәрмәгез, иптәш Хәсәнов, яратмыйм. Бер дүрт фестметр такта булмасмы дигән идек. Кайчаннан бирле сорап йөрибез.

Шамил. Юк.

Кәүсәрия. Юкның башы авыртмый инде аның.

Шамил. Пилорама эшләми. Двигательне урладылар. Такта юк.

Сәрьян. Өйләре бигрәк тау өстендә. Әллә кайдан күренеп тора.

Шамил *(башын күтәрә.)* Миннән сөт сорыйлар, ит сорыйлар, Кәүсәрия түтинең түбәсе ябылганмы, дип сорамыйлар.

Сәрьян. Юкка сорамыйлар, сорарга кирәк иде.

Шамил. Ну, ну! *(Кәүсәриягә.)* Сиңа эш урынында булырга иде, директор килгән.

Кәүсәрия. Кайчан язу бирәсез, шунда китәм.

Шамил. Син, Кәүсәрия, бу кыланышларыңны ирең алдында күрсәт, монда түгел. Кстати, кайчан ташлый инде ул эчеп йөрүләрен?

Кәүсәрия. Кем гаепле?!

Шамил. Кем булсын, мин — управляющийдыр инде.

Кәүсәрия. Унсигез ел йөрде ул бер машинада. Бер ремонтсыз. Машинасын өр-яңа итеп тотты. Аны газетта мактап язарга кирәк иде, ә сез аны алып ыргыттыгыз. Атлар пенсиягә чыккан бер заманда, сез аны машинадан алып атка утырттыгыз. Әле дә мескенем түзә, сүз әйтми. Аракы түгел, таракан даруы эчеп уларсең бу хурлыктан. Шул-шул, җылаганны күрмиләр, җырлаганны тиз күрәләр.

Шамил. Эчеп йөрүе җитмәгән, мине гаепли икән әле тагын. Балда.

Кәүсәрия *(Сәрьянга)*. Нәрсә диде?

Сәрьян. Ишетмәдем.

Кәүсәрия. Ни дигән сүз ул — балда?

Сәрьян. Шуны да белмисеңме? Тинтәк.

Кәүсәрия. Бирем мин сиңа тинтәкне!

Сәрьян *(кеткелди)*. Балда алайса.

Кәүсәрия *(Шамилгә)*. Кем балда, Гыйләҗме?

Шамил. Ярый бар, вакытыңны юкка әрәм итмә, сатып ала торган әйбер түгел.

Кәүсәрия. Һей, бер көн эшкә чыкмасам — менә сиңа вакыт. Язасызмы?

Шамил. Юк дим, юк. Сорап баш катырмагыз да.

Кәүсәрия. Сездән сорамыйча кемнән сорыйк. Урларга кушасыз, што ли?!

Шамил *(сүз беткәнне аңлатып, икенче бүлмәгә кычкыра)*. Лемара, сводка әзерме анда?

Кәүсәрия *(сизеп алып)*. Сәрьян абый, чыгып тор әле, шаһитсыз гына сөйләшәсе сүзем бар иде.

Сәрьян урындыгында борылып утыра, бүрек колакчынын төшерә.

Шамил Саттарович, шуны әйтәм, без бит бер тыкрыкта торабыз.

Шамил. Торсак соң?

Кәүсәрия. Бакчага бакча, мунчага мунча дигәндәй.

Шамил. Булса?

Кәүсәрия. Шул. Караңгы төндә мине очратып куюыгыз мөмкин.

Шамил. Бер тыкрыкта торгач мөмкин, әлбәттә.

Кәүсәрия. Бераз кызмача. Мине туктатасыз. Беләкләремнән тоткалыйсыз, колагыма нәрсәдер пышылдыйсыз.

Шамил. Ни сөйлисең син?!

Кәүсәрия. Билемә кул саласыз. *(«елый» башлый.)*

Шамил *(аягына баса)*. Нәрсә?

Кәүсәрия. Шунда, караңгы тыкрыкта, сез мине мыскыл итәргә теләдегез. Менә күлмәгемне дә ерттыгыз. *(Үзенең күлмәк итәген ерта башлый.)* Барам, барам, директорына да барам, секретарена да барам, әйтәм, барсын да сөйлим. Бу хурлыкка түзәмме соң.

Шамил. Нишләвең бу синең, ә?!

Кәүсәрия *(«елавыннан» кинәт туктап)*. Яз дүрт фестметр тактага кәгазь, шуның белән бетер, бер кая да бармыйм. Кайтам да күлмәгемне ямыйм.

Шамил. Чыгып кит моннан!

Кәүсәрия. Сәрьян абый, керсәң дә була. Ә мин киттем, директорны авылда диләр. Әйтәм, күрәм дә, барсын да әйтәм. Кәүсәрия тәтәң кулына эләкмәгәнсең әле. «Сибелә чәчәк» көенә биетермен мин. *(Сөйләнә-сөйләнә чыгып китә. Урам яктан тәрәзәне ачып тагын кычкыра.)* Әлпиеңне укытырмын!

Кәүсәрия ачкан ишектән Мәйсәрә килеп керә. Ул кыюсыз, оялчан. Кәүсәриянең нәкъ киресе.

Мәйсәрә. Керергә ярар микән?

Шамил нишләргә дә белмичә, йөренә, үзен кулга алырга тырыша. Өстәлгә килә, газеталар арасындагы катыргыга күзе төшә. Ала, укый.

Шамил. «Мууу... сыерлар сүзе бууу...» Лемара!

Икенче бүлмәдән Лемара чыга. Без аның кичә кич Җәүдәт белән очрашып та аның белән сөйләшергә теләмәгән кыз икәнен таныйбыз.

Шамил. Монда кем булды? Кем калдырган моны?

Лемара. Белмим шул.

Ш а м и л. Теңкәгә тиделәр. Әле килгәндә генә капкага ябыштырганын куптарып ыргыткан идем. *(Монысын да ертып ыргыта.)*

М ә й с ә р ә *(Лемарага).* Ачулы чагына туры килдем, ахры.

Ш а м и л. Сводка? *(Ала, карый. Йодрыгы белән өстәлгә сугып куя.)* Чорт! Сиңа нәрсә, сеңелем?

М ә й с ә р ә *(Лемара кереп киткәч).* Хәсәнев абый, үзегез беләсез микән, юк микән, бездә, фермада диюем инде, ярамаган эш эшләнә бит.

Ш а м и л. Нинди эш ул тагын?

М ә й с ә р ә. Тана сыерлар турында әйтүем. Инде алар менә сыер бит, сөтен савабыз. Ә үзебез аларны һаман да танага исәпләп йөртәбез.

Ш а м и л *(тагын кәефе кырылып).* Нигә исәплисез соң?

М ә й с ә р ә. Без дигәч тә, без түгел инде ул. Бригадир шулай итә, Низами абыйны әйтүем.

Ш а м и л. Э, чорт.

М ә й с ә р ә. Ярамый бит болай, Хәсәнев абый, шулай бит. Алдау булып чыга. Кемне алдыйбыз?! Сез инде, зинһар, Низами абыйның үзенә сиздерә күрмәгез. Минем сезнең янга килүемне дим. Сизеп алса, көн күрсәтмәс. *(Ишек артында аяк тавышлары.)* Низами абый бит ул...

Урам ишегеннән Низами үзе килеп керә, Мәйсәрә каушап кала.

Исәнмесез, Низами абый.

Н и з а м и. Син нишләп йөрисең монда?

Ш а м и л. Сводканы күрдеңме? Бүгенге көндә һәр сыердан кимендә яртышар литр сөт артырга тиеш!

Н и з а м и. Булыр микән?

Ш а м и л. Мин әйткәч булыр! Әйтәм икән су яна дип, янарга тиеш! *(Мәйсәрәнең шыпырт кына, сиздермичә генә чыгып китәргә юнәлгәнен күреп.)* Сеңелем, ашыкма әле син. *(Низамига.)* Сөт, сөт, сөт! Сөт кирәк, бүген кирәк!

Н и з а м и. Тырышырмын. Йөгердем. Боермак сездән, йөгермәк бездән!.. *(Хисапчы бүлмәсенә уза.)*

Ш а м и л. Ярар, сеңелем, туры үземә килеп әйтүеңә рәхмәт. Чарасын күрермен.

М ә й с ә р ә. Сез инде зинһар...

Ш а м и л. Ул яктан тыныч бул.

М ә й с ә р ә. Ачулана күрмәгез инде. *(Чыга.)*

Низами бүлмәдән әйләнеп чыга.

Ш а м и л *(хәзер үк әйтмәскә уйлаган иде, түзә алмады).* Ул таналарың белән нинди махинация корасың анда?!

Н и з а м и. Бу кыз шул турыдамыни әле?

Ш а м и л. Сүз аның турында бармый!

Н и з а м и. Ни җитми ул Мәйсәрәгә! *(Тәрәзәдән күреп.)* Директор килә.

Ш а м и л. Эшчеләр белән сөйләшеп тора. Фикер туплый. Ике көн йөрде, әле җитмәгән күрәсең. Менә, килеп керер дә, бер сүз әйтми, йөрергә тотыныр, ишекле-түрле. Синең җаныңны газаплап. Аннан придираться итәргә тотыныр. *(Тешен кысып.)* Гаеп эзли башлар.

Н и з а м и. Дөнья шулай корылган инде. Безне сез орышасыз, сезне ул. Аны югарыдагылар. Ә бит киресенчә булуы да ихтимал иде. Моннан ярты ел элек дим. Директорга кеше эзләгәндә. Без сезне куялар дип уйлаган идек тә инде. Күрәсең, югарыда аның бер танышы артыграк булган. Сезнеке артык булса...

Ильяс керә.

Ильяс. Сәлам бирдек.
Низами. Исәнмесез, Ильяс Гаязович.

Ильяс борчулы һәм ачулы. Ишекле-түрле йөренә башлый. Әйтерсең, нидән тотынырга белмичә азаплана.

Ильяс. Бригадаларда булдым. Әйе... Язгы чәчү борын төбендә. Ә ремонт бетмәгән.

Шамил. Беткән, Ильяс Гаязович. *(Сводканы күрсәтә.)*

Ильяс. Миннән киткәнче — иясенә җиткәнче. *(Тагын йөренә.)* Ничек соң бу болай булып чыга, егетләр, ә? Эшләр мактанырлык түгел бит. Һаман шул хәл, үзгәреш юк та юк. Терлекләрнең нәселе турында...

Шамил. Кайгыртмыйбыз!

Ильяс. Производствоны механикалаштыру турында...

Шамил. Уйламыйбыз!

Ильяс. Җирдән алабыз...

Шамил. Ә үзенә бирергә теләмибез!

Ильяс. Әйе, теләмисез! Менә нәтиҗә: совхозда ике бүлекчә...

Шамил. Икенчесендә эш гөрләп бара...

Ильяс. Гөрләп бара!

Шамил. Ә бирерә — беренчесендә — һаман да сөйрәләләр.

Ильяс. Җир бер үк. Аларда да, сездә дә. Ә убыток белән эшлисез. Ни өчен?!

Шамил *(кызып китеп)*. Ишеткән сүзләр, Ильяс иптәш. Күп мәртәбә ишеттек инде. Колак тонып бетте. Килгән берегез шуны көйли. Тирги дә өйрәтә, өйрәтә дә тирги. Яңадан яңа таләп куя. Артта калган хуҗалык булмаска тиеш, теге дә бу. Тиргәгәнгә карап кына эш барса иде! Сүздән чабата да үреп булмый ул. Тиргәве җиңел, эшләве читенрәк.

Ильяс. Әйе, дөрес әйтәсең, дөрес, болай ярамый. Ярамый, ярамый. *(Уйга кала.)*

Шамил. Булган ди берәүнең ике хатыны. Берсе — карт, икенчесе — яшь. Яшь хатыны моның көн саен ак чәчләрен чүпли икән, ә карт хатыны — карасын. Пеләш булып калган бичара. Мин дә шуның хәленә калдым инде. Бер якта — халык, икенче якта — сез. Икегез ике якка тартасыз. Ни өчен әле монда бер Хәсәнев кенә гаепле булып калды?

Ильяс. Юк, мин үземне дә күләгәдә калдырырга җыенмыйм.

Шамил. Калдырмасаң, менә шул: без арт тәгәрмәчләр. Алгылары — сез. Ал тәгәрмәч кайдан барса, арт тәгәрмәч шуннан тәгәри.

Ильяс. Алайса инде син эздән чыкма. Күпме сүз сөйләнде, киңәш ителде, бергәләп күпме план кордык, ә нигә үтәлми?

Низами. Һәр кушылган эшне үтәп барып булмый инде аны. Униннан берсе үтәлсә дә, шөкер итәрсең. Шуңа күрә аны күбрәк итеп кушалар да. Запас белән. Максимумлап.

Ильяс. Алайса, минимумы: күп дигәндә бер ай эчендә карусель төзелеп беткән булырга тиеш.

Шамил. Булмый.

Ильяс. Булдырырга кирәк!

Низами. Ике айда эшли алмаганны, бер айда?

Ильяс. Ул чагында унбиш көндә!

Шамил. У...

Ильяс. Аңлыйсызмы, сездә бит бер кеше эшлисе эшне дүртәрләпбишәрләп эшлиләр. Бу хәлгә күпме түзеп торырга мөмкин?

Шамил. Андый зур эшне башкарып чыгарлык кешеләрем юк. Гомумән, совхоз җитәкчеләре аңларга тиеш: бу бүлекчә иң авыр участок. Җыен эшлексез, бушбугаз, җыен жулик җыйналган бирегә. Бу-

затерлар оясы. Кайсы яла яга, кайсы сакал үстерә, кайсы намусын аракыга саткан.

Җилләнеп Җәүдәт килеп керә, тыны кысылган.

Шамил. Миңа берсе. Сиңа нәрсә?

Җәүдәт. Икегез дә биредә чакта, минем мәсьәләне хәл итәрсез дип кердем.

Шамил. Итәрбез, итәрбез.

Җәүдәт. Алай булгач...

Шамил. Без буш түгел.

Җәүдәт. Мин эшсез йөрим.

Шамил. Кайгырма, сиңа эш табарлар.

Җәүдәт. Мин таләп итәм. Юкса мин...

Шамил. Ну, Мингалиев. Синең фамилияң тикмәгә Мингалиев түгел. Мин-минлек көчле синдә. Күрәсең, эш белән утырабыз.

Җәүдәт. Белегез, озак көтә алмыйм *(Кулындагы урындыгын өстәл астына этеп җибәрә. Ул Шамилнең аягына бәрелә. Шамил аягын тотып сикереп тора. Җәүдәт чыгып китә).*

Шамил. Судка барам. Бүген үк бирәм. Синең рөхсәтең кирәк, ризалык бир.

Ильяс. Юк, ярамый. Суд белән уйнамыйлар!

Шамил. Ул җинаятьче. Двигатель аның эше.

Ильяс. Ышанмыйм, охшамаган.

Шамил. Син минем кул-аягымны бәйлисең. Эшләргә комачаулыйсың. Башкаларга сабак булсын өчен генә дә аны утыртырга кирәк.

Ильяс *(кызып)*. Кешеләргә карата синдә әзрәк кенә булса да ышаныч бармы?

Шамил *(телефонда номерлар җыя башлый)*. Синең килгәнеңә ярты ел. Мин бераз алданрак килгән. Кемнең кем икәнен яхшырак беләм. Кайда кыек ята — карап кына йөриләр. *(Трубкага.)* Ә? Юк ла, сиңа түгел лә. *(Трубканы куя.)* Каравылчы өстенә каравылчы куйдым, йозак өстенә йозак салдым...

Ильяс. Шулай... Кешеләрнең күңелләрен йозаклап бетергәнсең *(Ишекле-түрле йөри.)* Юк, Шамил, син кешеләргә ышанмыйсың. Шуңа күрә килеп чыга да: механик ат җигә, җир яраткан кеше урманда эшли, урман яратканы фермада.

Шамил. Кемнең нәрсә яратканын сорашып йөрергә вакытым юк. Миңа бүген план үтәргә кирәк. Подумаешь анда, механик ат җигә. Бүген кирәк икән — әтәч җигәр, эт җигәр!

Ильяс. Бүген? Менә, чуалган йомгакның очын таптык шикелле. Бөтен тырышлык, бөтен ыгы-зыгы бүгенге өчен генә. Иртәгәге көнне курмичә, киләчәккә караш ташламыйча.

Шамил. Иртәгә өчен ишәк кайгырсын.

Ильяс. Инде ишәк тә кайгыртырга тиеш икән, безне әйтеп тә торасы юк. Юк, дус кеше, син кешеләргә ышанмыйсың.

Сәрьян *(урыныннан кузгала)*. Безгә караганда, әтәч белән ишәккә күбрәк ышана ул.

Шамил. Ну-ну-ну, син нәрсә, курше?!

Сәрьян. Дөрес түгелме әллә?

Шамил. Тикмәгә генә «шайтан» кушаматы такмаганнар сиңа. Эчеңдә шайтан яши синең.

Сәрьян. Туры әйткән туганына ярамаган ди шул.

Шамил. Ни өчен син әйткән генә туры булып чыга әле. Бәлки кыектыр.

Сәрьян. Кыек булса, йөрәгеңә барып кадалмас иде. Значит туры.

Шамил. Ну, Сәрьян абый, кайнатасың саруымны.

Сәрьян. Чәйни сода эч. *(Чыгып китә.)*

Шамил. Ни булган аңа?

Низами. Билгеле инде, хәтере калган.

Шамил. Үпкәләгән. Кемгә, ни өчен? Аңламассың. Керер дә утырыр, әйтәсе йомышын да әйтмәс. Алып куй шул урындыкны!

Низами үтешли Сәрьян утырган урындыкны ишек янына алып куя да чыгып китә.

Ильяс. Үпкәләгән. Авылның аксакалы үпкәләгән. Булмый. Болай булмый, нәрсәдер эшләргә кирәк, ничектер чарасын табарга кирәк. Бүген үк! Хәзер үк! Болай булмый.

Шамил. Менә нәрсә, бүлекчәдә эш начар бара икән, димәк, управляющий гаепле. Үз вазифасын үти алмый дигән сүз. Әгәр шулай икән, нигә баш катырырга? Тотарга да урыныннан алып ыргытырга кирәк. Чәнчелеп китсен! Кеше беткәнмени?!

Ильяс. Алып ыргытуы җиңел.

Шамил *(бер карарга килеп)*. Менә нәрсә, без электән танышлар. Бер полкта сугыштык. Син безнең өй дусты. Шушы якынлык шәят миңа хак бирәдер: ачыктан-ачык әйтергә телим.

Ильяс. Тыңлыйм.

Шамил. Минем белән синең нинди алыш-бирешең бар, ни өчен үчле син миңа? *(Ильяс Шамилгә текәлә, әмма бер сүз дә әйтми.)* Менә син кешеләр турында кайгыртуны яклап сөйләдең. Ә нигә син миңа карата киресен эшлисең. Мин дә кеше бит. Синнән бер баскычка түбән булсам да.

Ильяс. Ачыграк әйт, мин нишлим?

Шамил. Пран-заран китерәсең, бөтен эшемне юкка чыгарасың.

Ильяс. Эх, Шамил, Шамил! Мин бу бүлекчәдә икенче көн йөрим. Эшнең асылына төшенергә, сәбәпләрен ачарга йөрим. Чөнки, бу бүлекчә совхозның иң әһәмиятле участогы. Биредә эш барса, бөтен совхозда барачак дигән сүз. Менә ни өчен йөрим. Сиңа ярдәм итү өчен.

Шамил. О, әле синең ярдәмең шушымыни? Ярдәм булмаганы ничегрәк булыр икән. Әллә инде...

Ильяс. Әйтеп бетер!

Шамил *(кул селти)*. Калсын!.. Менә бит хәзер дә күпме эш кушасың. Булдырып булмаслык эш. Булмаслыгын син аның үзең дә бик яхшы беләсең, ә кушасың. Чөнки үзең эшлисе түгел. Югарыдан гына кушып ятуы җиңел бит ул.

Ильяс *(үзен көчкә тыеп)*. Булдырып булмаслык эш дисең? Үзе эшлисе булмаганга куша дисең?

Шамил. Батырырга икән, бөтенләй батырырга дип!

Ильяс. Алай... Кая счетоводың? *(Кычкыра.)* Лемара! *(Пальтосын салып, урындык өстенә ташлый. Лемара керә.)* Ал кәгазь. Утыр. Яз: Совхоз буенча приказ. *(Лемара язарга утыра.)* Беренче. Җитәкчелектә җитди ялгышлыклар җибәргәне өчен... Юк, монысын боз. *(Уйлап торгач.)* Яз. Икенче эшкә күчүе сәбәпле, беренче бүлекчә управляющие иптәш Хәсәнев Шамил Саттаровичны эшеннән азат итәргә! *(Лемара нишләргә дә белми, бер Шамилгә, бер Ильяска карый.)*

Шамил. Мине эштән алырга? Мине?

Ильяс *(Лемарага)*. Яз, яз! *(Лемара язарга мәҗбүр.)*

Шамил. Шалишь, брат, болай бик җиңел генә булмый ул. Хәсәнев уенчык түгел, Хәсәнев диләр аны! Бөек Ватан сугышы ветераны, капитан! Күкрәге тулы орден, шуның өстенә югары белемле агроном! Муеныңны сындырырсың!

Ильяс. Яз. Икенче. Беренче бүлекчә управляющие эшен совхоз директоры Айтуганов Ильяс Гаязовичка йөкләргә. Бер айлык сынау шарты белән. Өстә: әгәр дә кыска вакыт эчендә эшне юлга салып җибәрә алмаса, ул бүлекчә белән дә, совхоз белән дә җитәкчелек итү эшеннән азат ителәчәк. Точка.

Шамил. Ох, ничек тиз генә, ә! Урынга кеше дә табылды. Кызык бу, кызык. Между прочим, бу синең алдан уйланган планың. Син бит инде парткомда бу мәсьәләне кузгаткан булгансың.

Ильяс. Нәрсәне?

Шамил. Совхоздан бүлекчәгә күчү мәсьәләсен.

Ильяс. Кузгаткан идем.

Шамил. Соң?

Ильяс. Принципта каршы булмадылар. Кызыклы идея дип тапканнар иде. Ләкин моңарчы мин үзем карар кылмаган идем әле.

Шамил. Үзең турында кайгырткансың, ә минем турыда уйламадың? Все-таки дустың бит. Бер полкта сугышкан. Эштә дә төшеп калганнардан түгел бугай. Колхозны күтәргән, райисполком председателе булып эшләгән. Һәм начар эшләмәгән. Шул кешене оныттыгыз?

Ильяс. Онытмадык. Синең турында да фикер бар иде.

Шамил. Нинди фикер? Кая, кем итеп?

Ильяс *(Лемарага)*. Яз. Өченче. Совхоз директоры эшләрен башкаручы итеп иптәш Хәсәнев Шамил Саттаровичны билгеләргә.

Бу юлы Шамил тынып кала, бераздан гына Ильяска күтәрелеп карый.

Ильяс *(Лемарага)*. Бүгенге числоны куй. Подпись. Булды. Ярый, бар. Рәхмәт. *(Лемара боларга карый-карый, урамга чыгып китә.)* Я, тәбрик итәм!

Шамил. Барып чыкмый. Директорны югарыдан билгелиләр.

Ильяс. Югарыда килешенгән мәсьәлә. Аннан соң бит, мин сине исполняющий обязаностей итеп кенә билгелим. Директор эшләрен башкаручы. И. О. Үзем отпускада чакта. Отпускадан соң күз күрер.

Шамил. Син бит биредә.

Ильяс. Булса соң! Кеше отпускасын теләсә кайда үткәрер. Балык тотаммы, монда йөримме — анысы инде минем эш. *(Папирос чыгара, Шамил үрелеп бер папирос ала. Ильяс шырпы сызып, башта Шамил папиросын, аннан үзенекен кабыза.)*

Шамил. И. О.?

Ильяс. И. О.!

Шамил. И. О.! Ярый. Килештек. *(Өстәл янына килә, урындыкны рәтләп куя да, Ильяска ымлый.)* Рәхим итегез! *(Ильяс килеп утыргач, көлеп җибәрә.)* О! Управляющий!.. Һем... Мин синең урында эшли алырмын. Менә син нишләрсең икән җыен бузатерлар белән! *(Тәрәзәдән күреп.)* Әнә берсе килә.

Урамнан Кәүсәрия белән Лемара керә.

Лемара. Кәүсәрия апа, иртәгә килсәң ничек булыр икән.

Кәүсәрия. Мин директорга. Директор янына мин.

Лемара. Эшнең тыгыз вакыты.

Кәүсәрия. Тыгыз булса бушатырсыз.

Шамил. Алайса, утырып тор, әнә.

Кәүсәрия. Утырмый торсын әле. Утыртып, ачуымны бастырмак буласыңмы? Утырмыйм. *(Ильяс каршына барып утыра.)*

Ильяс *(көлә)*. Тәки утырттылар бит үзеңне. *(Кәүсәрия шунда ук сикереп тора.)* Я, Лемара, синең цифрлар белән дә танышыйк. *(Бүлмәгә уза. Кәүсәрия аның артыннан кермәкче була.)*

Лемара. Син кая, Кәүсәрия апа?

Кәүсәрия. Мин директор янына килдем, аңа гына әйтә торган сүзем бар. *(Шамилгә кулмәк итәгән күрсәтә.)*

Шамил. Тыңлыйм сине, Кәүсәрия ханым.

Кәүсәрия. Юк, мин директорның үзенә. *(Бүлмәгә кермәкче.)*

Лемара. Әнә бит, директор сине тыңларга әзер тора.

Кәүсәрия. Ничек? Нәрсә бутыйсың?!

Л е м а р а. Бутамыйм. Бүгеннән совхоз директоры Шамил Саттарович. *(Бүлмәгә кереп китә.)*

К ә ү с ә р и я. Ба-а-а... дөнья кулиса — бер әйләнә бер баса. Күптәннән бирле сөйләнеп киләләр иде, карусиль дигәннәре шушы буламени инде?

Ш а м и л. Я, ни йомыш?

К ә ү с ә р и я. Директор?.. Һе... Мин, иптәш директор, управляющий өстеннән жалоба белән килгән идем.

Ш а м и л. Элекке управляющий өстеннәнме?

К ә ү с ә р и я. Әйе, элеккесе өстеннән. Минә хөкем итегез. Ул хаклымы, минме? Аның өй түбәсе калай, ә минеке...

Ш а м и л. Салам.

К ә ү с ә р и я. Әйе, салам. Үзегез дә беләсез икән.

Ш а м и л. Элекке управляющий сөйләгән иде, исерек ирнең телчән хатыны ярамаган сүзләр сөйләнеп йөри дип.

К ә ү с ә р и я. Ә-ә, сөйләргә дә өлгергән икән.

Ш а м и л. Өлгерде.

К ә ү с ә р и я. Ә бу эшкә яңа директор ничек карар икән соң?

Ш а м и л. Мин элекке управляющийга әйтермен, үзенең калай түбәсен куптарып алып сиңа бирер.

К ә ү с ә р и я. Шулаймы, менә рәхмәт. Бик рәхмәт инде, иптәш директор. Ә ул ничек: ферма бозауларын яхшы тәрбияләгәнем өчен, премия итеп бирәсезме инде аны, куптарып алган калай түбәне дим?

Ш а м и л. Калай түбә сиңа күзләрең кара булган өчен бирелә.

К ә ү с ә р и я. Ә-ә... рәхмәт инде, рәхмәт, бик рәхмәт. Ярый, вакытыгызны алдым. Китим инде. *(Кире борыла.)* Ә, ни... иптәш директор, элекке управляющийны очратсагыз, үзенә әйтегезче, югарырак урынга куйсалар да, бездән китүенә бер дә офтанмыйбыз. Күптән вакыт иде. Иткән яхшылыкның кадерен белми торган кеше булып чыкты. Җүнсез бәндә иде мәхлүк.

Ш а м и л. Ну-ну-ну! Ну!!!

К ә ү с ә р и я *(кеткелди)*. Сезнең турыда әйтмим ич, аның турында.

Ш а м и л. Җитте, җитте!

К ә ү с ә р и я. Киттем, киттем. Менә ич китеп барышым. Исән булыгыз.

Чыгып китә. Урамнан М ә р ь я м белән Д и л ә р а керә. Диләра кулында чемодан.

М ә р ь я м. Ни булды монда, нинди өермә узды? Шамил?

Ш а м и л. Укыгыз. *(Шамил приказны алып бирә, Мәрьям белән Диләра күз йөртеп чыгалар.)* Менә хәзер күреп карасыннар инде Шамилнең кемлеген, булдыра аламы ул, юкмы? Ох, күрсәтергә кирәк хәзер үземне, ничек кенә булса да күрсәтергә. Көн-төн эшләргә. Көн-төн! Танырга тиеш алар Шамилне, аңларга тиешләр: зур карабка зур дингез! Ха-ха-ха!.. *(Ильяс бүлмәдән чыга.)* Ильяска караганда Шамил булдыклырак булып чыкса, ә?! Ох, терсәген тешләмәкче булыр булуын Ильясың! Ох, биер әле минем кубызга, ох, биер! *(Механик рәвештә радионы бора. Ә анда камаринский музыкасы яңгырый.)* О, камаринскийга биетәм мин аны!

М ә р ь я м. Ильяс Гаязович, ни өчен болай эшләдегез инде, Шамилне кимсетү өченме?

И л ь я с. Ярдәм итү өчен.

М ә р ь я м. Эшне зурга җибәргәнсез, әле соң түгел, әллә кире аласызмы?

Ш а м и л. Ә юк, кире алышу юк инде. *(Приказны тартып ала.)* Ильяс иптәш, приказын биргәч, имзасы да кирәк булыр инде аның.

И л ь я с. Ә, әйе-әйе. *(Кул куя. Аннан Шамил приказны ала да, көлә-көлә, өреп кенә киптереп, бүлмәгә кереп китә.)*

Д и л ә р а *(ирония белән)*. Нишләп кире алсын ди, ул бит бу адымын Гагановадан үрнәк алып атлаган. Хәтта әле арттырып та җибәргән. Гаганова бер бригададан икенчесенә генә күчә, ә Ильяс абый югары урыныннан түбәнгесенә төшә. Бу яңалык түгелмени?! Менә күрерсез, аның турында газеталарда язарлар, портретын стеналарга эләрләр. Ильяс исеме телдән төшмәс. Шулай бит ул, дан-дәрәҗә дигән нәрсә кешене исертә бит ул.

И л ь я с. Диләра, телеңә ни килсә шуны әйтә аласың, әмма тыңлый бу дип өметләнмә. Мин сине ишетмим.

Д и л ә р а. Кая инде ул безне тыңларга. Аның өчен әз генә булса да ихтирам кирәк. Ә ул синдә бер генә тамчы да юк икән. Абыйга карата да, миңа карата да.

И л ь я с *(колакларын томалап)*. Ишетмим.

Д и л ә р а. Әйе, синең бу адымың халык арасында вызов булып, өндәү, нәрсәгәдер чакыру булып яңгырар. Директорлары үзе бүлекчә эшенә алынган икән, әлбәттә, купләрнең йоклаган намуслары уяныр. Әмма сиңа каршы баш күтәрүчеләр дә аз булмас.

И л ь я с. Шуларның берсе — син?

Д и л ә р а. Мин!

М ә р ь я м. Я, зинһар житәрегез. Аерылышыр алдыннан...

И л ь я с. Кем аерылыша, кая? Юк, Диләра беркая да китми.

М ә р ь я м. Ильяс Гаязович, ул бүген Казанга...

И л ь я с. Диләра, уйлама да.

М ә р ь я м. Уйланылган инде.

И л ь я с *(Диләрага)*. Син нәрсә, тиздән чәчү башларга торабыз, шундый чакта агроном ташлап качсынмы?! Юк, китмисең.

Д и л ә р а *(эчке шатлык белән)*. Җибәрмисең?

И л ь я с. Җибәрмим.

М ә р ь я м. Кияүгә чыкканда, кыз баланы берәү дә тота алмый. *(Диләрага.)* Ник дәшмисең, әллә инде үзең китәргә теләмисең?

Д и л ә р а *(елмаеп)*. Әнә ич, җибәрми.

М ә р ь я м. Ул җибәрми дип торсаң. *(Кычкыра.)* Шамил!

Ш а м и л *(бүлмәдән чыга)*. Фу, бүген хатын-кыз тавышыннан колагым тонып бетте. Барыгыз әле, бар, өйгә кайткач чәрелдәрсез.

М ә р ь я м *(үпкәләп)*. Рәхмәт. Әйдә. *(Диләраны алып чыгып китә.)*

Телефон шалтырый. Шамил трубканы ала.

Ш а м и л. Әйе? Управляющийны? Тыңлыйм... Ә, юк! *(Трубканы Ильяска суза.)* Управляющийны. Казаннан.

И л ь я с *(трубкага)*. Тыңлыйм. Ильяс Айтуганов... Ах, бу сез? Бирәдә юк шул. Әле генә кайтып китте.

Ш а м и л. Кемне, әллә Диләраны сорыйлармы? *(Тәрәзәгә ташлана.)*

И л ь я с *(трубкага)*. Юк, бара алмый ул Казанга, бармый. Көтмәгез.

Ш а м и л. Туктале син!

И л ь я с *(трубкага)*. Диләра Казанга барырга теләми, Шулай, Сәгыйт Баймурзин иптәш. Теләми.

Ш а м и л. Стоп! Син нәрсә?! Каяле үземә. *(Трубканы тартып ала.)* Сәгыйт, Сәгыйт! Ало, Казан, Казан!

И л ь я с *(Шамилнең колагына)*. Пи-пи-пи... Трубканы элде инде.

Шамил дә трубканы куя. Ильяска борыла. Пауза.

Ш а м и л. Ни хакың бар? Ни өчен әле син Диләра өчен җавап бирәсең?

И л ь я с. Ул минем агрономым.

Шамил. Агроном? Ай-һай, син аны агроном булганы өчен генә үз янында калдырасың микән. Монда башка сәбәп юкмы? Күптәннән сизеп киләм, син аның йөрәген яулап алырга омтыласың.

Ильяс. О-о, менә син ни турында.

Шамил. Әледән-әле киногa чакырасың.

Ильяс. Ул кино карарга ярата ич.

Шамил. Кичә булдымы, биергә аны сорыйсың.

Ильяс. Ул җиңел бии.

Шамил *(кызып китеп).* Онытмаска иде, аның хәтле кызың бар инде. Сиңа 40 яшь, аңа 26.

Ильяс. Аның янында мин үземне дә 26 яшьлек итеп хис итәм.

Шамил. Аның күңелен аздырырга, юлдан яздырырга ирек бирмәм. Калдыр Диләраны.

Ильяс. Бу синең беренче боерыгыңмы, иптәш директор?

Шамил. Директор буларак түгел, ә Диләраның тәрбияләп үстергән абыйсы буларак, таләп итәм. Аның сүз биргән кешесе бар. Алар бер-берсен яратышалар.

Ильяс. Бәхәсләшмим.

Шамил. Син аңа бәхет бирә алмыйсың. Аңа түгел, син үзеңә дә бәхет китерә алмыйсың. Ә мин сеңелемнең бәхетле булуын телим.

Ильяс. Әйе, мин аны яратам. Үзем дә сизми калдым, кайчан шулай йөрәккә кереп утыргандыр... Ярар, әгәр шулай кирәк икән, аның бәхете өчен кирәк икән... Тыныч бул, үземне кулга алырмын. Тешемне кысып. Сеңелеңнең күңелен аздырмам.

Шамил. Димәк, җибәрәсең?

Ильяс. Агрономсыз авыр булыр булуын... Ярый, китсен. Тотмыйм.

Шамил кулын суза, Ильяс аны кыса. Аннан Шамил киемен алып ишеккә юнәлә.

Ильяс. Шамил, син мотоциклыңны калдырасыңдыр бит?

Шамил. Ах, әйе, синең «Волга» машинаң миңа күчә бит хәзер. *(Кесәсеннән мотоцикл ачкычын алып, Ильяска суза.)* Нәрсәгә ул миңа тр-тр. *(Китә.)*

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Контора. Сәрьян карт керә. Гадәтенчә утыра торган урынында урындыгы булмагач, як-ягына карана да, ишек янындагы урындыгын үз урынына алып килеп куя. Телефон шалтырый. Бара да трубкасын күтәреп, кире салып куя.
Ильяс кайтып керә. Кожанын сала.

Ильяс. Ай-яй яз быел куыра. *(Газеталар арасындагы Марсельнең әлеге катыргысына күзе төшә. Укый, көлә. Аннан икенче ягына үзе нәрсәдер язып куя. Тәрәзәгә бара.)* Хәмит, бар әле, Диләра апаңны чакырып кил әле. *(Сәрьянга.)* Җитте сиңа анда — читтә утырырга. Кил, йомышың булса, каршыма утыр.

Сәрьян. Утыртуын сез башта йомшак утыртасыз, беләм. Нишләргә исәп? Двигательне эзләүдән тотынасыңмы?

Ильяс. Юк, эзләмим. Двигатель миңа үзе килер.

Сәрьян. Ай-һай.

Ильяс. Монда двигатель генә яшерелмәгән, Сәрьян абый, кешеләрнең йөрәкләре яшерелгән. Йөрәкләр! Миңа башта кешеләрнең йөрәкләрен ачарга кирәк. Күңелләрдәге боз эресен, үпкәләүләр җилгә очсын.

Урамнан Лемара керә.

Сәрьян. Әллә әйтимме дигән идем. Күңелем сизенә, двигатель авылдан чыгып китмәгәндер. Җәүдәтне чакыртып, стенага терәп сорасаң...

Лемара *(борчылып)*. Каныктылар бит шул Җәүдәткә. Инде сиңа, Сәрьян абый, олы кешегә, үзең күрмәгән нәрсәләр турында сөйләнеп йөрү килешмидер.

Сәрьян. Юк, минем әйтеп кенә каравым.

Ильяс. Әйтеп тә карама, Сәрьян абый. Берәүне дә стенага терәргә җыенмыйм. Миңа күңелләрнең якынаюы, йөрәкләрнең ачылуы кирәк. Йөрәкләр килсә, двигатель үзе килер.

Сәрьян. Килер. Тот капчыгыңны.

Ильяс. Менә күрерсең.

Сәрьян. Килерме?

Ильяс. Килер.

Сәрьян. Әйдә, менә мә: әгәр дә килә икән, чуар тавыгымны суям. Янына яртыны куям.

Ильяс *(Сәрьянның кулын кысып)*. Шулаймы? Әйдә. Әмма сүзеңнән кире кайтмаска.

Урамда мотоцикл тавышы. Альберт керә.

Альберт. Сәлам! Үзегезне туры китерүем шәп булды.

Ильяс. Ә, саулыкмы? Әйдә, нинди эш белән?

Альберт. Сезгә ярдәмгә килдем.

Ильяс. Ярдәмгә?

Альберт. Двигательне табып бирергә!

Ильяс *(үзгәрде)*. Бу мәсьәләдә миңа синең ярдәмең кирәкми.

Альберт. Ә сез борчылмагыз. Мин аларның эзләренә тиз төшәрмен. Бөтен авылның астын өскә әйләндерермен, җиде кат җир астыннан актарып чыгарырмын. Алар минем менә монда булырлар! *(Кулын йодрыклап күрсәтә.)*

Ильяс. Юк, юк, уйлама да, барып чыкмый. Кешеләр арасына шундый ният белән? Юк, мин сине авылга җибәрә алмыйм. Халыкны айкасы-чайкасы юк. Болай да инде...

Альберт. Как тоесть?! Мин конкрет задание белән килдем. Авылның астын өскә әйләндерергә, әмма двигательне табарга! Акт төзергә, кирәк икән, җинаятьчене кулга алырга.

Ильяс. Бу эшне син минем үземә калдыр. Двигательне мин үзем табармын. Ул миңа үзе килер.

Сәрьян. Һе-һе-һе... Болай булса килә инде.

Ильяс. Ә син, Альберт, бар, мотоциклың суынганчы тай моннан. Башка эшең бардыр.

Альберт. Юк, мин китә алмыйм. Мине Шамил Саттарович җибәрде.

Ильяс. Шамил?

Сәрьян. Һе, тынычлыкта калдырырга уйламый. Үзе юк, ә күләгәсе бире дә.

Ильяс. Мин сине үзем кире җибәрәм. Бар.

Альберт. Гафу итегез, аның боерыгын сез үзгәртә алмыйсыз. Ул директор, ә сез... гафу итегез.

Ильяс. Ах да, ул миңа начальник бит хәзер. *(Көлә.)*

Лемара. Утырыгыз, Альберт абый, сулу алыгыз, аргансыздыр. Фуражкагызны алып куйыйм?

Альберт. Рәхмәт. Рәхмәт, Лемара. Пожалуйста.

Лемара Альбертның кепкасын шкафка куя да шкафны бикләп үк ала.

Альберт. Кешеләрне авыл Советына чакыртыйкмы? Вакытым аз. Иртәгә иртүк китәргә кирәк. Шуңанчы...

Ильяс. Авылның төбен күккә асам дисеңме?!

Альберт. Анысы минем эш.

Сәрьян. Актарырга да, айкарга гына синең исәбең, алла бәндәсе. Шул гадәтләрең өчен, халык белән талашып йөргән өчен сине эшеңнән чыгаралар ди түгелме соң?!

Альберт. Әлегә чыгарылмаган.

Сәрьян. Бүген булмаса, алайса, иртәгә чыгарырлар. Шуңанчы айкап калыйм дисеңмени?! Халыкны авызлыклап тоту заманы үтте инде, энем. *(Чыгып китә.)*

Альберт. Нинди авызлык, причем монда авызлык?! Кем ул, әллә аның үзенең катнашы бармы?

Ильяс *(телефон шалтырата, трубкага)*. Мастерскойны! Садримы? Ничек анда сезнең? Булдырдыгызмы? Ә теге тракторны? Анысын да? Ай, рәхмәт, ай, молодцы! Әмма, Садри, чәчкечләрне яңадан карарга! Бел аны, синең җаваплылыкта!.. Өченче бригадагамы? Машина җибәрт. Ах, күпер? Күпер, күпер... Ат җиксеннәр. Өчне, дүртне җиксеннәр! Запчастьмы? Карале, син мотоциклда йөри беләсең бит? Ал минекен, элдерт сельхозснабка. Хәзер үк. Мин алар белән сөйләшкән идем. *(Трубканы куя. Альбертның Лемарага үзенең фотокарточкаларын күрсәтеп торуына игътибар итә.)* Лемара! *(Читкә алып, үзенә генә.)* Лемара, үзең сөйләшеп кара әле моның белән. Ул сине тыңлар шикелле. Аны халык арасына җибәрергә ярамый. Кешеләрне айкап йөргәнче, синең белән утырсын да — выжт — кайтып китсен. Буламы?

Лемара сиздермичә генә башын ия. Ильяс үз бүлмәсенә кереп китә.

Альберт. Миңа кешеләрне кем чакырта соң?

Лемара. Бүген безнең клубта кино. Кинодан соң танца. *(Тыпырдап ук ала.)*

Альберт. Ну? Мин кичкә кадәр эшемне бетерәм. Ә синнән сүз бирүеңне үтенәм: беренче вальс минем белән! Килештекме? Кая, шикле кешеләрнең барысын да авыл советына! *(Ишеккә юнәлә.)*

Лемара. Альберт абый! *(Альберт туктала.)* Сез юкка Ильяс абыйны тыңламыйсыз.

Альберт. Миңа Шамил Саттарович үзе...

Лемара. Ул ялгыша. Ул кешеләрне аңламый.

Альберт. Шамил Саттаровичмы? Аңламас! Аңламаган кешене директор итеп күтәрерләр идемени! Ә инде Ильяс Гаязовичка килгәндә, бик әйбәт җитәкче булса, урыныннан алып атмаслар иде.

Лемара. Ул үзе төште.

Альберт. Нәрсә?! Үзе теләпме? Ха-ха-ха... Төшәр!

Лемара. Төште шул менә.

Альберт. Төшкәндер, тәгәрәткәч. Кеше ышанмаслык сүзне дөрес булса да сөйләмә дигәннәр! Я, Марочка, кая... Беренче чиратта Җәүдәтне!.. Фамилиясе кем әле, Мингалиевме? Авылда микән?

Лемара. Җәүдәтме? Белмим, андый кеше юк бездә.

Альберт. Табарбыз! *(Ишеккә атлый.)*

Лемара. Альберт! *(Альберт туктала, Лемара нишләргә дә белмичә кала. Бераздан.)* Туктагыз, сез авырыйсыз түгелме соң?

Альберт. Каян алдың!

Лемара. Күзләрегез кызарган. Кая әле! *(Кул аркасы белән Альбертның битләрен, маңгаен тотып карый. Шул чакта Альберт аның кулын үбеп маташа.)* Әй!.. *(Чап итеп битенә сугып ала.)* Әйе, сез авырыйсыз. Мотоциклда килдегезме? Шул, шуның галәмәте, җилнекедер. Көчәеп китә күрмәсен, әйдәгез, миндә дару бар, эчегез, юкса танцага килә алмассыз.

Альберт. Сезнең кулдан булса, берне түгел бишне йотам. Авыр-

масам да йотам. *(Як-ягына каранып ала да, кеше юклыгына ышангач, Лемара артыннан бүлмәгә кереп китә.)*

Урам як тәрәзәдә Кәүсәрия башы күренә.

Кәүсәрия. Ильяс абый! *(Конторага керә, Ильяс белән очраша.)* Ильяс абый, җанкисәгем, премияңне әзерлә, таптым мин тегене.

Ильяс *(сагаеп)*. Нәрсәне?

Кәүсәрия. Двигательне. Безнең бәрәңге чокырына төшереп, өстен каплап куйганнар. Кем эшедер, белмим. Күрдем дә берәүгә дә сиздермәдем, туп-туры синең янга килдем. Участковой да монда икән. Кайда әле үзе?

Ильяс. Кәүсәрия, ашыкма әле, яхшылап кына тыңла әле мине.

Кәүсәрия. Тыңлыйм, Ильяс абый, ике күзем, тыңлыйм, җанкисәгем.

Ильяс. Алайса менә нәрсә: син ул двигательне күрмәдең.

Кәүсәрия. Ә?

Ильяс. Әйе, күрмәдең. Синең табуың, килеп әйтүең миңа кирәкми. Аңлыйсыңмы, миңа яшергән кешенең үзенең килеп әйтүе кирәк. Юкса харәп була бит. Аны коткарып калырга кирәк безгә.

Кәүсәрия *(аңлап)*. Ә-ә-ә.

Ильяс. Менә шулай. Күрмәдең син аны, Кәүсәрия.

Кәүсәрия. Шулай микәнни, күрмәдем микәнни?

Ильяс. Күрмәдең.

Кәүсәрия, Кара син аны, ә, күрмәгәнмен икән. Күрмәдем алайса?

Ильяс. Шулай килешик: күрмәдең.

Кәүсәрия. Ә-ә. *(Бармак янап.)* И-и, син миңа төтен җибәрмә, беләм мин, премия бирәсең килми. Юк, күрдем мин аны, Ильяс абый. Бер түбәлек такталарыңны әзерләп куй. *(Бүлмә ишегенә атлый.)*

Ильяс. Кәүсәрия!

Кәүсәрия *(кире борылып)*. Әү, Ильяс абый, карлыгачым.

Ильяс. Туктале, әйт әле, безнең ферма сыерлары җәйнең үзәгендә күпмешәр сөт бирә?

Кәүсәрия *(пафос белән)*. Җидешәр-сигезәр литрга җиткерәләр, иптәш директор.

Ильяс. Директор түгел. Ә синең үз сыерың бармы соң?

Кәүсәрия. Бар шунда корангыш нәмәрсә.

Ильяс. Начармыни?

Кәүсәрия. Начарның аргы ягы.

Ильяс. Сөтне күпме бирә?

Кәүсәрия. Тугыз-ун литр гына шул. Алыштырырга уйлыйбыз.

Ильяс. Алай икән.

Кәүсәрия бүлмәгә юнәлә, Ильяс аны тагын туктата.

Ильяс. Кәүсәрия!

Кәүсәрия. Әү, Ильяс абый! Ярый, ярый, килештек: күрмәдем.

Ильяс *(тәрәзәдән кемнедер күреп, тәрәзә аша кычкыра)*. Пруу!.. Әй, энекәш, туктат әле, кил әле, якынрак. Шуның өчен ат куасыңмы? Ни өчен ярты йөк кенә төядең?

Тыштан тавыш. Аркан кыска булды.

Ильяс. Ах, аркан кыска? Бармы, сал ременыңны. Мә минекен дә. Ялга! Бор атыңны кире, мондый эшеңне соңгы мәртәбә күрүем булсын! *(Урам ишегенә атлый.)*

Кәүсәрия *(Ильяс чыгуга)*. Әлбирт энем!

Альберт. Ни бар?

Кәүсәрия. Үзегез чыгасызмы, үзем керимме? *(Альберт бүлмәдән чыга. Урындыкка килеп утыра.)* Хәзер, Әлбирт энем. *(Урам ишегенә атлый да, кире борылып.)* Ә, исәнме, Әлбирт энем. *(Урамга чыгып, кара-*

*ныл, әйләнеп керә.)* Әлбирт энем, мин синең янга килдем. Бездә менә шундый эшләр булып китте бит. Бәйнә-бәйнә сөйләп бирим әле. Бүген шулай, бәрәңге чокыры буеннан үтеп барам... Тыңлыйсыңмы соң син, күтәр әле башыңны. Әлбирт энем, нишләвең бу, йоклыйсың түгелме соң? Кара, йоклап утыра. Йоклый, билләһи, йоклый. Әстәгъфируллa, участковой башың белән салып йөрмәсәң. Юк, салган да шикелле түгел. Лемара!

Лемара бүлмәдән чыга.

Л е м а р а. Нәрсә бар, Кәүсәрия апа?

К ә ү с ә р и я. Ни булды соң моңа? Урындыкка утырды да түнде. Әлбирт, Әлберттин дим, ач әле күзеңне, йокы чүлмәге.

Л е м а р а. Кара, нишләгән ул, арып килде микәнни?

К ә ү с ә р и я. Төн буенча кызлар артыннан йөриләр дә көндезен аягүрә йоклыйлар. Әлберттин, уян әле, ярдәмең кирәк. Ишетәсеңме син. *(Җилкәсеннән тотып селки.)* Ач күзеңне, дим. *(Альберт йокы аралаш башын күтәрә, күзен ача.)* Премия яна бит, премия!

А л ь б е р т. Янсын. *(Тагын башы салына.)*

К ә ү с ә р и я. Кара инде бу хәлне, йоклый. Ник шунда көлак төбендә туптан атмыйлар.

Л е м а р а. Ходаем икән, әллә ялгышлык миндә булды микән? Әллә мин аңа йоклата торган дару бирдем микән?

К ә ү с ә р и я. Ә?

Л е м а р а *(бүлмәгә кереп әйләнеп чыга).* Кәүсәрия апа, харап эш, мин аңа люминал биргәнмен. Әнигә дип алып куйган идем. Әни төннәр буенча йоклый алмыйча газапланып чыга. Ходаем икән, нишләдем мин, нишләдем. Суык тигәннән дип, белмичә йоклата торган дару биргәнмен бит.

К ә ү с ә р и я. Ишкәнсең икән ишәк чумарын. Болай булгач тиз генә уянуын көтмә дә инде.

Л е м а р а. Ичмаса берьюлы өчне йотты.

К ә ү с ә р и я. Ләгънәт. Шулкадәр комсызланмаса. Квартирда булса бер хәер. Йоклар иде шунда. Монда бит урам чаты шикелле, кеше өзелми. Нишләтәбез инде? Әйдә, булмаса синең бүлмәгә кертеп салыйк.

Л е м а р а. Әйдә.

К ә ү с ә р и я. Тот теге башыннан. Тфү, авырлыгын кара син аның.

Альбертны кузгатканнар гына иде, Альберт урындыгыннан шуышып идәнгә төште. Аякларын сузып бер киерелде дә, тезләрен җыеп, ике тез арасына кулларын кыстырып, рәхәтләнеп, изрәп йокыга китте. Әмма Кәүсәрия аңа йокларга ирек бирми. Колагын уып уята да, бармагы белән генә күтәрелергә куша.

К ә ү с ә р и я. Тор әле, тор. Әйдә-ле, бер сүз әйтәм. *(Альберт тора, честь бирел маташа.)* Анда кергәч, анда кергәч честь бирерсең.

Альбертны Лемара бүлмәсенә алып кереп китәләр. Урамнан М а р с е л ь керә. Тәрәзәдә Б ә н а т күренә.

*(Дәвамы бар.)*

*Әхмәт Юныс*

# ЗУР АШКЫНУ, ОЗЫН ГОМЕР ТУРЫНДА ҖЫР

Эшендә фаҗигале рәвештә, вакытсыз һәлак булган атаклы бораулау мастеры *М. М. Белоглазов* истәлегенә багышлана.

## Урал-йортның учагыннан

Урал-тауның кочагыннан
Табыла тимер, агыла күмер.
Урал-йортның учагыннан
Алды утны бу яшь гомер.

Урал-әнкә култыгында
Дәү төенчек... Кояштыр ул.
Биштәр генә бит улында —
Әмма йөзе ифрат горур.

Һай, бу чаклы охшар икән! —
Нәкъ үзе бит: эшкә сусар,
Кулы юмарт, күңеле күркәм—
Үз күрерләр улын дуслар.

Улкаена ышана ул,
Уй килә дә кот алына...
Һай, үзенә охшаган шул —
Җаны да бит уттан гына.

Озата да Урал-әнкәй,
Зәйгә җиткәч туктап кала.
Таудан төшкән гөрләвектәй.
Далага юл тота бала.

Чү, әнкәнең нигә әле
Моңсуланып китте йөзе?..
Төенчеген бирмәгәнме,
Калган мәллә әйтер сүзе?..

Карады ул хафаланып
Куенындагы кояшына —
Оныта язган... Кабаланып
Куйды аны иңбашына.

Иңбашыннан күккә чөеп,
Зәй өстенә тәгәрәтте:
Ташыт, улым, җирдән диеп,
Шундый якты бәрәкәтне!

## Эшнең дә бит була язы

Менә безнең Белоглазов
Буровойда эшләп йөри.
Эшнең дә бит була язы —
Тырышлыктан ташлар эри.

Кайнар алмаз бу малайда —
Тау астыннан ташка сыза...
Салмак кына буровойда
Эшләр йөгерә, эшләр кыза.

Бер карасаң, кышын — чиллә,
Бер карасаң, җәен — буран...
Каюм әйтте: — Дөрли белә,
Иллә суына белми торган...

Хәммәт әйтте: — Аңа тимә,
Аяз көнне яшьнәсә дә —
Көндез димә, төнлә димә
Бурмастерым янәшәмдә.

Питрей әйтте: — Яшен ташы!
Фахраз әйтте:—Безнең сыңар:
Эшкә усал, эштә яхшы,
Дуслар, эшләр безнең уңар!

Эшнең дә бит була көзе —
Белоглазов төксе йөри.
Тик хәтердә — «Хәзер үзем!»
Дигән сыман көлемсери.

«Бар!» дисәләр булмас борын,
Кырку гына тамак кыра.

Бәй... Су килми!.. Бурмастерым
Көрәк алган — ермак ера...

Төн. Бу җиле чыкты кайдан?—
Куллар оеп, күзләр тала.
— Ял итеп ал.— Котлыбайдан
Чыгыр сабын үзе ала.

Девон яры инде якын.
Уң булачак өметләре.—
Уңда-сулда алтын якның
Уңган-булган егетләре!

## Мондый чакта йокы кача

Ике айлык сәфәр иде.
Соңгы катлам... «Комын ишмә!»
Ай дигәндә, җир «Һай!» диде —
Акты-китте алтын чишмә.

Кичен — туйда, иртән — уйда...
Уй дигәнең уен түгел. —
Бурыч куй да, ташка уй да
Бәйгеләрне кабыз, күңел!

Сүз юк ачы бураннарга,
Якын булмас ераклыгы;
Тилмертә лә бу дәрьяга
Юл салуның озаклыгы.

Мондый чакта йокы кача,
Уйчан маңгай шабыр тирдә...
Тагын үзе килеп баса: —
Тагын борау: «авыр җирдә».

Аягүрә тамак ялгап,
Тагын бераз тирлә инде...
Сәгатьләрдән минут яулап,
Куба заман гөрләвеге.

Яңгырлы көз дә яктыра —
Шат күзләрдә таңы аткан:
Ае әле ярты гына —
Алда инде тулы фонтан!

Әлде-куйды, кызык итеп,
Ак буровой ал байракны,—
Куып-җитеп, узып-китеп
Вакыт дигән аргамакны.

Әйбәт атлый Белоглазов,
Очышларын төштә күрә...
Хисләрнең дә була язы —
Ташый... ташый... ташый бирә.

Йөз тонналы мәшәкатьнең
Төбенә үк җигелгән ул.
Мәшәкатьле мәхәббәтнең
Ярсуына бирелгән ул.

Шул яз канат — бу күңелгә,
Хыялы да — хисе мулга:
Ташытыр иде җирдән илгә
Көн дә берәр алтын елга.

## Әйтелмәгән уйлар кала

Ачып биргән чишмәләре
Әле бары кырык тугыз...
Алда тау-тау эшләр әле —
Вакыты тыгыз, вакыты тыгыз.

— Ел да шул бит көзләрендә...—
Нюрасына карап ала.
Карый гына... Күзләрендә
Әйтелмәгән уйлар кала:

— Кичер инде, хатын гынам —
Кайттым гына, тагы китәм.
Бураны бит... Каты гына...
Дусларыма дәрман илтәм.

Йоклап кала ике балам,
Үзең назла — үзем юкта.
Берсекөнсез бушый алмам —
Эшем тота, эшем тота.

Уйный алмыйм кунак-кунак,
Хәстәрләнеп йөрмә, хатын.
Бу арада өем ерак,
Эшем якын, эшем якын.

Утырырбыз бергә майда,
Яңа елда көтмә, иркәм.
Мәшәкатем буровойда,
Бәйрәмем дә шунда күркәм.

Бу сукмакны шушы төштән
Күңелем үзе эзләп тапты...
Сизеп йөрим: минем эштән
Илем якты, илем якты.

Киям брезент, йөрим туннан—
Костюмнарны улым кисен...
Кышын тирлим, җәен туңам
Эшем өчен, эшем өчен.

Ялга чыкмыйм, юлга чыгам —
Эшем тарта, эшем тарта.
Эшкә чумам — хискә чумам,
Сагыну кими — сөю арта.

Нюра иркәм, озак тормам —
Яңа фонтан менә-менә...
Соңгы катлам тозак корган
Буровойның йөрәгенә...

## Үз йөрәген бирер булып

Төшми борау, менми борау.
Ут сулый җир иргә янап.
Иреннәрдә юаш сорау,
Ә күзләрдә усал җавап...

Хәбәр итә. Боерык ала.—
«Ярты сәгать көтсәң, имеш...
Ярты сәгать!..» Боегып кала...
Кызып китә: — Үзе тиеш!

Ике атлап, бер ыргылып
Тагын менде тимер түргә, —
Үз йөрәген бирер булып
Турбобурын терелтергә.

«Минут өчен тартышканда,
Ярты сәгать — ярты гомер...»—
Җир белән бил алышканда,
Тетри дала, күкри тимер.

Җигелгән бит моторларның
Соңгы тамчы җегәрлеге...
Җиңгәләде батырлыкны,
Бармы җирне җиңәрлеге?!

Якыны юк үгетләргә,
Якыннары ерагайган —
Кырт кисте бит егетләргә:
— Чыгыгыз, дип, буровойдан!

Хәммәт сизде кушканыннан —
Сүзе хата... Уе таза...
Якын-якын дусларыннан
Ерак йөрсен бәла-каза...

Зур ачылып тирги-зурлый
Бригаданың күзе аны...
Кайсылары инде юрый
Чираттагы могҗизаны...

Зыкыларда ялан түзәр,
Ут йотып ла туңа Каюм...
Ялвара бит кайнар күзләр:
«Тыелсаңчы, туганкаем!»

Йөгереп керә... Күздә яше:
— Туганкаем, тыелсаңчы!
Чатырдады тимер яшен...
Кар өстендә — кызыл тамчы...

Сынып төшкән корыч кына...
Бу сынмаган — туры, озын —
Беренче кат тыныч кына
Йоклап ята тынгысызым.

Җил тиде дә җилбердәнеп
Куйды бәсле киемнәре...
«Тотмадыгыз җиңемнән» дип,
Турсайганнар иреннәре...

Яшь тапмый күз еларга да —
Зур тетрәүдән күңел тынган...
Бар бер тынлык: — Юк арада
Туганнардан якын туган.

Каты гына җирне казып,
Тирәсенә гөлләр куйган...
Йөрде кабынып, йөрде кабы-
зып,
Китте сүнеп — төште кулдан.

Якын иде, инде ерак...
Сагыш баса күңелләрне.
Бар бер тойгы: — басмый туф-
рак
Күңелләргә күмелгәнне!

Буран булып куба кире,
Урыны түгел, вакыты тарта.—
Дуслар белән китә гомере
Кайнар-кайнар вахталарга.

Ирнең даны ил гизсә дә,
Чын яшьлеген азлар белә.—
Көн туа да, җил исә дә
Илне иңләп язлар килә.

## Игелекле үз баласын

Урал-тауның кочагыннан
Табыла тимер, агыла күмер.—
Урал-йортның учагыннан
Кабызып ала таңын бу җир.

Алын-гөлен киенә дә
Килә-китә җәйгә ана.—
Урал-әнкә иелә дә
Итәкләрен Зәйгә мана...

Таңгы чыклар күзләрендә...
Алга карый, юлга карый:
Улының баскан эзләрендә —
Иленең алтын елгалары.

Тимер ярлар — тирә-юньдә,
Тимер ярлар — тере сулы.
Көләч дала күкрәгендә
Улы сулый, улы сулый.

Алтын нигез өсләрендә —
Аллы-гөлле олы кала.
Дусларының хисләрендә
Улы кала, улы кала.

Җырлар күкри Зәй өстендә,
Ана тыңлый, ана ятлый.—
Батырлыклар бәйгесендә
Улы атлый, улы атлый.

Илне бизәп яши бел дә
Күмел, имеш, җиргә яшьли...
Татарстанның яшьлегендә
Улы яши, улы яши.

Ел өстәлә тагын елга,
Тагын бәгыре сызлап китә.—
Колак салып уңга-сулга,
Урал-ана җавап көтә...

Бәгырең, әнкәй, сызланмасын! —
Җиренең язын кайтарышкан
Игелекле үз баласын
Онытамы соң Татарстан!

——◆——

*Шамил Бикчурин*

# КАЙТУ

## Хикәя

I

Кайрак кебек шома, тигез асфальт юлны калдырып, ул каен урманына таба борылды. Моннан инде барасы буровойның сәндерәсе дә, андагы верховойның гәүдәсе дә аерым-ачык булып күренә иде. Ахры, бораулаучылар инструмент күтәрәләр — верховой шәмнәрне кабул итәргә менгән.

Мөнәвир, верховойга күренмәскә теләп, юл буендагы яшь каен куакларына табарак сыенды, үзе зур дулкынлану белән кызу-кызу бара бирде. Йөрәге аның күкрәк читлеген җимерердәй булып тыпырчына, сулыш алырга ирек бирми, ярсый. «Нәрсә диярләр, үзләренә кире алырлармы?» дигән уй җәфалый иде юлчыны.

Мөнәвир, нәрсәдер белергә тырышкан сыман, тагын вышка башына карап алды, тагын агачларга елыша төште. Назлы каен яфраклары аның битен сыйпап иркәләгәндәй иттеләр, аны бераз тынычландырдылар. Ул күлмәк изүен чишеп җибәрде, агачтан бер-ике салкынча яфрак өзеп алып, аның белән маңгай тирен сөртеп ташлады. Аннан, юл читендәге яңа киселгән агач төбенә күләгәгә утырып тәмәке кабызды да ерактагы буровой гөрелтесе белән кушылган кошлар сайравын тыңларга кереште. Сигез айдан соң туган җирләргә кайтып, яңадан таныш урманда утыру аңа чиксез ләззәт бирә иде.

Урман, урман! Хуш исле, сайрар кошлы урман, ничек сагындырдың син Мөнәвирне! Үзеңдә булган бар нәрсәне: һәр аяк тавышын, һәр агач шытырдавын, һәр кош сайравын һәм буровой торбасының һәр чыңын бәйнә-бәйнә сөйләп торган яңгыравыклы, беркатлы, гади урман, ничек юксындырдың син улыңны!

Тыңлап карагыз әле, чыннан да гаҗәп соң: шунда ук гөрләп буровой эшләп тора, шунда ук, тирә-юньгә әһәмият бирмәстән, агачлардан-агачларга кунып төрле кошлары, сандугачлары сайрый. Мондагы кошлар һич тә буровойны үзләренә комачау итеп карамыйлар — сайрыйсын сайрый бирәләр. Җитмәсә, оя да ясыйлар, бала да чыгаралар. Буровой һәм кошлар ничектер бер-берсен тулыландыралар. Кошлардан башка буровой, буровойдан башка кошлар яши алмастыр кебек.

Мөнәвирнең сынаганы да бар: урманнан вышка күченеп киткәч, кошлар моңсуланып калгандай булалар, ямансу сайрый башлыйлар. Урман эче барабансыз оркестрны хәтерләтә. Көз көне, кошлар җылы якларга очкач, тагын да күңелсез — урман оркестрының бер барабаны — тукраны белән буровое гына кала.

Мөнәвир киткәндә көз, урманның әнә шундый күңелсез чагы иде. Тик Мөнәвир туган ягын урман күңелсез булган өчен ташлап китмәде.

Юк, ул чагында урманның ямен дә, туган якларның якынлыгын да белерлек дәрәҗәдә түгел иде ул...

...Соңгы уйлар Мөнәвирнең кәефен генә җибәрде. Ул тәмләп тәмәкесен дә тартып бетерә алмады, төпчеген аяк астына салып изде дә, урыныннан авыр гына торып, кыяр-кыймас юлга төште. «Үткәннәрне бәлки гафу итәрләр» дигән өмет бетмәгән иде әле аңарда. Бары шул бердәнбер өмет кисәге генә аны кире кайтырга, бирегә килергә мәҗбүр итте дә.

— Сәләхетдин абзый бәлки читкә типмәс, алыр...

Бораулау мастерының бөтен яхшылыкларын, иткән изгелекләрен хәтерләп, юл буе шул уйлар белән юанып килде Мөнәвир.

Менә буровой да яп-якын инде, каршыда гына. Бораулаучылар ашыга-ашыга забойга инструмент төшерәләр. Чынлап карасаң, кешеләрен дә танырга була. Әнә, вышка башында верховой Әбүзәр — дус малай. Гәүдәгә озын булганы өчен Мөнәвир аны үз итеп кенә ирештерә, үрти торган иде: «Нигә сиңа вышка башына менеп йөрергә, үрелсәң болай да җитәсең ич...». Теге юаны — Фәрит, ахры. Әйе, ул. Ярдәмче урынына баскан. Димәк, күтәрелгән егет.

Тукта, бораулаучы кем соң? Зәңгәр шакмаклы күлмәк кигән, тәбәнәк буйлы бу кеше кем, Зыя түгелме?

Кайчандыр Мөнәвир генә басарга хаклы булган идарә пультына басып, тормоз рычагын тоткан Зыяны күргәч, Мөнәвир үзе дә сизмәстән кашларын җыерды.

— Зыя булып Зыя бораучы? Минем өйрәнчегем?..

Бөтен тәнен биләп алган тирән көнләшү хисе әлегәчә булмаган тәвәккәллек белән Мөнәвирне алга өстерәде.

Шул вакыт культбудка астыннан зур соры эт өреп чыкты һәм, ямьсез калын тавыш белән амалап, Мөнәвиргә таба килә башлады. Юлчы куркып, барган җиреннән шып туктап калды.

Бу эт Вертлюг иде. Шул — бер вакыт эшкә барганда бораулаучыларның юл буенда яңгыр астыннан тапкан һәм автобуска утыртып вахтага алып килгән көчекләре.

Мөнәвир киткәндә Вертлюг йодрык кадәр генә иде, хәзер чын овчарка, кешене куркытырлык эт булган.

— Вертлюг, әллә үзеңнекеләрне танымыйсыңмы? — диде Мөнәвир, исәнләшкәндәй, эткә таба кулын сузып. Ләкин Вертлюг аны тыңламады, эндәшкән саен усалланды гына.

Эт өргән тавышка культбудкадан бораулау мастеры Сәләхетдин абзый чыкты. Ул бөтенләй нефтьчеләргә хас булмаган челтәрле ак майка кигән, ялан баш иде. Чәчен, гадәтенчә, тап-такыр итеп алдырган, мыегын борын астында бармак башы кадәр генә калдырып кырган.

— Вертлюг! — диде эткә кисәтүле итеп Сәләхетдин абзый һәм, үзенә ялагайланып сыенган овчаркага бармак яный-яный, килүчегә каршы китте.

— Әллә Мөнәвир инде?

Мастер гаҗәпләнгәндәй итенде, туктады. Мөнәвир кабаланып аңа кулын сузды.

— Мин, Сәләхетдин абзый, исәнмесез?

Очрашу, күрешү нәкъ Мөнәвир көткәнчә булды. Сәләхетдин абзый салкын гына, исе китмичә генә кул бирде һәм:

— Кайттыңмы? — дип сорады мәгънәле генә итеп. Мөнәвирне баштан-аяк күзе белән капшап чыкканнан соң: — Ишеткән идем, ишеткән идем, — дип өстәде.

Мөнәвирнең йөрәге жу итеп китте: «Барысын да ишеткән икән».

Сәләхетдин абзый, чыннан да, Мөнәвир Гариповның кайтуы турында бораулау конторасында бер атна элек үк ишеткән иде инде. Халык дигәнең андый хәбәрне яшен тизлеге белән тарата бит ул. Мөнәвирнең маҗараларын конторада бераз арттырып та сөйләделәр бугай. Имеш,

Гарипов моннан киеп киткән күлмәген дә алыштырмаган. Имеш, кайтырга да хатыныннан акча соратып алдырган. Сәләхетдин абзый башта бу сүзләргә гайбәт кенә дип караган иде, кичә Мөнәвирнең хатыны Кәүсәрияне күреп сөйләшкәч, тәмам ышанды. Сүзләр шактый күпертелгән булса да, Мөнәвирнең өс-башын карый алмавы хас икән. Әмма кайту өчен акча сорамаган, сер бирмәгән, ничек итсә иткән, үзе кайтып егылган.

— Үзе чорт с ним, холкы үзгәргәнме соң? — дип, уенын-чынын бергә кушып сорады Сәләхетдин абзый Кәүсәриядән.

— Һаман шул, кире беткән тәкәббер. Урамга да чыкмый, кешеләр белән дә сөйләшми, эш тә эзләми...

— Мөнәвирлеген итә дисең, алайса... Шулай инде, характер трактор түгел, тиз генә төзәтеп булмый. — Карт, үз кызыдай күреп, Кәүсәриянең аркасыннан какты: — Борчылма, килен, «кайткан малда бәрәкәт бар».

Моңа кадәр дә Сәләхетдин абзый белән Кәүсәрия очрашканда сөйләшә торганнар иде. «Ничек, килен, хат-хәбәре бармы?» — дип башлый иде мастер сүзен.

Мөнәвир турында сорашсалар, Кәүсәрия уңайсызланып кына җавап бирә иде. Мөнәвир башта озак кына хат язмады. Бичара Кәүсәриянең күңелендә ниләр генә булмагандыр дисең.

Мөнәвирдән беренче хат килү белән үк Кәүсәрия Сәләхетдин абзыйларга йөгерде. «Мөнәвирнең хәле мөшкел икән, әллә чакырып языйммы, Сәләхетдин абзый?» — дип, киңәш сорарга килгән.

— Кирәкми, чакырма, үзе кайта ул, үзе! — дип, мастер тәмам Кәүсәрияне ышандырган иде.

Картның әйткәннәре юш килде. Менә хәзер аның алдында күптән көткән «иске дусты» Мөнәвир басып тора.

— Куяннар базарда очрашалар дисең инде, ә? Ничек соң әле болай...

Сәләхетдин абзый сәер генә итеп Мөнәвиргә тагын бер мәртәбә карап алды.

— Язмыш, Сәләхетдин абзый... — дип пышылдады Мөнәвир.

— Үзең эзләп тапкан язмыш, кем...

Мөнәвиргә шундый читен, шундый авыр. Элек аның өчен үлеп торган Сәләхетдин абзый да аңардан әнә ничек суынган, аңарга әнә нинди кырын күз белән карый. Чит иткәне, кунакны өенә дәшәсе килмәгәне әллә каян ук сизелеп тора. Эте булып эте дә тешләргә генә чамалый, каһәр.

Шулай да Мөнәвир кыстауны көтмәде, мастерга ияреп культбудкага керде. Йөзеңне ертып килгәч, кире китеп булмый инде...

Ике бүлмәле вагон эче пөхтә итеп җыештырылган, бизәлгән. Төрле плакатлар, рәсемнәр, диаграммалар... Түр стенада алтын хәрефләр белән язылган Кызыл байрак һәм рамга куелган Мактау грамотасы эленгән. Иң өстә, стена буена сузылган кызыл комачта «Елына егерме биш мең метр бораулау өчен!» дигән лозунг кычкырып тора. Өстәлдә телефон, зур радиоалгыч.

Ишек янындагы кием шкафы башында күзләрен шарландырып симез ала мәче утыра — таныш булмаган керүчене күзәтә.

Кызыл байрак, егерме биш мең метр, Мактау грамоталары. Болар барысы да Мөнәвиргә ничектер ят та, яңа да, гаҗәп тә булып тоелдылар. Алар әллә ничек Мөнәвирне әрнештерә, үкендерә, көнләштерә иде.

Бригаданың уңышлары турында Бохарада вакытта ук ишеткән иде инде Мөнәвир. Хәтта «Правда» газетасында Сәләхетдин абзыйның рәсемен дә күрде. Менә шунда инде ул тынычлыгын җуйды да...

Культбудканың әнәсеннән-җебенә кадәр карап чыккач, Мөнәвир түзмәде, вахта журналына нидер язарга утырган мастерга дәште:

— Бай яшисез.

Сәләхетдин абзый башын күтәрми генә җавап бирде:

— Аллага шөкер, син юк дип тормадык.

Мөнәвир сүзсез калды. Дөрес сүзгә җавап юк. Уңайсызлануын яшерү өчен тәрәзәгә борылды.

Тышта бораулаучылар соңгы шәмне төшерәләр иде инде. Кара, ничек җәһәт эшлиләр. Мөнәвир күрә дә алмый калды — торбалар җир астына чумып та өлгергәннәр. Байракны тикмәгә генә бирмәгәннәр шул егетләргә. Хәзер булса Мөнәвир дә бригадасының кадерен белер, башын калкытмый эшләр иде, тик алсыннар гына иде.

Шул турыда сүз кузгатмакчы булып, ул яңадан мастерга таба борылды. Ә Сәләхетдин абзый уйлап та бирми — такыр башын кырын салган да яза гына. Нәрсә яза икән журналга шул кадәр? Нигә соң ул дәшми? Ичмаса, нәрсә булса да сорашсын, я булмаса, үткәндәге гаепләре өчен Мөнәвирне авызы туйганчы тиргәсен иде. Барысын да күтәрер иде Мөнәвир, җанына рәхәт, җиңел булып китәр иде...

Мөнәвир берничә мәртәбә: «Мин бригадама кайттым, зинһар алыгыз, Сәләхетдин абзый», — дип әйтмәкче дә булып талпынган иде, тик моңа кыюлыгы җитмәде. Сәләхетдин абзый һичшиксез: «Исеңдәме, мин сиңа нәрсә әйттем?» — дип, үз сүзләрен хәтерләтәчәк иде.

Әйе, Мөнәвирнең бүгенгедәй исендә. Китәргә ниятләп гариза тотып кергәч, шушы культбудкада әйтте: «Уйлап эш ит, энем, үкенерсең, кайтсаң яңадан алмам». «Алмасаң, кем сиңа ялына!» Менә шулай дип җавап биргән иде Мөнәвир.

Ул чагында Сәләхетдин абзый башын чайкап: «Бозылса бозыла икән кеше!» — диюдән башка сүз әйтә алмады. Аның Мөнәвиргә бик нык хәтере калган иде.

Чынлыкта, Мөнәвирне кеше иткән дә, аны бозган да Сәләхетдин абзый үзе булды.

Тимәштә нефть мәйданы ачылган ел, бораулау эшләре чиксез зур. Бораулаучылар рәттән икешәр вахта торалар: бораулаучы кадрлар житешми. Эшчеләр табу тәртибе дә шундый: юлда бер атлы колхозчыны күрсәләр, бораулаучылар аның каршысына йөгерәләр, үзләренә яучылый башлыйлар: «Әйдә безгә, бездә яхшы, бораулаучы булырсың». Ул кеше: «Мин бит нефть эшен белмим», — дип карышса да, тукталып калмыйлар: «Нефть вышкасын күргәнең бармы? — Бар. Шулай булгач булдырасың!»

Сәләхетдин абзый — карт төлке, Баку нефтьчесе, кадрны алай юлдан тотып җыймый. Вахтадан бушаган араларда Шөгергә баргалап, промысел операторларына агитация ясап йөри. Имеш, нигә монда скважина сагалап ятарга, ни эше, ни ашы. Әйдәгез безгә буровойга, кесә тутырып акча эшләрсез.

Сәләхетдин абзый Мөнәвирне шуннан, Шөгер промыселыннан ияртеп кайткан иде. Мөнәвир бригадага буровой эшчесе булып керде. Ләкин күрә: алтын таулары вәгъдә иткән мастер аңа акчаны санап кына бирә. «Минем үз эшем лутчы иде», — ди Мөнәвир. Эшчесез калудан курыккан мастер егетне акчалырак эшкә — верховой итеп күтәрә.

Гайбәтенә кереп булмый, Мөнәвир — тырыш, уңган егет, нәрсәгә тотынса, шуны эшли. Шуңа күрә дә контордан Мөнәвир Гариповны бораучы ярдәмчесе итеп билгелиләр һәм икенче бригадага күчерәләр.

— Кеше өчен табып кайттыммы мин аны? — дип, эшчесен алуга бик ачуланып йөри Сәләхетдин абзый. Күп тә үтми, Мөнәвир янына килә:

— Нәрсә син безне ташладың, Сәләхетдин абзыеңда яхшырак урын булмас дип белдеңме әллә?

Мөнәвир үз кадерен үзе белә торганнардан була күрәсең, бораучы булып яңадан Сәләхетдин абзый бригадасына күчә.

Үсенеп киткән Мөнәвирнең борыны яхшы ук күтәрелә. Гарипов иптәшләрен санга сукмый башлый. Аның чуар күңеле кайсы буровойда яхшы, кайда күбрәк түлиләр — шунда омтыла.

Ул елны Сәләхетдин абзый бригадасы бораулый торган мәйдан гаять көйсез булып чыкты. Бораулаучылар биш-алты йөз метр әйбәт кенә бораулап баралар да көтелмәгән җир асты куышлыгына юлыгалар. Бораулый торган су каядыр упкынга кереп югала. Куышлыкны томалап кырык-илле метр борауларга да өлгермиләр, тагын упкын, тагын су йотылу.

Башка чакта Сәләхетдин абзый дип кенә торган Мөнәвир сукрана башлый:

— Менә, авыртмас башка тимер таяк! Каян килеп эләктем мин бу эбер-чеберләр арасына! Монда эшләсәң, ыштансыз калырсың, билләһи! Китәм!

Мастерның да, бораулаучыларның да Мөнәвирне бригададан җибәрәселәре килмәде. Ни әйтсәң дә, Гариповның тәҗрибәсе зур, авыр хәлдән чыгарга ярдәм итә ала торган кеше.

Акча шаукымы тигән Мөнәвир бригададан китте. Мастерның фатыйхасыннан, иптәшләренең ризалыгыннан башка китте — буровой эшчесез, ятим калгандай утырып калды. Сәләхетдин абзыйның соңгы мәртәбә өзгәләнеп әйткән «Уйлап эш ит, энем, үкенерсең, әмма соң булыр, кайтсаң яңадан алмам» сүзе Мөнәвиргә хәтта көлке генә булып тоелды. Чөнки, үзенең әйтүенчә, аны теләсә кайда күтәреп алачаклар, кулына меңәрләгән сум акча тоттырачаклар иде.

Мөнәвир киткәч, Сәләхетдин абзый әллә никадәр исенә килә алмыйча, башын чайкап торды:

— Бозылса да бозыла икән кеше!

Сәләхетдин абзыйның Мөнәвиргә карата булган үпкәсе әллә ай буена барды тагын. Тик бераздан соң, йөрәк әрнүе басыла төшкәч кенә Мөнәвирне бозуда үзе гаепле икәнен төшенде. Картны күтәрә алмаслык вөҗдан газабы басты.

— Яшь баланы кәнфит ашатып бозгандай боздым шул. Башкалар сүзенә колак салмадым... — дип сөйләнә иде ул бораулаучылары янында. Бу Сәләхетдин абзыйның алар алдында үзенчә гафу үтенүе иде инде.

— Кайтса, кире алыр идеңме, Сәләхетдин абзый? — дип сорыйлар иде бораулаучылар, кызыксынып.

— Алыр идем. Гаебемне төзәтер идем, яңа баштан тәрбияләр идем мин ул каһәр сукканны, — дип йодрыкларын йомарлап куя иде мастер.

Ниһаять, теләге кабул булды: Мөнәвир кайтып төште. Сәләхетдин абзый нишләргә белми аптырап калды.

## II

Сәләхетдин абзый бригадасыннан киткәч, аны башка бригадалар кабул итмәделәр.

— Һәй, алмасагыз, ул кадәр шаккатканым юк әле, сездә генәмени эш! — диде дә, контора белән исәп-хисапны өзеп, гаиләсе белән дә киңәшеп тормыйча, күзе караган якка сәфәр чыгып китте Мөнәвир.

Башта ул Куйбышев бораулаучыларына кагылды. Бораулау конторасына кереп, үзенең тышы белән үк нефтьченеке икәнен белдереп торган хезмәт кенәгәсен күрсәтте. Карчыга борыны кебек озын кылыч борынлы кадрлар бүлеге начальнигы кенәгәне ничектер җирәнеп кенә ачканнан соң болай диде:

— Ә документыгыз?

— Документ күрсәтәм! — диде Мөнәвир ирәебрәк.

Теге кеше күзлеген маңгаена күтәреп куйды да кылыч борынын югары чөеп сорады:

— Диплом, аттестат кебегрәк нәрсәгез дим?

Мөнәвирнең моңа ачуы чыкты, нәрсә дип әйтергә белмичә, иреннәрен мимылдатып торды да, начальникның кулыннан кенәгәне тартып алып, чыгып китте.

Ачуы да килерлек иде шул. Ике ел эшләде, верховой булды, бораулаучы ярдәмчесе булды, бораучы булды — моңа кадәр беркем дә аннан аттестат та, диплом да сорамады. Ул турыда хәтта телгә алучы да булмады.

Мөнәвир Башкортстанга китте. Туймазы шәһәрендә, бораулау конторааларының берсендә исә үзенең сораулары белән бер башкорт аның теңкәсенә тиеп бетте:

— Нәмә дип эшеңде ташланың, эшеңдән нәмә дип сыктың, үзеңделәр ярамый инемени?

Мөнәвирнең мин-минлеге, тәкәбберлеге ул кадәр төпченүләрне күтәрә алмады:

— Анысы инде, абзый, безнең эш, китер кенәгәне! — диде дә кенәгәсен алып икенче контораага юнәлде.

— «Нәмә сыктың?» — дип сакаулан̆ган була тагын, үләрсең кыланышына!

Эченнән юл буе сүгенеп, төкеренеп барды Мөнәвир һәм шул ачулы хәлендә икенче бер контораның ишеген барып тартты.

— Сабыр итегез, егет, күрәсез, кешеләр, — дип, мөлаем генә бер хатын Мөнәвирне кире борды.

Мөнәвир ишек төбенә баскан хәлдә чират көтеп тора һәм уйлана: «Монда безнең контора түгел икән...»

«Татбурнефть» трестында бит аны теләсә нинди мәсьәлә белән, теләсә кайчан чиратсыз кертәләр иде. Ишектән башыңны гына күрсәтү кирәк: «Ә-ә, Гарипов, әйдә! Сез, кем, бераз сабыр итегез, кешенең вахтага барасы бар». Касса янына акча алырга килсә дә, бөтенесе юл биреп тора: «Читкәрәк китегез, башта эре акчаларны җибәрик».

Биредә ишек төбендә ярты сәгатьләр басып торгач кына кабул иттеләр.

Чибәр хатын кенәгәгә күз төшерү белән әйтте: «Ай-яй, эш алыштырырга яратасыз икән үзегез! Риза булсаң, бораучы ярдәмчесе итеп алабыз».

— Нәрсә сез, көләсезме әллә? Мин бит бораучы булып эшләдем!

— Эшләвен эшләгәнсез дә, ләкин... кем ничек эшләми!

Бу сүзләрдән соң инде Мөнәвир ничек чыгып китүкәнен дә, кая барганын да хәтерләмәде. Ул нииндидер юл белән вокзалга килеп чыккан иде. Нишләргә? Промыселга, Шөгергә кире кайтыргамы? Юк, анда инде аны алмаслар. Яңадан әлеге ханым янына барып, ризалашыргамы? Булмый, түбәнгә тәгәрәү. Урта Азиягә юл тотаргамы?

Мөнәвирнең Бохарада бораулаучылар алалар икән дип ишеткәне бар иде. Шунда китәргә карар итте. Тик анда да Куйбышевтагы, Башкортстандагы кебек каршы алсалар, ул нишләр, тагын кая барыр?

Поездга утыргач та, төрле ямьсез уйларга бирелеп, ут йотып барды Мөнәвир. Ераграк китүкәч, километрлар саны арткан саен йөрәгенең дә сызлавы көчәя барды. Ә поезд туган җирләрен артка калдырып, көнтөн туктамый чаба гына. Гүя бу җәһәннәм машинасы аны мәҗбүри алып китә, каядыр җир читенә илтеп олактыру өчен ашыга — Мөнәвирдә шундый тәэсир.

Юл буена диярлек аның эче пошты, бик кыйммәтле әйберен югалткан кебек йөрәге әрнеде. Ул кемнәрнедер үзе дә белми юксынды, сагынды...

Инде вагон тәрәзәсеннән ят, ләкин гаҗәп матур бакчалар, гомер таныш булмаган яшел үзәннәр, биек-биек агачлар күренә башлагач, Мөнәвирнең күңеле күтәрелеп китте, авыр тойгылары таралды. Тышта чын гүзәллеге белән Азия кояшы балкый иде. Гаҗәпләнмәслек тә түгел:

әле берничә көн генә элек салкын җилләр исә, вак яңгыр сибәли иде. Керза итекләрдә туган якның лае да кибәргә өлгермәде — ул инде кояшлы Азиядә.

Хәзер инде Мөнәвирнең күңелен яңа, берсеннән-берсе тәмлерәк хисләр кытыклый башлады. Имеш, ул мондагылар өчен бик кирәкле кеше булып чыгачак, аны монда күтәреп алачаклар. Ул атаклы бораучы булыр, даны шушыннан бөтен илгә таралыр. Исән булса, акчаны да көрәп алыр. Сәләхетдин абзыйны да, белеш-танышларын, хатынын да шаккатырыр әле ул.

Бохара вокзалына ул шундый хыяллар белән төште. Үткән-барганнан бораулау конторасын сорашырга кереште. Сәгатьләр буена йөрсә дә, беркем дә андый контораның барлыгын әйтеп бирә алмады. Ахырда, шәһәр советына кереп сорарга мәҗбүр булды Мөнәвир.

— Ай-вай, бала! — дип, тел шартлатып, Мөнәвирне кызганып баш селекteләр шәһәр советындагылар.

Бораулау конторасы дигәннәре моннан йөз чакрым ераклыктагы далада икән. Нишлисең, башыңа төшкәч, барасың. Мөнәвир бер үзбәк картын яллап, ишәккә атланып далага чыгып китте. Чүлдә кызу кояш астында өч тәүлек барды, ниһаять, янып-пешеп килеп җитте. Контораны эзләп бер киез чатыр эченә килеп керде.

— Исәнмесез?

— Вәгаләйкем әссәлам, мосафир, түрдән узың, чайдан авыз итең,— диде аңа түр башында, киез өстендә аяк бөкләп утырган әкә.

Аларның искиткеч кунакчыллыгы, ачык йөзлелеге Мөнәвиргә ошап китте. Бик сусаган чагы иде, бер дә кыстатып тормыйча, чәй эчте, аннан татарчалап-русчалап үзенең ни өчен килүен сөйләп бирде.

— Хуп, мәйле! — дип сикереп торды әкә һәм кулына Мөнәвирнең әлеге дә баягы майланып, читләре бөрешеп беткән хезмәт кенәгәсен алды. Әкә дип дәшкән кеше үзе бораулау конторасының директоры булып чыкмасынмы!

— Без сине участок начальнигы итеп куябыз, хупмы? — диде директор, кенәгәне саклык белән карап чыкканнан соң.

Моны ишеткәч, Мөнәвир көлеп җибәргәнен шәйләми дә калды. «Начальник! Мөнәвир — начальник! Җиде класс белеме дә булмаган Мөнәвирне начальник ясамакчы булалар. Бар икән башның кадерле чаклары!»

Бераз аңгы-миңге килеп утыргач:

— Мин бит бораулаучы, бораулый беләм, әмма... — дип, хәлен аңлатырга да маташып караган иде Мөнәвир, тик әкә аңа сөйләп бетерергә ирек бирмәде:

— Бораулый белгәч, начальник була беләсең дә беләсең! Хуп, мәйле, язып куйдым, иртәгәдән эшкә!

Мөнәвирнең язмышка буйсынмый чарасы да юк иде. Акча тотылып беткән, шулай булгач, кая да булса бүтән җиргә китү турында уйларга да урын калмый.

«Әйдә, — диде ул эченнән генә, — мәйле икән, мәйле, начальник булып карыйк, соңыннан күз күрер...»

«Күз күрер» дигәне инде бирәдә, кайчан да булса урын табып, бораучы булып керү иде. Ләкин килүенә ике-өч ай үтте, конторада андый урын бушамады.

Югыйсә Мөнәвир өчен участок начальнигының эше дә зарланырлык авыр түгел иде инде. Станциядән буровойларга торбалар, җиһазлар кайтарта, машиналарга гына утырып йөри. Исәп-хисап, язу-сызу кебек эшләрне башкаруда аңа инженерлар, хисапчылар ярдәм итеп тора. Йөрәккә ятмагач, күңелең тыныч булмагач — эшең эш түгел инде.

Ничаклы гына тырышып хезмәт итмәсен, аңа ничектер бирәдәге кешеләр ышанычсыз карыйлар, үз итмиләр, килмешәк дип әйтәләр төсле

тоелды. Директор әкәнең кич саен диярлек үзенә чәйгә чакыруы да, бораулаучыларның иптәш начальник дип эндәшүләре дә — барысы да ясалма, Мөнәвирне сынау өчен генә эшләнә кебек. Шуңа күрә дә Мөнәвир әкә янына керми, бораулаучыларның күзенә артык чалынмый башлады.

Килгәннең беренче атналарында Мөнәвир «дала клубы» дип аталган күршедәге зур чатырга кереп йөри, кино-мазар карый иде, хәзер алардан да бизде.

Далага яз килде. Урта Азия табигате купшы кунак кызыдай көязләнде, матурланды. Апрель башларында ук инде күз күреме җитмәс җирләрне җете кызыл тюльпан, алланып торган кыргый мәк чәчәкләре каплады. Һәркайда кошлар сайраша. Озын койрыкларын җилбердәтеп кушаяклар, җитез йомраннар чабыша, ояларыннан башларын тыгып, бер-берсен үртәшкәндәй суырлар сызгырына. Җансызга җан кертә, рухсызга рух бирә торган гүзәл яз иде бу.

Яз даланы җанландырды, ләкин Мөнәвирнең күңелен күтәрә алмады. Мөнәвир зарыгып көткән бораучы урыны һаман бушамады. Кешеләренә исең китәр, буровойгаябышып яталар, берсе дә эшен ташлап китәргә исәпләми.

Мөнәвирнең ачуы да килә башлады. Әкәне күргән саен тинтерәтеп бетерде: «Миңа кайчан үз эшемне бирәсез инде?»

— Башта бу эшеңдә үзеңне күрсәт әле, — ди Юлдаш әкә, көлә генә.

Эх, үзен бу эштә күрсәтә алырмы микән Мөнәвир? Бер дә генә дә ошамый бит аңа бу эш!

Мөнәвир кебек күңеле китек кеше өчен далада язгы төннәр ямансу була. Бүген дә ул эштән соң беркая чыкмады, чатыр эченә кереп, аның брезент ишеген чак кына күтәреп куйды да алсу офыкка карап уйланып ятты.

Күршедә күңел ачалар. Клубның җир идәне дер селкенеп тора. Шаяру, көлү тавышлары, төрле милләт көйләре ишетелә.

— Шулай да Татарстандагы кебек түгел инде, — дип үртәлеп куйды Мөнәвир. — Безнең Әбүзәр тальянын тартып җибәрсә...

Кәүсәриядән хат алган иде. Исәнме, качкыным, дигән... Сагынам, дигән. Илгизәр дә үсте инде, тәрәзәгә капланып: «Әти, кайт!» дип кычкыра дигән. Сәләхетдин абзыйлар икенче скважинаны башлаганнар, алдынгылык алар кулында икән. Мөнәвир соң монда килеп ни майтарды? Йөри шунда, кеше булмаганнан начальник исеме күтәреп!

Мөнәвирнең төннәре гел әнә шундый кичерешләр белән үтә иде. Күзен йомса да, бригадасындагы иптәшләре, хатыны, баласы килеп баса. Бигрәк тә Илгизәре күз алдыннан китми. Туптай тәгәрәп әтисенең итәгенә менә, шаяра. Колак төбендә дә аның тавышы: «Әти, кайт! Әти, кайт!»

Мөнәвирнең күңеле әкренләп туган якларына күчте. Аны бары принцип дигән нәрсә генә тота иде инде хәзер. «Кайтмам» дип китте ич. Нигә бер дә уйламый әйтте икән? Нигә иптәшләрен, Сәләхетдин абзыйны, хатынын тыңламады икән? Каһәр суккан тәкәбберлеге булмаса, шушы минутта ук кайтып китәр иде...

Эшеннән, тормышыннан зарланып язган хатына җавап алды. Кире чакырмаслармы дип өмет иткән иде Мөнәвир. Юк, чакырырга исәпләмиләр. «Гелән җил куып йөрү булмасын. Кайтсаң да үз эшеңне таба алмассың», — дип язган Кәүсәрия.

— Чакырмасалар чакырмаслар, кайтам, — дип фикер йөртте Мөнәвир. — Мин иптәшләремне, Сәләхетдин абзыйны, хатынымны бәхилләтергә тиеш. Минем эшемме соң начальник булу, торбалар санап йөрү?

Уйлап-нитеп тормый гына күңеленә килгән бер халык мәкален дә үзенә яраклаштырып куйды Мөнәвир: «Чит җирләрдә солтан булганчы, үз җиреңдә олтан бул».

Китәргә төрле сәбәпләр эзләп, гомердә кыланмаган гадәтләр дә уйлап тапты — тимер юл станциясенә торбалар алырга баргач, буфетка кереп аракы эчә торган булып китте.

— Ай-вай, бу баланың яман гадәте дә бар икән, мәс булып йөри! — дип исе китте әкәнең.

Бораулаучылар да: «Моны Татарстаннан эчкәне өчен куганнар икән», — дигән нәтиҗәгә килделәр.

Бер көнне Мөнәвир буровойга лаякыл исереп кайтты. Кесәсеннән Сәләхетдин абзыйның рәсеме төшкән «Правда» газетасын чыгарып, аны бораулаучылар алдында селки-селки сөйләнә башлады:

— Күрәсезме, кемнең рәсеме? Бөек кеше ул Сәләхетдин абзый, кешенең көзгесе, әүлия! Минем монда килеп харап буласыны сигез ай элек үк әйтте. Мин тиле ышанмадым, бәхет эзләргә киттем, шундый алтын кешене ташлап киттем. Хәзер төшендем, әмма ләкин соң. Мин Сәләхетдин абзый янына китәм. Аңардан гафу үтенергә кайтып китәм һәм вәссәлам!

Иртәгесен Мөнәвир гариза язып директор янына керде.

— Хуп, мәйле, — диде әкә, гаризаны укып караганнан соң. — Хәерле сәфәр! Игелексез кеше икәнсең...

Директор Мөнәвирне ничек алган булса, эшеннән дә шулай бик җиңел генә чыгарып җибәрде.

Менә күрәсез, Мөнәвир инде әкә янында түгел, ә абзый янында утыра. Шул ук күпне күргән хезмәт кенәгәсен тотып Сәләхетдин абзый янында утыра.

— Үткәннәрне онытыгыз, Сәләхетдин абзый, гафу итегез, гаебемне тирем белән юармын, аңлыйсызмы? — ди ул.

— Миндә эш тормас... Коллектив гафу итәрме соң?

Сәләхетдин абзый урыныннан торып ишекле-түрле әйләнеп килде дә яңадан урынына барып утырды. Күрәсең, үткәндәгеләрне ул Мөнәвирдән дә ныграк кичерә иде.

Икесе дә бер авыз сүзсез утырдылар.

— Әй, егетләр... — дип мастер көрсенеп алды һәм культбудкадан чыгып китте. Мөнәвир тәрәзә аша аның буровойга таба алпан-тилпән генә атлавын күзәтеп торды.

Сәләхетдин абзый кулы белән ымлап югарыдан верховойны чакырып төшерде, эшне туктатып торырга кушты. Бораулаучылар аяк өсте генә Сәләхетдин абзый белән нәрсәдер бик кызып-кызып сөйләштеләр, бераз кычкырышып алдылар. Мөнәвир тәрәзә аркылы кайсыныңдыр «кирәкми» дигән сүзен дә ишетеп калды төсле. Шуннан соң Сәләхетдин абзый тагын кемнедер үгетләде кебек, бармаклары белән культбудка янына таба төртә-төртә Мөнәвирне күрсәтте.

Мастер биш-алты адым китте дә янә буровойга әйләнеп килде. Бу юлы инде алар тыныч кына сөйләштеләр.

Аларның хәрәкәтләреннән Мөнәвир үзенә хөкем ясаганнарын аңлады. Ул, тәрәзә яңагына поскан хәлдә, аларның гадел карарын көтте.

Ниһаять, башын, муенын кулъяулыгы белән сөртә-сөртә Сәләхетдин абзый культбудкага керде.

— Эшне дә, тормышны да яңадан башларга туры килер, энем, — диде ул, Мөнәвир янына утырып. — Буровой эшчесе итеп алырга булдык. Риза булмыйсың икән, әнә, үзең чыгып сөйләш...

— Рәхмәт, туганнар, мин риза, бик риза! — диде Мөнәвир. Шатлыктан аның күңеле тулган иде.

— Я, я, син ир бул! — диде Сәләхетдин абзый Мөнәвирнең күз яшьләрен күргәч. — Яз гаризаңны. Мә каләм, мә кәгазь!

Мөнәвир берсүзсез каләмне тотып алдындагы кәгазьгә иелде. Күз яшьләре таммасын өчен керфекләрен кысты.

# Яшь шагыйрьләр тавышы

Дифгать Сирай

## Кайберәүләрне балык кызыктыра

Киләмен дә,
Татлы хискә бирелеп,
Каршылыймын Идел таңнарын...
Дулкын кебек,
Текә ярга кагылып,
Уяталсаң иде талларын.
Аның кебек
Һәр чак ярсый-ярсый
Барсаң иде алга, турыга.

Алган үрең
Калсын иде артта
Һәйкәл булып үткән юлыңда.
Шулай димен.
Әйдә, бар йөрәкләр
Шул омтылыш белән тулсыннар.
...Кайберәүне балык кызыктыра,
Мин юләрне—һаман дулкыннар.

## Көзге этюд

Аударырга теләгәндәй
Җил селкетә куакларны:
«Вакыт җитте, китегез»,—дип
Куа җәйге кунакларны.

Тик агачлар көрсенмиләр,
Җил йөрсә дә азып-тузып;
Яфрак төшсә, бөре кала
Килер язгы хәбәр булып.

## Сүрелми

Поезд килгән саен каршы чыгып,
Юлчыларны күздән кичерәм.
Менә ул да килеп кочар диеп
Мин юанып куям эчемнән.
...Кемнәр белми солдат дуслар белән
Көрешкәндә туган хисләрне.
Тартынмыйча,
Күзне-күзгә текәп,
Сөйләшәсең баштан кичкәнне.
Ашлар куера,
Чәйләр суынып бетә,
Вакытны да сизми каласың.
Китәм дисә, тагы берне кун, дип
Үгетлисең, сәбәп табасың.

Озатканда күңел йомшап китә,
Керфек буйлап яшьләр йөгерә.
Сине яратучы дускаеңнан
Аерыласың гүя гомергә.
Аннан башка гүя беркемең юк,
Андыйларны күңел тапмас та...
Запаста без.
Ләкин походларда
Туган дуслык чыкмый запаска.
...Күпме поезд инде үтеп китте.
Ул күренми, һаман күренми...
Ә шулай да
Көтәр кешең булгач,
Килер дисең, өмет сүрелми.

## Сандугач

Ботакка басып сайрый сандугач. —
Тавышы дәртле.
Матур көйләрне сайлап алган ул
Кайдан шул хәтле?

Сайрый җилкенеп, хәтта агачлар
Чайкалган чакта.
Гүя җырлары тотып торалар
Аны ботакта.

● ● ●

Сөенечнең чиге бар микән —
Яңа туган бала кулында.
Хатыны һич бирми тынгылык:
— Матур исем кушыйк улыма.

— Хикмәт анда түгел, — ди ире, —
Азатмы ул яки Рөстәмме.
Шунсы әйбәт,
Тагын дөньяга
Бер тынгысыз кеше өстәлде.

## Күрсенми ул

Әкрен генә атлап
Бара Гариф,
Җиргә терәп имән таягын.
Их, куясы иде үз урнына
Ядрә өзеп киткән аягын...

Тик күрсенми Гариф.
Күрсенүдән
Ни файда бар, төптән уйланса:
Сау аяк та ярдәм итмәс иде
Басып торыр җире булмаса.

## Вышкалар

Вышкалар, вышкалар...
Санына
Чыгалмам ахры аларның. —
Гигантлар бизәгән Каманың
Элекке тын, сөзәк ярларын.

Вышкалар...
Маяклар шикелле
Еракка тезелеп китәләр:
Киләчәк көннәргә илтүче
Зур юллар шул төштән үтәләр.

*Салисә Гәрәева*

● ● ●

Аяз таңым!
Көлеп килгән яз шикелле,
Тормышымда бәйрәм булып балкыдың син.
Йөрәгемнән аккан җырым сиңа булсын,
Күңелдәге яшерен сөю ялкыны син!

Ярсып аккан язгы ташкын суы кебек,
Күңелдә гел якты хисләр кайнап тора,
Син уйлама боек диеп, тоныкдиеп,
Керсез җаным сандугачтай сайрап тора.

Аяз таңым!
Мин бәхетле, мин яратам!

Кирәк түгел миңа сүзләр,
вәгъдә, антлар...
Кара гына күзләремә сөю белән,
Шул карашны җырчы дусың
мәңге саклар...

Яз таңнары минем өчен үткән, диләр,
Күңел өчен язлар бетми икән, иркәм!
Мин бәхетле! Мин яратам, шуңа күрә
Күкрәгемдә якты, кайнар
кояш йөртәм!

• • •

Кызым үсә.
Аңлый бар нәрсәне,
Көннән-көнгә арта җорлыгы;
Кызыксыну дисәң — хәтәр инде,
Ә үзе соң — хөрмә зурлыгы!

Чәчләренә бантик куйган булам,
Тормый гына — чәче санарлык;
Елаганда энҗе күз яшьләрен
Алка итеп кенә тагарлык!

Кичен арып,
йоклый алмый ятса,
Сәйдәш көен аңа көйлим мин;
Һәм җирдәге һәрбер ана кебек
Тыныч, матур еллар телим мин.

## Карамадым

Урам аша ашыгып узган чакта
Карашымны тартыр өченме,
Кул изәдең,
борылып карамагач
Әкрен генә әйттең исемемне.

Ә мин, юләр, сиңа омтылсам да,
Горурлыкмы, ашыга идемме, —
Ни өчендер борылып эндәшмәдем,
Кылана бит, ай-һай! — дидеңме?

Карамавым бәлки яхшыгадыр,
Горур булсаң — кадер арта бит;
Бер карамый барыбер булмас инде,
Никтер сиңа күңел тарта бик...

## Урал туфрагында

Урал туфрагына тартты күңел,
Таныш түгел юллар әйдәде;
Еллар мине,
аерып Минзәләдән
Урал туфрагына бәйләде.
Урал!
Тауларыңнан тавышым
яңгырап кайтсын,
Җырым илтсен хисләр ташкынын!
Гашыйк булып сиңа Ләйлә сыман,
Юлларыңнан үтәм ашкынып!
Туган яклар ерак-ерак калды,
Ерак моннан ямьле Казан да,
Минем эзләр Ильмен карларында
Бу юлларны язып язганда.
Язылмаган җырлар аһәңедәй,
Олы бер көй яңрый күңелдә;
Хыялымда ашам кыялардан,
Бөркет булып Урал күгендә!

## Беренче сөйгән кешем

Яратсаң — эзләп табарсың,
Онытсаң — ихтыярың;
Син минем яшьлек таңымда
Беренче сөйгән ярым.

Беренче сөйгән кешем син,
Беренче кабынуым;
Күңелдә йөртеп төсеңне,
Беренче сагынуым.

Иң беренче оялуым,
Беренче сагышым син;
Йөрәк хисеннән уянган
Каләмем тавышы син.

*Егор Уткин*

## Яз да тамчылардан башлана

Март бураны күпме дуламасын,
Күрче, һава ничек ачылган.
Түбәләрдән җиргә энҗе тама —
Яз башлана нәни тамчыдан.

Тамчылардан шаулы яз уяна,
Ташый инеш, ташый бар сулар.
Ак каеннар яшел яфрак яра,
Купшылана тугай, басулар.

Кимсенмә син гади хезмәтеңә,
Юкка кырын караш ташлама.
Җаның олы булса — һәр эш олы!
Яз да тамчылардан башлана.

● ● ●

Урам тулы дәртле аваз —
Бала-чага шау-шуы.
Урамда яз. Балалардай
Шаулап ага кар суы.

Уйныйлар, уйнап туймыйлар,
Арылсын арылмасын.
Әй яз! Күкләрең күкрәсен,
Тик туплар ярылмасын.

● ● ●

Мин читләтеп үттем инешемне, —
Ду килешә инеш ярында
Бала-чага. Тарсына бит алар
Кайчак өлкән кеше барында.

Тын чоңгылда балык каптырулар
Ничек кенә кызыктырмасын!
Мин читләтеп үттем — шат тавышлар
Беркайчан да тынып тормасын.

Сабый чакны сугыш тартып алды,
Күпме кыен юллар үтелде...
Без тормышка кердек, —
Ташны ярып,
Шытып чыккан гөлләр шикелле.

● ● ●

Тумагансың көзге айларда да,
Ник соң болай чуар холыклы?
Көнгә унбиш тапкыр кояшлы син,
Көнгә унбиш тапкыр болытлы.

Өлгермәдем әле тоярга да,
Сөюеңне, татлы назыңны.
Көзге урман кебек төрле төскә
Ник кертәсең яшьлек язымны?

Мәхәббәткең көчен, тирәнлеген
Вакыт кына сыный дөньяда.
Буш савыттай нигә шалтырарга,
Тирән елга бит ул тын ага.

## Пианист кызга

Куллары ла нәфис, житез аның
Гүя аккош канат кагына.
Чиртеп нечкә күңел кылларына
Залга сихри моңнар агыла.

Чылтыр-чылтыр тау чишмәсе ага,
Тау итәге, хәтфә болыннар,
Иркен кырлар... Ниләр, ниләр генә
Хәтерләтми икән бу моңнар?

Әй, гүзәл кыз, нигә син җаныма
Иөрәгеннең куштың ялкынын?!
Бүркем кулда килеш кайтканмын мин,
Онытканмын январь салкынын.

*Газиз Камалов*

## Авылымның чишмәләре

Һәркемнең барып иләшкән
Яраткан чишмәсе бар.
Һәркемнең вагъдә куешкан
Иртәсе, кичәсе бар.
Бергә чишсеннәр серләрен,
Вәгъдәләр ныгытсыннар.
Һәм көянтә-чиләкләрен,
Суларын онытсыннар...
Чишмәләр аксын, тамчылар
Шаяртып сикерсеннәр,
Җырлашып салкын суларын
Инешкә җиткерсеннәр.
Әйтсеннәр мәхәббәт белән
Йөрәкләр дөрләгәнен,
Ялгыз ай күреп аларны
Көнләгәнен...
Саф сулы, көмеш тавышлы
Авылымның чишмәләре.
Һәркемнең була бәхетле
Иртәсе, кичәләре.

## Киттең

Серле итеп, өмет биреп
Күземә багып киттең —
Хисләремне яктылыкка,
Нурларга манып киттең.
Күңелемә, уйларыма
Исемең язып киттең —
Очкын түгел, ялкын түгел
Вулканнар ягып киттең.
Үзең сизми йөрәгемне
Еракка алып киттең —
Күкрәгемә түзәлмәслек
Сагыну салып киттең.

*Гәрәй Рәхим*

## Буыннар елъязмасы

*1938 ел*

Алар — кырык бер шат егет
Шаулап яши.
Дөньядан тик чын бәхетне
Даулап яши.

*1941 ел*

Алар бит — кырык ир инде
Һәм бер егет.
Онытылмаслык дәһшәтле көн
Җитте килеп, —
Кырык хатын карап калды
Кырык иргә.
Кырык малай туып калдык
Кырык бердә.

*1944 ел*

Ерак кырда кырык ир иде
Һәм бер егет.
Барысы да Ватан өчен
Калды үлеп.

*1958 ел*

Бер авылда кырык егет
Җырлап үстек;
Әнкәйләрдән әткәйләрне
Сорап үстек...

*1961 ел*

Кырык берәү кырык өчен
Үлгән җиңеп.
Утыз тугыз ир инде без
Һәм бер егет.

*1965 ел*

Утыз тугыз малай туды
Инде бездә.
Утыз тугыз малай карый
Безнең күзгә:
— Тагын шулай дәһшәт белән
Бер көн килеп
Сез — әтиләр кайтмассызмы?.. —
Дигән кебек.
Утыз тугыз малай яши
Бик рәхәттә.
Алар кырык булыр менә
Киләчәктә.
Бумасын дип кабат кара
Язмыш килеп,
Тынычлыкны уяу саклар
Кырык егет.

# Беренче күкрәү

Бик җырлыйсым килә
Бүген минем,
Бар тавышка,
Көчле иттереп.
Бүген минем
Язгы күкрәү белән
Бер күкрисем килә
Гөр килеп.
Яңгыр болытлары
Сыймый күккә,
Бер-берсенә бәрелә, сөртенә.
Алар бәрелүеннән утлар уйный,
Күкләр күкри, таулар селкенә.
Иң беренче күкрәү...
Буразнада,
Маңгаена куеп кулларын,
Атам карап тора болытларга —
Ул белә шул анда ни барын.
Ул белә шул — иң беренче яңгыр
Җиргә яшәү, яшьлек китерә.
Борын төрткән япь-яшь үләннәрне
Колагыннан тартып үстерә.
Ул белә шул,
Иң беренче күкрәү
Ирек бирми җиргә кибәргә.
Яңгыр көтеп көн дә бөртә торган
Бөреләрне ачып җибәрә.
Маңгаена ике кулын куеп,
Атам карап тора югары.
Сакалыннан ташу акты инде,
Киемнәре тәмам чыланды.
Нигезенә,
Баскан туфрагына
Иң беренче күкрәү көн биргәч,
Шыпырт кына:
— Булды,
Икмәк булды, — диде, —
Ил интекмәс,
Ие, интекмәс!
Менә шуңа,
Язгы күкрәү кебек
Бер күкрисем килә
Гөр килеп.
Минем бүген
Бик җырлыйсым килә
Бар тавышка,
Көчле иттереп!

# Очерклар

*Галим Шәйхиев*

# МАТУР ТУГАНДА

●

«Муеным сындырырмын ахыры мин монда!» — яңа председательнең колхоз хуҗалыгы белән танышып чыкканнан соңгы беренче фикере шул булды. Ә бит ничек кенә мактамадылар бу артельне. «Тыңлагыз, Урта Балтай сөйли!», «Ныклы адымнар», «Әхиятдин бабай әкияте» шикелле башлар астында эре хәрефләр белән бирелгән зур-зур хәбәрләр өлкә газетасының күренекле урыннарыннан кычкырып торалар иде. Журналистлар шушы колхоз турында әллә ничә очерк язып чыгардылар. Язучы Әмирхан Еники да үзенең «Егет кунакка кайтты» дигән китабын бирედә торып, шуннан рухи азык алып язган иде ич!

Кайда соң бирედә алар күрә алган хозурлык, алар мактаган күркәм хәзинәләр кая киткән?!

Башын аска иеп урам буйлап барган Хәмидуллинны берәү дә туктатмады. Чирмешән чокырындагы каз-үрдәкнең дә аңарда эше булмады. Аларга нәрсә, түшләре күмелерлек су таптылармы, шул җитә. Әмма председательнең фикерләре ничек кенә чуалган булмасыннар, үткен күзләре исә бер генә нәрсәне дә читләтеп үтмәде. Бу чокыр булып калган ярлар кайчандыр су белән тулып торгандыр. Әнә, буа ясый торган урын култыкланып күренә. Биредә күпер булган. Аны ташудан соң яңадан төзәтмәгәннәр, ахрысы. Калдык агачларын балта белән чапкалап алып киткәннәр... Таушалган, бөтенесе дә менә шушы сусыз калган Чирмешән чокыры шикелле.

Ә райкомдагы сводкалар ал да гөл иде бит. Икмәк заданиесе елның-елы үтәлеп килә. Сөт, ит сату буенча да колхоз районда алдынгыларның берсе булып күренә. Каян килгән соң бу саннар, кем биргән, нинди оятсыз кул язган аларны?! Дөрес, моңарчы укытучы булып эшләгән һәм «эквивалент» дигән сүзнең илаһи кодрәтен белмәгән кеше өчен болар бөтенесе дә караңгы иде әле. Бу колхоз җитәкчеләре генә түгел, район үзе дә әнә шул «эквивалент» белән яши иде ул чакта. Бәрәңге, яшелчә заданиесе үтәлмәдеме, эквивалент исәбеннән чыгып, икмәк белән капларга була иде. Ит һәм сөт урынына, тагын шул эквивалентка таянып, икмәк тапшырдылар. Фураж калмады. Чәчүлекне дәүләттән ссудага алдылар. Аны язгы пычракта заготзерно кадәр җирдән жилкәгә салып ташыдылар. Менә шул 1953 елны да әле Урта Балтайдагы Крупская исемендәге колхоз членнары һәр хезмәт көненә бары 147 грамм ашлык алдылар...

Авыр уйларга бирелгән Хәмидуллин үзенең авылдан чыгып ук киткәнлеген абайламый да калды. Менә ташлы чокырлы ак ба...

жирләр башланды. «Кабул ит, председатель, сиңа калган мирас шушы инде», дигәндәй, алар ниндидер бер җылылык көткән сыман Хәмидуллинга карыйлар төсле тоелды. Ул изүләрен чишеп җибәрде. Ак балчыклы ярга ятып, туфракка күмелердәй булып, җир сулышын тыңлады. Ике пульс бергә кушылгандай булды. Гүя, председательнең йөрәк тибешенә кушылып, җир дә җавап бирә, аның — күп хәсрәтләр күргән изге җирананың да — йөрәге ярсый-ярсый типкәндәй тоелды аңа. Хәмидуллинны ниндидер бер рәхәтлек чолгап алды. Башта кечкенә генә, сизелер-сизелмәс кенә булган бу сихәтле тамчы җанны уятты, тәнгә ниндидер сихри көч таратты һәм Хәмидуллин җирдәге вак ташларны да сизмәстәй булып, бала вакытындагыча, бер тәгәрәп алды. Мондый рәхәтлекне бала чактан ук җиргә ялан аяк баскан һәм җир кочагында эшләп үскән кеше генә сизә белә!..

● ● ●

Беренче көн шулай үтте. Ә иртәгесен инде таң белән үк эшкә керешергә кирәк иде. Идарәгә беренче булып ферма мөдире Габдулла Фәтхуллин килде. Ул Хәмидуллинның күптәнге танышы. Әле Дәвештә укыткан чагында ук алар районда үткәрелә торган киңәшмәләрдә бергә очрашалар, президиумда да янәшә утырганнары бар иде. Үзе юкта авыл кешеләренең Фәтхуллинны «ярты Гаптул» дип атаганнарын да ишеткәне бар иде Хәмидуллинның. Бу икенче исемне Габдулла Бөек Ватан сугышыннан алып кайтты. Тездән югары ике аягын да өздереп, госпитальдә дәваланганнан соң, аны авылга кадәр медсестралар озата килделәр. Менә шул Гаптул район хәрби комиссариатыннан үзенә пенсия кенәгәсе китерүчене култык таягы белән куып чыгарган, дип тә сөйлиләр.

— Миңа мескен итеп карамасыннар. Үземә бер сынык икмәк табарлык көчем бар әле, — дигән ул, ярсуына чыдый алмыйча. Мәктәп балалары аңа коляска ясап биргәннәр. Шуның белән йөреп, Габдулла шактый вакыт клуб мөдире булып эшләгән. Ул чакларны Урта Балтай клубының үзешчән сәнгать коллективы район смотрларында беренчелекне алып килгән. Менә шул Габдулланы, сөт җитештерүдә кризис килеп тугач һәм учет эшләре буталгач, товарлыклы-сөтчелек фермасына мөдир итеп күчергәннәр. Гәүдәгә ярты гына булса да, ике кеше җилкәсенә салырлык йөкне күтәрә ул. Фермада — мөдир дә, учетчы да, авыл Советында — даими комиссия председателе — культура эшләрен оештыруда башлап йөрүче кеше.

Бу юлы да Фәтхуллин председатель янына зур йомыш белән килгән иде. Сүз терлекләрне җәйге лагерьга күчерүдән башланды.

— Фермада сыерлар да картайды, савымчылар да карчыклар гына калды. Яшьләрнең бик үк киләселәре килми, — диде Габдулла, хәлне аңлатканнан соң. Аннары нәрсәнедер оныткан төсле уйланып торды да:

— Әллә терлекчеләрне акчалата түләүгә күчерикме икән? Кызыксынулары арта төшәр иде, — дип куйды.

Тәкъдимнәр күп җыелды бу көндә. Администраторлыкны төп эш стиле дип санаган һәм үз фикереннән чыгып кына командалык итәргә яраткан элекке председатель заманында томаланып килгән уй-фикерләр бөтенесе дә өскә калкып чыктылар.

Педагог буларак кешеләрне үзенә тарта белсә дә, колхоз хуҗалыгына җитәкчелек итү тәҗрибәсе булмаган Хәмидуллин өчен бу мәсьәләләрне чишү бик авыр иде әле. Райкомда да, авыл хуҗалыгы бүлегендә дә төпле киңәш бирүче булмады. «Һәр тармак буенча җиткерелгән план бар. Сезнең төп бурычыгыз шуны үтәү. Сукмактан чыкмаска тырышыгыз», — диделәр аңа. Ә бу сукырга таяк тоттыру шикелле генә иде.

Менә колхоз хисапчысы, чал чәчле карт Әхиятдин бабай Рәхмәтуллин председатель алдына артельнең еллык отчетыннан күчереп алын-

ган мәгълүматлар кәгазен китерде. Андагы саннар һич тә күңел юатырлык түгел иде.

«Һәр гектардан уңыш 4,14 центнер.

Еллык акча доходы 51.708 сум.

Һәр сыердан уртача савым 695 литр.

Банктагы хисапта акча калдыгы 5 сум 25 тиен...»

Хәмидуллин башкаларын укып тормады. Бүген Чирмешәнне буарга, сулык ясарга тиешләр иде. Ул шунда китте. Анда да кешеләр нигәдер теләр-теләмәс кенә эшлиләр иде. Авыл Советы председателе Зиннәт Баһавиев бер читкәрәк алып китеп, серне чиште. «Мәгәрич көтәләр алар» дигән сүзләрне ишеткәч, Хәмидуллин ачуына чыдаша алмады. Каты сүз ишетмәсә дә, председательнең кызыл тимгелләр чыккан йөзенә, чытырдатып кысылган йодрыкларына карап, аның хәлен аңлаган Баһавиев кулларын җәйде:

— Электән шулай килә. Бүген генә төзәтеп булмый, туган, — диде ул.

— Бер бозганны төзәтү өчен тагын күпме тапкыр бозарга кирәк бит. Баштан ук кизәнергә ярамас. Үтсен әйдә, бу юлыга,— дип, Хәмидуллин «белгәнегезчә эшләгез» дигәндәй кулын селтәп китеп барды. Ул никадәр тирән ялгышуын бер атнадан соң, партия райкомы бюросына баргач кына аңлады...

● ● ●

Бюрога иртән үк килеп җитәргә куштылар. Хәмидуллин юлга чыкканда, кояш офыктан аз гына күтәрелгән иде әле. Юл буе чирәмнәрендә чык бөртекләре ялтырый. Җирдәге тереклек өчен бердән-бер җан бирүче әнә шул тамчылар иде. Чәчүгә кадәр дә яңгырлар булмады. Соңгы бөртекләрне күмдергәнгә дә бер атна була, ә табигать һаман юмартлыгын күрсәтми иде. Ел җиңелдән буласы түгел, ахрысы. Менә инде язгы гөнаһлар да күренә башлады. Бодай, солы басуларында чәчелми калган урыннар балалайка сыман, бормаланып-бормаланып торалар. Әйтерсең, ул участокларда биләүсәле малай ятып калган да, аның йокысын бозмас өчен читтәнрәк әйләнеп үткәннәр. Күп әле, бик күп саксызлык, әрәм итү дә күп. Колхозчыны да гаепләп булмый. Нәрсәгә кызыксынып эшләсен соң ул?

Хәмидуллин, әле кичә генә идарәдә бригадир Фәһим Мөхәмmәтгалимов сөйләгәнне исенә төшереп, көрсенеп алды. Бибинур Газимова эшкә чыкмый калган икән. Икенче көнне бригадир аны беркадәр кыздырып алырга теләгән. «Болай эшкә салкын карасаң, хезмәт көнеңне дә кисәрбез», дип сүз генә башлаган икән, тегесе шаркылдап көлеп үк җибәргән. «Бәй, Фәһим абый, көнем җәл түгел, без бит аңа барыбер бернәрсә ала алмыйбыз, берүк төнемне кисә күрмәгез, йокларга калсын», дип бригадирның авызын каплаган да куйган.

«Бу көйгә барып булмый, халыкны ничек кенә булса да кызыксындырырга кирәк, күңел биреп эшләрлек бер чара табарга кирәк», дип уйлады председатель...

Ә җиңел арбага җигелгән юрганың уйлап торырга вакыты юк. Ул һаман элдерә, юлаучысын тизрәк илтеп җиткерергә кирәк. Әнә бормаланып аккан Зөя дә артта калды. Юлның ике ягында су ята торган җирләр. Җәен анда әрем, каты агач үләне үсә. Үткән-барган хатын-кызлар аны идән себеркесенә җыялар. Менә сабан туе урыны. Наратлык. Тау төшәсе дә аннары район үзәге — Апас. Райкомда ни көтә, нигә дип чакырганнар икән? Хәер, белмәссең. Бюрода беренче булуы гына кыен. Аннары күнегәсең. Ә Хәмидуллинның әле бюро членнары алдына беренче басуы.

Кеше күп чакырылган. Урамда да, райком бинасы коридорында да, янәшә кабинетларда да бюрога килүчеләрне очратты Хәмидуллин. «Нигә

инде һәркемне үз сәгатенә туры китереп чакырмаска. Эш калдырып, монда тупланып ятудан кемгә файда бар», — дип уйлады ул. Ләкин ачыктан-ачык әйтергә батырчылык итмәде.

Арада яңа председательләр — яшьләр дә күп. Состав бигрәк тә үткән елгы урып-җыю кампаниясе вакытында күп үзгәрде. Эчке кирәкләргә барлык сугылган ашлыкның 15 процентыннан артык тоткан өчен әләкте кайберәүләргә. Икенчеләре кулдан ягулык-майлау материаллары сатып алган өчен ычкындылар. Сукмактан читкә тайпылма, дип кисәтүнең дә нигезендә нәкъ менә шулар ята иде.

Бюро бик озакка сузылды. Хәмидуллинның «персональ эшен» көн тәртибенең егерме дүртенче мәсьәләсе итеп карадылар. Оештыру бүлеге мөдире Хәйбуллин урыннан килгән жалобаны укыды. Анда түбәндәге юллар бар иде: «Апас районының Крупская исемендәге колхоз председателе Гашикъ Хәмидуллин колхоз дисциплинасын таркатуга алып бара, артель байлыгыннан явыз ният белән файдалана. 12 май көнне, елганы буабыз дигән булып, «коллектив пьянка» ясадылар. Бер капчык песоктан самогон кудыртып, бөтен начальство җыелышып эчтеләр».

Хәмидуллин ничек дип тә аңлатырга урын тапмады, хәер, аклану юлын эзләмәде дә. Тик аның—бергә эшләүче, йөкне үзең белән бергәләп тартучы кешенең (ул жалобаның авторы Баһавиев икәненә шикләнмәде) шулкадәр пычрак атуына гына җаны әрнеде. «Димәк, яратмый, күрә алмый, ниндидер ярасына басканмын. Теге председатель белән бик әшнә дигәннәр иде. Бәлки, шул ачудыр. Юк, ничек кенә булмасын, почмактан торып ату кешелеклелек түгел. Гайбәт ул». Жалобаны укыганнан соң урнашкан кыска вакытлы тынлык эчендә Хәмидуллин күңеленә шундый уйлар килде.

Кинәт тынлык бозылды. Урындыгын артка этәреп, райкомның беренче секретаре Харис Заһретдинов сикереп торды:

— Позор, түбәнлек бу! Хәмидуллин кем тегермәненә су коюын беләме икән?! Колхозда шабашниклар тудырасыңмы? Эх, син, педагог. Без аны ныгытырга җибәрәбез, ә ул беренче көннәреннән үк тарката башлый...

Сүзләр, тәкъдимнәр күп булды. Кемдер: «Каты шелтә бирергә кирәк», диде. Кемдер аңа каршы төште. Яшь кадр, тикшерү белән чикләнеп калсак та ярый, диде. Ут, су кичкән карт коммунист, райкомның пропаганда бүлеге мөдире Фатих ага Адаматов кына бер якка да кушылмады.

— Кызмыйк, иптәшләр, — диде ул. — Мондый очракта беренче тәэсирләрдән чыгып кына, үлчәп карамый торып кисәргә ярамый. Хәмидуллин — яшь кадр. Өйрәтергә, ярдәм итәргә кирәк. Колхоз председателен тиз генә әзерләп булмый бит. Үткән көзне дә күпме кадрларны югалттык. Ә бит аларның берсе дә үзе өчен тырышмады, колхоз хуҗалыгын алып бару өчен көчәнде. Уйлап карагыз, минем сүзем шул.

Бу юлыга Хәмидуллин шелтә белән котылды. Коридордагылар аны юатып озатып калдылар. «Бусы гына түзәрлек әле, котелмәгән хәлләр дә килеп чыккалый. Нишлисең, югарыдан күрсәтмә шундыйдыр», дип иң өлкән яшьтәге председатель Сәйхунов аның җилкәсеннән сыйпап калды.

Ләкин тынычланырга иртәрәк икән әле. Колхозда тәртип урнаштыра, акча артыннан гына чабучыларның койрыкларын кисә башлагач, райкомга исемсез хатлар ташкыны тагын да арта төште. Икешәр бакча тотучыларга, ит, йомырка белән Казан юлында йөрүчеләргә, көтүе белән терлек асраучыларга да җәелергә урын калмады. Әрәм тамакларны кыса төшү белән бергә Хәмидуллин, партия оешмасы һәм идарә членнары белән киңәшеп, хезмәттә үз-үзләрен аямыйча эшләүчеләрнең интересларын күздә тота торган чаралар да күрде. Колхозда эшкә чыгуны исәпкә алу буенча, совхоз системасындагыча, наряд тәртибе кертелде.

һәр наряд кәгазен биш көнгә бер яба бардылар. Бу тәртип хезмәткә акчалата түләүгә күчә башлау иде инде.

Уракка төшү алдыннан, ярты еллык хезмәт нәтиҗәләреннән чыгып, колхозчыларга акчалата аванс бирелде. Дөрес, финанс тәртибен беркадәр бозарга туры килде. Тулып җитмәгән өлешенә производство кирәкләренә алынган кыска сроклы ссуданы да кушып җибәрделәр. Исәп шулай иде: беренче акчалата аванс, гомумән, яңача түләү тәртибе терлекчеләр өчен өстенлеклерәк итеп эшләнде. Бу фермаларда эшне яхшыртырга стимул булачак иде. Ә инде продукцияне реализацияләүдән килгән табыш ссуданы капларга артыгы белән җитәчәк. Киңәйтелгән кабат житештерү процессында капитал салуны дөрес оештыруның ролен Хәмидуллин институтта укыганда ук хәтеренә салган иде. Ул аны практикада да оста кулланды. Әмма бу беренче талпыну гына иде әле. Бөркет баласы да беренче талпыну белән генә очып китә алмый, диләр ич. Шулай да бу кыю чара колхозчыларның, ничә еллар буе икмәк игеп тә, үз хезмәтләренең нәтиҗәсен күрмәгән, артталыкка күнегеп беткән Урта Балтай кешеләренең күңелләрендә яңа тойгы уятты, ышаныч чаткылары кабызды.

Халык җилкәне киңрәк җәйгән, адымны ышанычлырак атлый башлаган бу көннәрдә тагын колхозга тикшерү белән килделәр. Райком инструкторы Гайнетдинов тикшерү эшен авыл Советы бүлмәсендә алып барды. Коммунистларны, тармак мөдирләрен, кайбер колхозчыларны чакырып сөйләште. Ике көн утырып, командировка кәгазенә печатьне дә авыл Советында суктырып, соңыннан янгын сакчылыгындагы атны җиктереп китеп тә барды. Тикшерүчеләрнең үзе белән очрашырга теләмәүләре, бөтенесен дә яшертен генә алып барулары Хәмидуллинны беркадәр борчуга салды. Әмма ул монысының да элекке җитәкчеләрнең тарафдарлары язган чираттагы әләкләү икәнлегенә һич тә шикләнмәде. Тик күп вакыт үткәч кенә авыл кешеләре арасында: «Үзен зампредтан төшергән өчен Бари Каюмов үч тота икән. Хәмидуллин өстеннән ЦКга язган икән», дигән хәбәрләр таралды. Була бит шундый көнче бәндәләр. Берәвесе үзенең хәленнән килмәгәнгә көнләшә. Икенче берәвесе — янәшә хезмәттә эшләүчесе — миннән узып китәр дә мине кысрыклап чыгарыр дип көнләшә. Менә шушы искедән калган йола кадрлар сайлаганда да бик зур зарар китерә. Начальник кеше зам итеп гадәттә үзеннән көчсезрәкне, сүзсез буйсынучан, ул әйткәнне куәтләүче юмакайны куярга тырыша һәм шулай итеп тылны ныгытам дип уйлый.

● ● ●

Хәмидуллин колхозда беренче күргәннәрен «яшьлек хәтирәләре» дип кенә искә ала. Председательнең киң маңгаена тирән эзләр салган, чәченә кырау төшергән әнә шундый «хәтирәләр» аркасында бит кайберәүләр туган якларыннан, семьяларыннан аерылдылар, урынсыз газапланууларга дучар ителделәр.

Эзләре күптән күмелгән бу вакыйгаларның минем күңелемдә күп еллар үткәннән соң калкып чыгуына нәрсә сәбәпче булды соң? Шул ук кешеләр белән унбер ел үткәннән соң яңадан очрашумы, әллә колхозның бүгенге тормышын күреп соклануумы? Бәлки, алары да тәэсир иткәндер. Әмма үткәндәгеләр турында уйландыра торган һәм күңелдә ябылып ятканнарны айкап ташларга мәҗбүр иткән вакыйга аларыннан күп тапкыр тәэсирлерәк. Ул — КПСС Үзәк Комитетының 1965 елгы март Пленумы. Аның карарларын укыгач, нәкъ менә Хәмидуллин сөйләгәннәрне күз алдыннан кичерәсең. Һәм үткәндәгеләр янәшәсендә хәзерге тормыш тагын да ачыграк, гүзәлрәк чагыла.

Максатны әйткәч, миңа КПССның Апас райкомында нәкъ үзем уйлаган колхозга барырга тәкъдим иттеләр.

— Күптәнге председательләрдән менә Сабир Сафин бар. Әмма Хәмидуллинда кызыклырак материаллар таба алырсыз, — дип киңәш бирде райкомның беренче секретаре Шамил Мостаев. Ул шундый бер эпизодны да искә төшереп алды.

Үткән елның көзендә райком һәм авыл хуҗалыгы производство идарәсе район колхозлары алдында катнаш силосны күбрәк әзерләү бурычын куйганнар. Бирелдәге хуҗалыклар өчен яңа нәрсә бу. Идарә белгечләре техниканы көйләү, эш процесслары белән таныштыру өчен кайсы да булса берәр колхозда тәҗрибә семинары үткәрергә дигән фикерне әйтәләр.

— Күпчелек председательләр шундый сорау белән мөрәҗәгать иттеләр. Әле кичә генә Хәмидуллин да шалтыратты, — ди идарәнең баш зоотехнигы Гобәй Сәләхов.

— Ә нигә аның үзендә, Крупская исемендәге колхозда, оештырмаска? — дип тотып ала Мостаев.

Моннан соңгысын инде мин Хәмидуллинның үзе сөйләгәннәрдән белдем. Райкомнан хәбәр алгач та ул механизаторларны чакырып киңәшә. Әле ул көнне силос базлары да, катнаш силос әзерләү өчен җайлаштырылган техника да булмый. Колхоз елның-елы кукурузны җир өстендә силослап килгәнлектән, элекке чокырлар онытылган хәлдә ятканнар.

— Аккордно-премиаль түләү билгеләдек. Бурычны төшендердек. Кешеләр көнен-төнен белми эшләделәр. Ә өч көннән соң, район колхозларыннан семинарга килүчеләргә тулы көченә эшләп торучы агрегатны күрсәтә алдык, — ди председатель. Менә бит ул мораль һәм материаль стимулны бергә кушуның илаһи көче.

Колхоз савым сыерлары һәм дуңгызлар өчен мең тонналап катнаш силос әзерләгән. Туклыклылыгы ягыннан концентраттан калышмаучы бу азык ит һәм сөт чыганагы булып хезмәт итә. Фермаларга барып керсәң, кыш көне дә хуш исле җәй һавасын сулыйсың. Күңелгә бик яхшы тәэсир итә торган икенче ягы да бар икән әле аның. Анысы идарәнең отчет кәгазьләреннән күренә. Элек елына 695 литр сөт биргән сыерлар хәзер 2 мең 400 не бирәләр. Бу бит дүрт тапкырга якын үсеш! Саннарга күчкәнбез икән, инде башкаларын да мәхрүм калдырмыйк. Хәмидуллин эшләгән чорда (төгәлрәге соңгы ун елда) иген уңышы ике тапкырдан күбрәккә, акча доходы биш тапкырга арткан. Колхозчылар хезмәтенә түләү дә шундый ук пропорцияләрдә үсә бара. Хезмәткә өстәмә рәвештә генә дә былтыр 114.750 сум акча түләнгән. Колхоз капиталь төзелешкә ел саен 150—200 мең сум средство тота.

Без артельнең терлекчелек хуҗалыгын карап йөрибез. Менә «П» хәрефе формасында кирпечтән эшләнгән кошлар фермасы. Аны кошчылык фабрикасы дип атарга була. Тик янында инкубаторы гына юк. Дуңгызлар торагы да зур группалап асрау өчен көйләнгән, типовой проект буенча салынган. Сыерлар фермасы дүрт рәтле. Быел анда машина белән саву мәйданчыгы да булачак.

— Терлекчелекне колхозның үз эчендә специаллаштыруга юл тотабыз. Вак фермаларны бергә туплау төгәлләнеп килә, — ди иптәш Хәмидуллин.

Яңа биналар янында таушалган элеккеге корылмаларның әле дә торуына гаҗәпсенүемне күргәч, ул көлемсерәп өстәп куя:

— Бусы инде үзенә күрә колхозның үсеш диаграммасы. Аннары без ул биналарны кирәк-яракны саклау өчен файдаланабыз.

Кайту уңаенда без колхозның техника паркына тукталдык. Ремонт мастерское да яңа гына салынган. Шунда ук гомуми ашханә. Язгы һәм җәйге кыр эшләре вакытында ашларны кыр станнарына, трактор агрегатларына илтеп бирәләр.

«ДТ-54» тракторы янында ике егет сөйләшеп тора. Икесе дә урта мәктәпне тәмамлаган һәм тракторчы-слесарь квалификациясен шунда

алганнар. Ринат Сәләхов «ДТ-54», Касыйм Сибгатуллин «Т-40» тракторында эшләячәкләр. Беренче сезон. Күңелле дә, аз гына шикләнү дә бар.

— Безнең мәктәп хәзер колхоз өчен төп кадрларны әзерләү комбинаты шикелле,— ди председатель.

Хәер, мәктәп белән колхоз арасындагы бу элемтә күптәннән килә инде. Аңа беренчеләр булып Талия Гаязова белән Әминә Хәбибуллина юл салдылар. Сигезенче класста укыганда ук тавыклар фермасында эшләп, алар елга һәр тавыктан 140 ар йомырка алганнар иде. Шефлык елдан-ел киңәя барды. Һәм хәзер инде терлекчелек тулысы белән яшьләр кулында.

Мәктәп кадрлар әзерләүне ике профильдә алып бара. Малайлар тракторчы булып чыгалар, кызлар — терлекче һәм яшелчә үстерүче. 40 гектарлы участокта укучылар производство бригадасы иген уңышын күтәрү буенча сорт-сынау эшләре алып баралар. Анда яңа алмаш, колхозның киләчәге үсә, формалаша.

● ● ●

Кич. Авылда хезмәт симфониясе дәвам итә. Ул кырлардан клубка, уку өенә, китапханәгә күчә. Анда агро-зоотехника түгәрәкләренең чираттагы занятиеләре башлана. Алдынгы тәҗрибә мәктәбендә игенчелекне һәм терлекчелекне алып баруның яңа алымнары өйрәнелә. Кешеләр зур эш белән мәшгуль. Хәзер аларның бер-берсеннән чүп эзләргә, донос язарга вакытлары юк. Ул чаклар онытылган. Шәхси интереслар бөтен халыкның гомуми интереслары белән бергә бәйләнгән бу көннәрдә бөтен көч бер ноктага суга, йөрәкләр бергә тибә.

Ә бит моңа ирешү өчен күп көч куелган. Әле хәзер дә Хәмидуллинның яратып кабатлый торган бер сүзе бар: «Көн саен бер генә кешенең аңын сафландыру да җитәкче өчен зур җиңү ул». Бу юлда, сафлык өчен көрәшләр юлында, күп сынаулар кичкән ул Хәмидуллин. Һәр адымында кешеләргә, аларның әйткән киңәшләренә таянып эш иткәнгә күрә генә колхоз хуҗалыгы бүгенге дәрәҗәгә ирешә алган.

Коллектив җитәкчелек органы — бригада советлары шушы колхозда беренче тапкыр килеп тугач, күп кенә председательләр бу яңалыкка кырын карадылар, аяк астындагы җирне ычкындыру дип санаучылар да булды. Әмма совет идарәнең җитәкчелек ролен киметмәде генә түгел, аның актив ярдәмчесе булып китте. Хәзер советта Фәттах Шакиров, Гаяз Шиһабиев, Галихан Габбазов, Зариф Рәхимов кебек картлар белән бергә, Лена Гафарова, Люция Гыйззәтова кебек яшь колхозчылар да утыралар. Яшьләрнең белеме картларның тәҗрибәсе белән бергә кушылып, авыл хуҗалыгын үстерүдә яңа резервларны ачуга ярдәм итә. Инспекторлар киңәшмәсе, экономик анализ бюросы кебек ярдәмче комитетлар массаны колхоз белән идарә итүгә киңрәк тартуның, иҗат активлыгына киң юл ачуның бик мөһим формалары.

Бригада советлары колхозда күп кырлы эш алып баралар. Андагы утырышларда производствоны планлаштыруның яңа формаларын эзләүдән алып колхозчыларга материаль ярдәм күрсәтү, кешеләрне тәрбияләү мәсьәләләренә кадәр карала.

Сәйфи Шәгалиев яхшы электрик була. Йортларда электр приборларын төзәтергә, яңа чыбыклар үткәрергә туры килә аңарга. Хезмәт өчен «натуралата» түләүчеләр дә табыла. Егет эчә башлый. Советта тикшереп, хәлне ачыклаганнан соң, аны тракторга күчерергә дигән тәкъдим кертәләр. Бригадир да килешә, идарә дә хуплый. Хәзер Сәйфи алмаштырып куйган шикелле.

Совет тәкъдиме белән колхозда индивидуаль төзелеш кузгатучыларга биреп тору өчен озак сроклы ссуда фонды булдырыла. Ә инде ар-

тельдә озак еллар хезмәт итеп пенсиягә чыккан Фатима Камалиева кебекләргә артель средствосы хисабына берничә йорт салынган.

Колхозда аерым фермаларны, бригадаларны хуҗалык исәбенә күчерү буенча да талпыныш ясап караганнар.

— Әмма әлегә кадәр төпле бер нәтиҗәгә килеп булмады. Елына җидешәр задание җиткереп, производство планын җидешәр тапкыр үзгәрткән тәкъдирдә нинди хуҗалык исәбе кертергә мөмкин иде соң, — ди Хәмидуллин. — Менә хәзер, кагылгысыз план заданиеләренә кучкәч, бу төп мәсьәләне дә хәл итүе реаль нигезгә корылачак.

Әйе, Март Пленумы карары колхоз авылы хезмәт ияләренә ачык перспективалар бирде, шаблонның тамырына балта белән чапты. Әлегәчә бит авыл хуҗалыгы белән кем генә командалык итмәде. Ит вәкиле... Сөт вәкиле... Икмәк вәкиле... Райкомнан нинди генә вәкилләр килмәде. Һәркайсы — давай да давай. Ә нинди материаль кызыксыну бар иде ул давайдан. Бу уңайдан Хәмидуллин кызык кына бер үткәндәгене искә төшереп алды.

1959 ел. Колхоз ашлык тапшыру заданиесен үтәгән. Ә артель членнарының хезмәт көненә ашлык бүләргә һаман рөхсәт итмиләр. Көтмәгәндә райкомнан яңа өстәмә задание килеп төшә. Нишләргә? Фуражсыз калсаң, терлекчелеккә удар. Колхозчыны да кыерсытып булмый. Председатель үзенең бухгалтериясен ашыгыч эшкә куша. Тикшерү килгәнче, ике ведомостьны кладовойчыга төшереп җиткерәләр. Берсе— контрактация тәртибендә колхоз фермасына бозау китерүчеләргә тиешле ашлык, икенчесе — колхозчылардан алып торылганны кире кайтару. Фактта исә бернинди бирәчәк тә булмый. Ә шул ведомостьлар аркасында фураж сакланып кала. Үзеңнекен үзеңнән яшерү иде бу. Менә бит шаблон нәрсәләр генә эшләргә мәҗбүр итмәде.

— Исәп белмисез. Кулыгызга карандаш алып эш итмисез, дип теңкәгә тиделәр. Андый шартларда ничек итеп исәпләргә мөмкин иде соң? — ди Хәмидуллин, көрсенеп.

Колхозда иң доходлы культура булган киндер мәйданы яртылаш кысрыкланган. Ә нигә аерым артельләрне билгеле бер техник культура игүдә специаллаштырмаска?! Туфракка ашлама кертүне дә производство идарәсе билгеләп, колхозга планын җиткергәч, агрономнарга нәрсә эшләргә кала иде соң? Инициативаны чикләүме бу? Нәкъ үзе.

Хәмидуллин — күпне белергә теләүче, җиде кат үлчәп, бер кат кисүче кеше. Фән казанышлары, алдынгы тәҗрибә аның өчен бетмәс-төкәнмәс хәзинә. Әле яңа гына Казан авыл хуҗалыгы институтының читтән торып уку бүлегендә дәүләт имтиханнары тапшырып кайтты. Шуңа да ул белемнең кадерен тоя, колхозның урта буын кадрларын теоретик яктан әзерләүгә һич нәрсәне кызганмый. Зоотехник Нурулла Гатауллин хәзер экономистлыкка укый, шофер Һарун Закиров, механик Илдус Хәйбуллин — авыл хуҗалыгы институты студентлары.

— Таләпләр үзгәрә. Шуңа күрә иске багаж гына җитми. Иске багаж ул һәр елны бер тирәнлектә сөреп, асфальтка әйләнгән җир катлавы шикелле генә. Аннан дым да килми, һава да йөрми, — ди укырга теләмәүчеләргә карата председатель.

Бүгенге ирешелгәннәр әле беренче баскыч кына. Тагын күпме атлыйсы, күтәреләсе бар әле. Менә колхозда ашламалар куллануның яңа технологиясе кертелә. Ул электәгедән бөтенләй аермалы. Елның-елы бар черемәне чөгендер һәм кукуруз участокларына кертеп бетерү тулы эффект бирә алмады. Шуның белән чәчү әйләнеше дә бозылды. Хәзер исә, колхоз идарәсе, белгечләр һәм инспекторлар киңәшмәсе ашламалардан яңача файдалану тәртибен эшләделәр. Бер елны бер кыр, аннары икенчесе тулы дозада ашланачак. Моның өчен черемә генә җитми. Исәп компостка кайтып кала. Торф күп.

Орлыкчылык эшен яхшыртасы бар. Монысы да җиңел генә түгел. Мәсәлән, колхозда ике ел «Отечественная» сортлы бодайны Чувашиядән алып кайтып чәчеп караганнар. Кабул итү пунктындагы белгечләр «безнең республикада расланмаган» дип сорт өстәмәсе өчен түләүдән баш тартканнар. Уңышны яхшы бирсә дә, аны бетерергә туры килгән.

Болынсыз колхоз өчен люцерна, тимофеевка да кирәк. Капылт кына сөреп аттык, ә ул үләннәрдән башка терлекләр ач кала язды. Әйе, мәшәкать җитәрлек. Әмма болар бөтенесе дә күңелле мәшәкатьләр.

Председатель кесәсеннән «Правда»ның 27 март санын тартып чыгара. Анда кызыл карандаш белән сызылмаган бер генә юл да юк. КПСС Үзәк Комитетының март Пленумында иптәш Л. И. Брежнев доклады Хәмидуллинның иң якын сердәше булып әверелгән:

— Һавалар үзгәрә. Җылыга таба бара, — ди ул көлемсерәп һәм жирле радионы тоташтырып җибәрә. Ә анда Урта Балтай сөйли. Колхоз авылының бүгенге көне, якты киләчәге, авыл хезмәт ияләре алдында торган яңа перспективалар турында сөйли ул. Шуларны тыңлыйм да мин тагын бер тапкыр Хәмидуллинның башыннан кичергәннәрен күз алдыма китерәм. Әйе, дим мин, кешеләрне үз ялкыны белән яндыра алган җитәкче генә зур коллективны бердәм, тату семьяга тупларга сәләтле.

---

## *Латыш халык мәзәкләре*

### ТЕЛ ЭЗЛӘҮ

Бик усал һәм бик четерекле бер хатын, бер дә кирәксезгә ачуланып, иренә атна буе бер сүз дәшми икән. Якшәмбе көнне аның ире көпә-көндез шәм кабыза да чорма-чоланда актарына башлый.

— Нәрсә эзлисең? — дип сорый хатын.

— Синең телеңне югалттым. Әгәр табылса, мин аны шәпләп кенә авызыңа яңадан урнаштырам һәм син тагын сөйли алачаксың.

### ЗИРӘК АКЫЛ

Мин бик яхшы аучымын дип мактанып йөргән берәү мылтыктан да рәтләп ата белми икән. Берчакны ул көн буе урманда йөреп кайта. Өендә хатыны сорый, ди, моңардан:

— Я, берәр нәрсә эләктерә алдыңмы?

— Кая ул анда җәнлек эләктерү! Көчкә качып котылдым — берьюлы йөз бүре очрады миңа, карчыгым.

— Тагын алдашасың бит!

— Алайса илле генә булсын!

— Лыгырдама юкны!

— Ким дигәндә егерме бар иде...

— Ишетәсем дә килми!

— Әмма акылың зирәк тә соң, карчыгым, пристав итеп куярлык кеше син. Шулай булгач, әйт инде: куаклыкта нәрсә кыштырдады икән?

### САКЧЫЛ ЗАТ

— Синең хатын бик сак һәм бик сакчыл диеп сөйлиләр, Тенис, дөресме шул?

— Бик дөрес! — дип җавап бирә Тенис. — Ул хәтта тирәюньгә дә бер күзен ачып, ә икенчесен йомып кына карый — бозылмасын дип, күзләрен шулай саклый ул.

### БӘЛА КИЛГӘЧ

— Бәлага тардым, хатын, балта төшереп ботинкам башын кистем һәм балта очы аягыма да тиде...

— Эх син, шайтан! — дип кычкыра хатыны. — Алайса бит син яңа оекбашыңны да кискән буласың.

# УРТАК ТЕЛӘГЕБЕЗ

*(Язучы блокнотыннан)*

Быелгы яз турындагы, дөресрәге, март Пленумы турындагы фикерләремне мин үткән ел март аенда булган бер сөйләшүдән башларга телим. Ул чакта районнарга командировкага чыккан идем. Шул вакыт, район үзәгеннән шактый ерак булган совхозга барышлый, бер авылда кунып калырга туры килде. Мин тукталган йорт хуҗасы бик юмарт һәм сөйләшүчән кеше булып чыкты. Ул колхозлашуның беренче елларыннан бирле гел буразнада эшләп килгән. Шунлыктан, аның игенчелеккә карата һәм бер игенчелеккә генә түгел, гомумән авыл хуҗалыгының барлык мәсьәләләренә карата сине уйга калдыра торган үз фикерләре барлыгы аңлашылды.

Тары ярмасыннан пешерелгән аксыл-сары ботка ашап утырабыз. Ботка шулкадәр тәмле ки, мин бу ашка карата үземнең гаять дәрәҗәдә канәгать икәнлегемне әйтмичә кала алмадым:

— Бик рәхмәт сезгә, бигрәк тәмле булып пешкән, — дидем.

Хуҗа җавап урынына үзен борчыган мәсьәләне кузгатты:

— Тары ярмасы, мине суда пешерсәгез, икегә генә ярылам, ә сөттә пешерсәгез, җидегә ярылам, дип әйтә ди. Бу да шулай җидегә ярылып пешкән. Һи, туган, тары боткасына ни җитә!.. Тик менә аңа, нишләптер, үги итеп карыйлар шикелле.

Ул үзе яши торган авылда да, тирә-юньдәге башка авылларда да тары чәчүнең елдан-ел кими баруын сөйләде. Аннары кинәт карабодайга күчте:

— Карабодайга да шундыйрак караш сизелә. Ә бит карабодай боткасы тәнгә җиңеллек кертә, сихәтлек бирә ләбаса! Элек-электән үк: «Солдатларның ашаганы — карабодай боткасы...» — дип җырлаганнар бит. Чынлап та, аны ашап кайсыбыз гына рәхәтләнмәгән! Аннары ул ярма гына биреп калмый, бал да бирә ләбаса! Шуңа карамастан, аны чәчүгә кырынрак карыйлар... Безнең авыл басуларында карабодай гомергә котырып уңды. Хәтта аны арба белән ерып чыга алмаган елларны хәтерлим мин.

Ул кичне, тары боткасы ашап, чәй эчкәннән соң да, без урында килеш озак кына сөйләшеп яттык. Ул сүз арасында чәчү әйләнешеннән чиста парны чыгаруның дөрес түгеллеге турында да әйтте.

Берничә көн үткәч, мин иртә белән радиодан соңгы хәбәрләр тыңлап, уйга калып утырдым. Анда, дөрестән дә, чиста парны хурлап, аны чәчүле пар белән алмаштыруны алга сөрәләр иде. Ул көнне чәчүле парны шулкадәр яклап сөйләделәр ки, хәтта шушы турыдагы бер үк мәкаләнең баш өлешендә «чәчүле пар» дип, уртасында «биләмле пар» дип, ахырында «биләүле пар» дип, өч төрле термин кулландылар. Әлбәттә, чәчүле пар да кирәк. Ләкин чиста пардан бөтенләй баш тарту һич кенә дә дөрес түгел.

Мин үзенең фикерләре белән әлеге чыкылдап торган колхозчы агайны искә алдым.

Март Пленумы күп кенә җитди хаталыкларны ачып салды һәм чиста парга да, карабодайга да, тарыга да тиешле урын бирде. Аларны сатып алу бәяләрен күтәрүне кирәк тапты, бу культураларны игүдә катнашучыларга әстәмә түләү тәртипләрен билгеләде.

Солы турында да берничә сүз әйтәсем килә. Солы кешеләр өчен дә, терлекләр өчен дә бик файдалы культура. Сөлек кебек шома гәүдәле, көр атлар турында халык: «Моны солыга тәмам катырганнар», — дип әйтә икән, бу инде тикмәгә генә түгел. Ә менә соңгы елларда авыл хуҗалыгына югарыдан торып «күрсәтмә» бирүчеләр шулчаклы «акыллы» башка әйләнделәр ки, хәтта алар солының иген икәнлеген инкарь итеп, аны чәчүдән бөтенләй кул селтәүгә кадәр барып җиттеләр.

Әйе, март Пленумы бу төр культураларны чәчүне яңадан торгызды. Хәзер инде безнең басуларыбызда карабодай катык кебек ак чәчәк атып, тары саргылт ефәктәй чукларын асып, солы исә яшкельт төймәле сыргаларын тагып утырачак. Һәм, ниһаять, кайсы колхозда, нинди иген чәчәргә кирәклекне шунда яшәүчеләр үзләре сайлаячаклар. Бу нәрсә дигән сүз? Бу — кешеләргә инициативага юл кую дигән сүз. Дөрестән дә, әгәр шаблон күрсәтмәләр белән теләсә нинди мәсьәләгә килеп тыгыласың икән, ул чагында кешеләр ике кулсыз калалар, эштән сүреләләр, гомумән, аларның гайрәтләре чигә. Бу уңай белән кызыклы гына, берүк вакытта бик аянычлы мисал китерер идем. Миңа кайсы елныдыр, бервакыт шулай кызу урак өстендә Арча районының бер колхозында булырга туры килде. Андагы председательнең гаҗәп энергияле, гел булсынга гына эшли торган кеше икәнлеген күптән белә идем. Ул көнне мин аны басудан да, ферма тирәләреннән дә эзләдем, ләкин таба алмадым. Кемдер аның кәефе юклыгын, бүген бөтенләй күренмәгәнлеген әйтте. Өенә киттем. Барсам, ул чоланда ята. Үзе авырмый да, йокламый да.

— Нишләп болай тик ятасың, Шаһиәхмәт абзый? — дидем аңа.

Ул әчке бер ризасызлык һәм әрнү белән:

— Районнан уполномоченный килде бит, минем кирәгем юк, — дип җавап кайтарды.

Мондый уполномоченныйларның колхоз председательләрен, колхозчыларны «өйрәтүләре» кайчакларда шул дәрәҗәгә җитә ки, гомер-гомергә иген иккән бу кешеләр гүяки бер нәрсә дә белмиләр булып чыга. Хәлбуки, шушы уполномоченныйларның үзләренә килсәк, алар арасында, бигрәк тә игеннәр әле яңа тишелеп чыгып кәс каплый башлаган чорда, теге яки бу культураны аера белмәүчеләр дә очрый. Алар солыны бодай, бодайны солы дип, сине шуңа ышандырырга тырышалар.

Менә шуның өчен дә март Пленумы колхозларга квалификацияле җитәкчелек итүне төп бурычларның берсе итеп куйды.

Пленум прогрессив яңалыкларны, файдалы тәҗрибәләрне практикага кертергә кирәклекне әйтте. Берүк вакытта теге яки бу тәҗрибәне уйламыйча, шул килеш кабул итүнең ярамаганлыгын да кисәтеп куйды. Дөрестән дә, «һәрбер ялтыраган алтын булмый» бит. Моны хәтердә нык тотарга кирәк.

Пленум материалларын һәм шулар нигезендә чыгарылган карарларны укып карагач, чын күңелдән сөенәсең. Ашлыкны һәм терлекчелек продуктларын сатып алуның бәяләрен күтәрү, колхозларга салына торган доход налогларын киметү, еллар буе өелеп килгән бурычларны списать итү кебек һәртөрле җиңеллекләр һәм шәхси хуҗалыкларда терлек асрауны чикләүләрне бетерү — болар һәммәсе дә бөтен халыкка файда бит. Боларны буш кул белән, коры куаныч белән каршы алып кына калмаска, ә җир байлыгын арттырганнан-арттыра бару өчен көрәшергә кирәк. Бу исә, шулай ук, бөтен халык эше. Чөнки бөтенебез бергә көрәшкәндә генә безнең һәрберебезнең алдында күкрәккә терәп каерып-каерып кисәрлек, тегермән ташы чаклы икмәк торачак һәм һәрберебезнең авызында бал-май булачак! Бу — синең дә, минем дә, бөтенебезнең дә уртак теләгебез!

*ГАРИФ ГАЛИЕВ.*

# Әдәби тәнкыйть

Гали Халит

## ЯҢА ГЕРОЙ НИЧЕК ТУДЫ

I

Һәр заманның алдынгы язучылары яңа герой образын сурәтләп калдыру теләге белән рухланып иҗат итәләр. Сүз сәнгатенең төп максаты беренче нәүбәттә шуннан гыйбарәт икәнлеге күпләр тарафыннан кат-кат әйтелгән инде. Татар әдәбиятының да чирек гасыр күләмендәге бер кисәк тарихын алып карасак (бу урында без аның 1905—1930 еллар арасындагы чорын күз алдында тотып сүз алып барачакбыз), яңа герой өчен көрәшнең үзәк мәсьәләләрдән берсе булып торуын күрербез. Заманның алдынгы кешесе мәгънәсендәге яңа герой проблемасы татар әдәбиятында XIX йөзнең азакларында ук күтәрелгән иде инде. Беренче милли роман һәм драмаларда гәүдәләнгән мәгърифәтче геройлар шул юнәлештәге беренче норматив үрнәкләр булдылар. Мәгърифәтчелек әдәбиятының бу матур үрнәкләрендә халыкка хезмәт итүче яңа кешенең гуманистик образын бирү шикелле максатның яралгылары бар иде. 1905 ел революциясе алып килгән яңа шартларда алар тагын да күтәрелеп, бөреләнеп киттеләр. Кыю әйтергә мөмкин ки, барыннан да элек прогресс хакына, кеше азатлыгы һәм халык бәхете өчен, иске дөнья белән мөнәсәбәтен өзәргә ашыккан яңа герой, Тукайча әйткәндә, «Фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егет», XX йөз башындагы татар әдәбиятында үзенең хаклы урынын алды. Хәзер инде бу герой алдан әзерләнгән әдәби нормалар һәм мораль догмалар кысасында түгел; ул күп очракта үзлегеннән хәрәкәт итә, үз теле белән сөйли, үзенчә уйлый һәм кичерә, төрле иҗтимагый, интеллектуаль һәм психологик интереслар дөньясында яшәү хокукын даулый, заманның зур иҗтимагый-политик идеяләреннән һәм сыйнфый каршылыкларыннан читләшми. Шуңа күрә аны гомумән түгел, ә билгеле бер иҗтимагый мохитның вәкиле мәгънәсендәге әдәби характер һәм тип итеп, аерым язучының иҗат көзгесендә чагылган индивидуум — герой итеп карарга бөтен нигез бар. Чыннан да, бу геройны иҗтимагый тирәлек һәм рухи-әхлакый каршылыклар эчендә, сәбәпле бәйләнешләр дөньясында тасвирлау кебек детерминизм тамыр җәя башлады. Үткән җәмгыять үзенең иҗтимагый-сыйнфый табигате белән бик чуар һәм каршылыклы булганлыктан, ул чор әдәбиятындагы уңай герой характерында да шул чуарлык һәм каршылыклар, әлбәттә, гәүдәләнергә тиеш булды. Болар социалистик революция алдыннан җитлеккән татар демократик әдәбиятындагы яңа геройның гомуми сурәтендә дә тирән эз калдырдылар.

И. Нуруллин «XX йөз башы татар әдәбияты» дигән хезмәтендә (Лекцияләр курсы, 2 нче кисәк, 1964 ел) «ике лагерь арасында урталыкта калган катлауга игътибарның артуы» (25 бит) турында әһәмиятле бер фикер кузгатып, моның көчле реалистик үрнәкләре Ф. Әмирхан иҗатында барлыкка килүен әйтә. Һичшиксез, бу язучыны «татар тормышының алмашыну көннәрендә» мәйданга чыккан геройлар аеруча кызыксындырды. Аңа кадәр шул ук темага караган кайбер үрнәкләрне драматургиядә Г. Коләх-

метов биргән иде. «Ике фикер» һәм «Яшь гомер»дәге яңа геройлар тормыш һәм фикер каршылыклары эчендә формалашалар. Алар арасында үзләренең сыйнфый максатларын ачык аңлаган Вәли һәм Йосыф кебек революцион эшчеләр генә түгел, бәлки, Давыт һәм Гали шикелле, урталыктан революция, халык ягына күчүче интеллигентлар да бар. Дөрес, Коләхметовның бу геройлары белән Ф. Әмирханның урталыктагы типлары арасында аерма зур. Димәк, мондый герой проблемасына якын килүдә дә идея-эстетик аерымлыклар бу чор татар әдәбиятында яхшы ук тирәнәйгән икән. Гомумән алганда, бу аерымлыклар заман героен тумышыннан ук коеп куйган, статик хәлдә түгел, ә тормыш каршылыклары, фикер һәм хисләр көрәше аша күрсәтүнең төрлелеге, байлыгы турында сөйлиләр. Г. Ибраһимовның да революциягә кадәрге иҗатында әнә шундый тенденция — искелек белән яңалык көрәше эчендә үзенең уңай идеалын, туры юлын эзләүче геройны сурәтләү бик калку булып торды. Аның ике дәвер иҗатын бәйләгән «Безнең көннәр» (1914—1920) романындагы Давыт Урманов бу яктан аеруча гыйбрәтле. Урталыкта калган интеллигенциянең бер вәкиле буларак, Урманов аңлы революцион көрәш, алдынгы идеяләр юлына күчү газабын кичерә.

Билгеле булганча, социалистик революция алдыннан котырынып киткән декадентлык һәм модернизм кешенең ролен түбәнсетү, аның эчке матурлыгын һәм батырлыгын инкарь итү кебек антигуманизмны — кешегә каршы фәлсәфәне күтәреп чыкты һәм шуның белән сәнгатьне агулый башлады. Мондый рухтагы фәлсәфә һәм сәнгать, гадәттә, иске тәртипләрне төбе-тамыры белән куптарып ташлаячак революцион давылларга, халыкларның азатлык өчен көрәшенә каршы юл белән китте.

Алларында А. М. Горький торган һәм бөек классик әдәбият традицияләренә турылыклы булган язучылар азатлык һәм гуманизм байрагын югары тотып, кешенең матурлыгын һәм батырлыгын яклап тавыш бирделәр. «Кеше ул горур яңгырый!» — диде Горький, декадентларның кешене пычратуга юнәлтелгән черек фәлсәфәсен фаш итеп, һәм әдәбият кешенең рухи кыйммәтен, тарихны, тормышны яңадан коручы көрәшче булуын күрсәтергә тиеш дип чыкты. Шул рәвешчә, социалистик революция алдыннан кызып киткән әдәби-идеологик көрәш мәйданында сәнгатьнең төп героена — кешегә мөнәсәбәт мәсьәләсе кискен бер төскә керде. Шушындый ук көрәштән татар әдәбияты да читтә торып калмады. Аның да төп герое кем һәм ничек булырга тиеш? — дигән сорау куплагән татар язучыларының идея-эстетик программасын билгеләде. Алар шул сорауга җавап бирү юлында кыен эзләнүләр һәм каршылыклар кичерделәр. Әмма аларның идеалында да «көч белән бергә гүзәллекне җыйган»[1] кеше образына мәхәббәт якты маяк булып янып торды. Яшь татар совет әдәбияты үзенең өстенә менә шундый геройны бөтен чынлыгы, тормышчанлыгы һәм гүзәллеге белән чагылдыру бурычын алды. Аның миссиясе гаҗәп тә җаваплы һәм мактаулы иде. Шуңа күрә дә, совет әдәбиятының асыл новаторлыгы нәрсәдән гыйбарәт? — дигән сорауга, барыннан да элек, социалистик революция белән тарих сәхнәсенә чыккан гади кешеләргә тапкыр яңа геройны илһамлы итеп сурәтләү дип җавап бирәсе килә. Бу бурычның, проблеманың күләме һәм хәл ителеше төрле чорларда һәм әдәби жанрларда ничек кенә булмасын, татар совет әдәбиятының башлангычында ук инде тарихның якты сәхифәләренә бөек азатлык идеалларын үз каны белән язган кешене югары күтәреп күрсәтү ачык иде.

Октябрь революциясе ил һәм халык язмышын хәл итү өчен тарихта һичбер вакыт булмаган реаль мөмкинлекләрне алып килде. Сәнгать дөньясының да нигездән яңарыyна киң юл ачты. Бу юл — һәртөрле изелү һәм хурлыклардан азат кеше атлый торган олы юлдан читтә була алмый иде инде. Һәм яңа чор әдәбиятына да әнә шул кеше беренче герой булып килеп керде, аның беренче мәртәбә горур тавышы ишетелде:

Мәңге газап, мәңге коллык, мәңге хурлык,
Мәңге изелү, мәңге елау һәм әрнүләр...
Кирәк түгел, кирәк түгел, — хөрлек телим,
Юлларымда кан-яшь күрмим, коллык күрмим,
Азат булыйм, азат торыйм, азат яшим,
Тыныч эшләп, тыныч кына гомер сөрим!..

*(Г. Харис. «Ни өчен?» 1919)*

[1] Г. Тукай. «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре», 1912.

Бу, һичшиксез, гасырлар буенча ирек даулап килгән һәм, шуның өчен үзен һәрвакыт корбан итәргә әзер торган халык идеалының яңа лирик герой аша яңгыравы иде. Шулай итеп, революциянең беренче елларында ук әнә шундый герой татар әдәбиятын тулысынча яулап алды дияргә мөмкин. Аннардан башка безнең әдәбиятның язмышын хәл итү мөмкин түгеллеге елдан-ел бөтен зурлыгы һәм авырлыгы белән ачыла барды. Байтак вакытлар дәвамында ул герой, үзендә «тумыш тапларын» саклаган хәлдә, әдәби традицияләрнең төрле һәм калын катламнары арасыннан, үзенә лаеклы новаторлык кыюлыгы белән, зур тормыш эченә юл салырга тиеш иде. Бу юл аңа алдан әзерләнеп һәм шомартып куелмады. Нәкъ шушы урында атаклы немец язучысы И. Бехерның: «Яңа сәнгать бервакытта да яңа формалардан башланмый, яңа сәнгать һәрвакыт яңа кеше белән бергә туа», — дигән тирән мәгънәле сүзләрен кабатлыйсы килә.

Социалистик революция татар әдәбиятына яңа идея коралы бирде: халыкның һәртөрле дошманнарына каршы рәхимсез сыйнфый көрәш пафосы белән үтәдән-үтә сугарып, аны тарих ташкыннарының уртасына алып керде. Шушы көрәш идеясе кешелекне алга әйдәүче һәм аерым сыйныфларның, аерым шәхесләрнең язмышын хәл итүче бердәнбер көч итеп аңлана башлады. Нәкъ шушы җирлектә күп кенә татар язучыларының дөньяга карашында яңа тарихи омтимизм — пролетариат революциясенең җиңүенә, аның тарихи закончалыгына һәм кешелекнең яңа дәверен ачуына ышаныч тамырланды. Революция, азат халык һәм иреклe ватан яшь татар совет әдәбиятының иң илһамлы тема һәм мотивларына әверелеп, алар киң массаларның хәрби-политик энтузиазмы, гражданлык һәм патриотлык тойгылары белән тирәнтен сугарылдылар. Болар һәммәсе әдәбиятның яңа героена хас сыйфатлар да иде. Бу герой үзе теләп кызыл солдат булган һәм революцион көрәш романтикасы белән рухланган яшь лирик герой ролендә мәйданга чыкты:

Авыр көрәш... ирекле эш... иркен тормыш...
Тик шуларга багышлана бар җырларым.
Җырлыйм һаман... «Җиңәбез!» дим, иманым там,
Алга барам... авырлыклар куркытмый һич.
«Канлы көрәш аша иркен тормыш», —
Шигарем шул: мин — көрәшче яшь коммунист!.. —

*(М. Максуд. «Минем җырларым», 1920)*

ди ул герой һәм үзе баскан көрәш юлының бик авыр, канлы икәнлеген аңлый, әмма бу юл якты, бәхетле тормышка илтәчәгенә ышанып җырлый һәм көрәшә. Заманның революцион тормышына хас батырлык романтикасы иде бу.

Әлбәттә, бу романтик герой нигездә риторик һәм схематик әле. Аның сәнгатьчә дәрәҗәсе югары, камиль түгел. Аны шартлы рәвештә, мәсәлән, йөз сызыклары ачылмаган мрамор фигура белән чагыштырырга мөмкин. Бу фигура скульпторның бик җентекләп һәм яратып эшкәртүен көтеп тора әле. Шулай да һәйкәлнең мәһабәт бер геройны сынландырырга теләве күзгә бәрелә инде. Ул үзенең пьедесталында башын югары күтәреп, горур басып кына калмый, ә үз заманы кешеләре белән бергә, җиңүчеләр ореолының нурлары эчендә киләчәккә табан ашкынып атлый:

Ирекле җан теләп алган юлым белән барам алга,
Барам һәм тиз җитәрмен изге теләк, изге идеалга, —

*(Б. Рәхмәт. «Тылдагы дошманга», 1919)*

дип кабатлый ул. Һәм аны, һичшиксез, яшь татар совет әдәбиятының үзәгендә торган яңа норматив герой дияргә мөмкин. Бу яктан ул киң мәгънәгә, эчтәлеккә ия, ләкин эстетик яктан — тар һәм абстракт. Аның шәхси, индивидуаль дөньясын күрү кыен. Психологик, хисси портреты юк дәрәҗәсендә. Ф. Бурнашның һәм башка күпләрнең «типовой» сюжетка корылган поэмаларындагы кыз һәм егет образлары да бер-берсеннән аерым булган индивидуаль эчке сыйфатларга ия түгелләр әле.

Заманның гомуми идея-эстетик рухы — политик максимализм, настроениеләрнең романтик канатлы булуы, революцион мөмкинлекләргә чиксез ышану — тәүге татар совет әдәбиятын шул елларда өстенлек иткән рус пролеткультчылык хәрәкәте белән

якынлаштырды. Ләкин бу якынлашуны пролеткульт доктриналарын, эстетик принципларын турыдан-туры һәм аңлы рәвештә уртаклашу дип карарга кирәкми. Дөрес, мондый тенденция дә берникадәр башланган иде инде. Шулай да бу уртаклык серен яңа чынбарлыкны сәнгатьчә кабул итүнең гомуми стихиясе ничек булудан эзләргә кирәк. Кешелек дөньясының бөтен почмакларын тетрәткән иҗтимагый шартлау булды, әмма бу тетрәү сәнгатьчә, художестволы аңда, хистә детальләр белән түгел, ә беренче нәүбәттә үзенең искиткеч мәһабәтлеге, грандиозлыгы белән чагылды.

Революция башындагы татар совет әдәбиятында абстрактлык һәм агитацион риторика ни дәрәҗәдә генә булмасын, аның яңа герое халыкка һәм революциягә хезмәт итү юлыннан батыр басып атлый башлады. Классик әдәбиятның гуманистик һәм демократик традицияләренә нык бәйләнгән бу герой шулай ук прогрессив романтизмга хас «героик индивидуализм»ны да кире какмады. А. М. Горький фикеренчә, «героик индивидуализм» ул «мин»нән элек халыкны һәм кешене икърар итә, үзенең рухында тормышның барлык шатлык һәм газапларын гәүдәләндерергә омтыла [1]. Бигрәк тә татар поэзиясендә шәхескә, кешегә революция биргән иректне халык азатлыгыннан аерымыйча хис итү элементларының чәчәк ата башлавы «реаль кеше шәхесен массаларның абстракт, суык образына батырып калдырырга» [2] омтылган пролеткультчыларның романтик героеннан нык кына аерылып торуны да искәртә иде.

Җыеп кына әйткәндә, социалистик революция темасына турыдан-туры бәйле яңа герой проблемасыннан башка татар совет әдәбиятының иҗат методын, яңа эстетиканың тормышчан җирлеген билгеләү мөмкин түгел. Ә яңа герой проблемасы исә бернигә еллык иҗат тәҗрибәсе белән генә хәл ителми, әлбәттә. Моның шулай икәнлеге гомумән 20 нче еллар дәвамында ачык күренде. Аеруча бу чорның башында поэзиябездә киң генә урын алган гыйсъянчылык яңа шартларда романтик традицияләрнең үзенчәлекле бер гәүдәләнеше булып мәйданга килде. Кайберәүләр уйлаганча, гыйсъянчылыкны аерым язучыларның нинди дер вакытлы мавыгуы дип карап, аңа бунтарьлык, анархистлык мөһере сугу белән генә чикләнү дөрес булып җитмәс. Ә чынлыкта исә, гыйсъянчылык ул яңа герой эзләүнең катлаулы төстә, традиция белән новаторлык күренешләренең үзара гаҗәп каршылыклы керешүе, аралашуы һәм бәрелешүе җирлегендә барганлыгын исбатлаган бер хәрәкәт. Гыйсъянчылык һәм гыйсъянчы герой татар әдәбиятына читтән килеп кермәде, ә демократик әдәбият традицияләре белән нык бәйле хәлдә чыкты. Аның да «тумыш таплары» ярылып ята иде әле.

Җирдәге һәм күктәге барлык иселек калдыкларына, яңалык дошманнарына каршы рәхимсез көрәш һәм ләгънәт игълан иткән гыйсъянчы герой күп очракта «мин» ролендә тавыш бирде. Аның биографиясе дә бик билгеле һәм гади: иске җәмгыятьтә ул кыерсытылган, җәберсетелгән һәм тормыш төбендә калган булса, хәзер инде ирекле горур кеше булган. Менә шундый герой үзен мәсхәрә иткән тормыштан, явызлыклардан үч алу теләге белән яна, аңа каршы «утлы, канлы сугыш» ача. Димәк, бу ягы белән ул гражданнар сугышы вакытындагы кызыл солдат бурычын дәвам иттерә. Ләкин гыйсъянчы герой, кулына корал тотып, сугыш кырларында ак бандаларга каршы көрәшеп йөргән замандашыннан бигрәк, үткәндәге романтик туганына күбрәк охшый. Г. Ибраһимовның «Көтүчеләр» (1913) хикәясендәге Вахит образын гына искә төшерик. Бу хикәянең революциядән соңгы редакциясендә Вахитның (шул ук «мин»нең) иске тормышка төбәлгән ләгънәт тирадасы барлык гыйсъянчыларга уртак рухта көчәйтеп җибәрелә: «Сөйләгез! Без, тормышның төбендәгеләр, сездән җавап сорыйбыз! Ничә мең еллык тәҗрибә иске юлларның хатасын ачмадымы, — без җавап көтәбез! Миллионнарча ач балалар, ачлыктан баласын имезергә сөте булмаган миллионнарча аналар, гомеренчә эшләп тә, ахырда урамга ташланган картлар, аһ-зарлары, кайгылары белән җир йөзен каплаган барча мазлумнар — без сездән җавап көтәбез...» — ди Вахит үткәнгә һәм аның даһиларына мөрәҗәгать итеп, иске тормышка каты хөкем чыгарып. 20 нче еллар башында калыккан гыйсъянчы да шундый ук пафос белән сөйләде. Әмма шуның белән бергә, ул үзенең элекке романтик туганы газапланган тар дөньядан батырлык мәйданына чыгарга, революция каһарманы булып, «тарих ташкыны» эченә ташланырга ашкына. Нәкъ шул урында гыйсъянчы геройның нечкә, йомшак җире —

[1] А. М. Горький. Несобранные литературно-критические статьи. М., 1941, стр. 394—395.

[2] В. Ермилов. Избр. работы, т. 3. М., 1956, стр. 366.

«Ахиллес табаны» күренде дә инде. Үткән тормыш белән исәп-хисапны өзеп, үзен революциягә багышлаган геройны гыйсъянчылар «саф пролетарий» рәвешендә күз алдына китерсәләр дә, чынлыкта исә андый герой, шул ук иске романтик плащны киеп, яңа шартларда да үзенә йорт-җир таба алмаган ялгызак (отшельник) сыман күренде әле:

Көрәшчеләр!
Сезнең арагызга яшь бер егет килә.
Аның да
Һичбер нәрсәсе юк:
Малы да,
Атасы да,
Анасы да,
Сөйгән яры да...

дип тәмамлаган иде Такташ үзенең бер шигырен («Такташ үлде», 1923). Һәм шушы сыйфатларны шагыйрь яңа геройга тапкыр дип күрергә теләде. Инде чынбарлык белән чагыштырганда, ул сыйфатларда традицион-романтик шартлылык, әдәбичелек никадәр күп булуы һәм кычкырып торуы турында сөйлисе дә юк.

Монда без гыйсъянчы геройның барлык билгеләрен санауны максат итмибез. Әмма шунысын әйтергә кирәк: яңа геройдагы революционлыкны, батырлыкны аңлауда шәхеснең «абсолют иреге» кебек идеядән бик ук ерак китмәсә дә, искелеккә бәйле дип каралган барлык нәрсәләрдән азат яңа кеше идеалы гыйсъянчылык эстетикасының да үзәгендә торды. Үзенең героен титаник кеше итәргә, аңарда көчле шәхесне күрергә теләү дә шундый идеалдан аерылгысыз иде. Гыйсъянчы геройда иске мәгънәсендәге романтик трагизм күпме генә булмасын, аның да төп юлы — революция башында бөтен гәүдәсе белән аякка баскан көрәшче — солдат салып калдырган олы һәм якты юл.

Гыйсъянчылыкка бәйле традицияләр безнең әдәбиятта вакытлы гына бер күренеш булды да үтеп китте, аларның эзләре калмады дигән караштан без ерак торабыз. Шул ук 20 нче еллар әдәбиятының барлык жанрларына аның тәэсире зур булды. Монда мәсьәләгә тик яңа геройны күрсәтү ноктасыннан гына кайбер фактларга һәм әһәмиятле моментларга кагылып китү белән чикләнәбез. Мәсәлән, 20 нче еллардагы татар әдәбиятында физик көчле һәм рухи горур геройны сурәтләргә омтылыш гомуми бер тенденциягә әйләнде диярга мөмкин. Әйтик, К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендәге Булат һәм качкыннар яки Ф. Бурнашның «Хөсәен мирза»сындагы Муса һәм качкыннар — болар шул ук гыйсъянчы геройлар. Алар 20 нче елларда да һәм аннан соң да сәхнәдән төшмәделәр. Мондый геройларның классик романтизм типлары (мәсәлән, Шиллернең «Юлбасарлар»ы һ. б.) белән якынлашып, аваздаш булып китүләре дә гаҗәп түгел.

Яңа геройны күз алдына китерүдә шундый ук романтик традициянең үзенчәлекле бер чагылышын Х. Туфан поэмаларында да күрергә мөмкин. Аларда да гаҗәп нык ихтыярга, физик көчкә, сирәк, уникаль характерларга ия булган, тышкы кыяфәте һәм эчке дөньясы белән гадәттәге кешеләрдән бик аерылып торган геройлар хәрәкәт итә. Туфанның берничә поэмасы аша үткән Хабул гына да моны тулысынча раслый. Иске тормыш белән көрәш эчендә элекке бунтарьның ничек яңа кеше, революция кешесе булып үсүенә җанлы мисал ул. Гыйсъянчы геройдан аермалы буларак, аңарда инде нәкъ менә шул нәрсә — яңа герой булып үсү тарихы, эволюциясе бар. Туфан үз геройларының иҗтимагый табигате белән эчке характеры, шәхси натурасы арасында уртаклык, гармония эзли. Бу урында алар социологизм кысаларыннан да бөтенләй үк азат түгелләр. Әмма шагыйрь бу кысаларны тарихи фон һәм тормышчан эпик чолганыш исәбенә киңәйтеп, геройларның җанлы, хәрәкәтчән булуына ирешә. Ә гыйсъянчы герой болардан мәхрүм булып, статик, катып калган хәлдә гәүдәләнде. Чөнки ул әле нигездә шартлы романтик герой иде. Ш. Усмановның «Таң» повестендагы Сөләйман образы да үзенең көчле һәм горур булуы белән шундый ук, ягъни Хабулга якын типлардан. Гомумән, мондый охшаш геройларны татар әдәбиятыннан күпләп китерергә мөмкин. Әлбәттә, татар әдәбиятында реализм принциплары ныгый барган саен, гыйсъянчы герой традицияләре дә тормышчан конкретлык, эпиклык шартларында реалистик төсмер алды. Шул ук Хабулны яки Сөләйманны гына алып карасак та, аларның чынбарлыкка нык тоташканлыгын, риторик һәм абстракт гыйсъянчылар гына булмавын күрербез.

II

Революциянең беренче елларында ук инде алдынгы татар совет язучылары чынбарлыкның катлаулы каршылыклары эчендә туа һәм формалаша башлаган яңа герой белән очраштылар. Әмма тормыш һәм көрәш белән тыгыз бәйләнгән героик характерны әдәбият битләрендә реалистик тулылык белән сынландыру югарылыгына берничә ел эчендә генә ирешү мөмкин түгел, билгеле. Моның өчен әдәбиятның үз эчке мөмкинлекләре дә өлгерү кирәк иде. Элекке әдәби традицияләр сәнгать зәвыкларын тулысынча диярлек биләп торган бервакытта, революционер, халык көрәшчесе кебек яңа герой образын тормышчан эпик колачларда, тирән драматик шартларда, аның катлаулы уй-тойгылары белән сурәтләү — бу гадәттән тыш зур иҗади бурыч иде. Ләкин моннардан һич тә, революциянең беренче елларында татар совет язучылары әнә шундый бурычтан ерак тордылар, аны аңламадылар, дигән нәтиҗә чыгарырга ярамый. Киресенчә, шул юлда беренче күренекле тәҗрибәләр ясалуы безнең әдәбият өчен бик тә сөенечле һәм мактаулы иде. Бигрәк тә драматургия жанры революция героен сәхнәгә чыгаруда беренче кыю адымнарын атлап, күп меңләгән гади тамашачыларның игътибарын яулап алды. 1919—1920 еллар арасында Ш. Усмановның «Канлы көннәрдә», «Беренче адым», Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр», Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» кебек драмалары язылу яшь татар совет әдәбиятындагы яңа герой образының ролен тагын да киңәйтеп һәм җанландырып җибәрде. Бу әсәрләрдә Камил, Батырхан һәм Кәрим шикелле, революцион-сыйнфый көрәш эчендә чыныккан яңа кешеләр алгы планга куелдылар. Дөрес, болар шулай ук нигездә норматив типлар. Чорның бөтен әдәбиятына хас агитацион максатка нык буйсындырылганнар. Җанлы кешегә тиешле күп кенә эчке сыйфатлардан алар мәхрүм иде. Ләкин бу геройлар ялгыз түгелләр һәм заманның зур көрәшеннән читтә тормыйлар. Шуның белән бергә алар, үзләренең замандашлары да иске тормышның һәм революциягә дошман идеяләрнең, шартларның колы булып калмасын дип, яңа кеше өчен актив көрәш алып баралар. Тегенди яки мондый сәбәпләр аркасында революциядән, халыктан аерылып китү куркынычын кичергән, ягъни урталыкта калган геройларга үрнәк булалар. Мәсәлән, «Канлы көннәрдә»ге Иосыф, Хәмзә, «Яңа кешеләр»дәге Шәйбәк, «Дошманнар»дагы Айсылуларның язмышында, революцион-сыйнфый көрәш шартлары белән бергә, Камил, Батырхан һәм Кәримнәрнең дә роле зур. Шул рәвешчә, демократик әдәбиятта куелган проблема — тормышның олы юлын эзләп газапланган һәм саташкан геройны күрсәтү бөтен принципиальлеге белән күтәрелә һәм хәл ителә башлый. Урталыктагы геройларның күпчелеге чын мәгънәсендә яңа кешеләр сафына кушыла. Димәк, революция әзер көенчә, үзеннән-үзе генә мәйданга килмәгән кебек, аны ясаучы геройлар да бер юлы гына тумыйлар һәм «сайланма» затлардан гына тормыйлар. Революция һәм сыйнфый көрәш эчендә яңа кешенең дөньяга карашы, характеры формалаша һәм ачыла дигән хакыйкать татар совет әдәбиятының башлангычында ук тамыр җибәрде. Бу хакыйкать исә безнең әдәбиятның үзенә лаеклы реализм юлыннан үсүе өчен кирәкле шартларның киләчәктә, перспективада тагын да нәтиҗәлерәк булачагы турында сөйли иде. 20 нче еллар дәвамында тупланган әдәби тәҗрибәбезнең күпчелек өлеше моны тулысынча раслады дисәк, һич артык булмас. Бөек тарихи процесска кушылып, тормышның киң юлына чыккан чын яңа геройны сурәтләү бурычы бу чордагы татар әдәбияты алдына да бөтен зурлыгы һәм җаваплылыгы белән килеп басты. Актив тарихи эшчәнлеккә күтәрелгән миллионлаган гади кешеләрнең образлары 20 нче еллардагы татар совет әдәбиятының бөтен жанрларында үзәк урынны алдылар, аның реалистик һәм романтик тенденцияләрен билгеләүдә хәлиткеч рольне уйный башладылар.

Олы буын язучылардан бигрәк тә Г. Ибраһимов иҗатында яңа герой проблемасы үзенең бик әһәмиятле яклары белән куелды. «Яңа кешеләр»дәге Батырхан һәм Камәрләр, «Кызыл чәчәкләр хикәясе»ндәге Солтан һәм Шаһбазлар, «Тирән тамырлар»дагы Фәхри һәм Садыйклар — алар һәммәсе халык арасыннан чыккан яңа кешеләрнең югары күтәреп, калку итеп бирелгән типлары. Алар — революцион көрәш эчендә янып яшәүдән башканы белмәгән романтиклар. Язучының аеруча мондый типларны сурәтләгәндә күбрәк күренә торган публицистик-риторик пафосын да, бәлки, шуның белән аңлатырга һәм акларга мөмкиндер. Әмма, барыннан да элек, шунысы әһәмиятле: Ибраһимовның яңа герое тарихның, тормышның драматик вакыйгалары,

иҗтимагый-сыйнфый каршылыклары эчендә формалаша, үзенең характерын ача. Бу инде язучының революциядән соңгы иҗатында үсеп киткән эстетик карашларында иң әһәмиятле реалистик сыйфат булып, аның гомумән иҗат методында, ә хосусан уңай геройны типиклаштыруында иң тотрыклы, нык концепциягә әверелде.

Үз заманындагы барлык татар язучыларына караганда да, Ибраһимов үзенең художниклык игътибарын яңа геройның гармоник образын күрсәтүгә юнәлтте. Моның белән шулай ук яңа чор прозасына лаеклы синтетик стиль мәсьәләсе дә бәйләнгән иде. Октябрьга кадәр үк инде Ибраһимов иҗатында гармоник кеше идеалы сизелде. Аның кайбер яралгыларын, мәсәлән, «Яшь йөрәкләр» романындагы Зыя образында төсмерләргә мөмкин. Ләкин бу яралгылар тормыштан түгел, ә язучының романтик хыялыннан азыклангалыктан, перспективалы булып чагыла алмадылар, ягъни уңай геройны изгән иске тормыш авырлыклары аның киләчәккә омтылу ихтыярын, оптимизмын басып, буып тордылар әле. Ибраһимов үзе үк, ул чорда язучының уңай идеалы һәм геройлары белән изүче тормыш арасында тирән каршылык яшәү котылгысыз фаҗигане китереп чыгара, дип аңлаткан иде. «Шагыйрь халкы, әгәр дә ул чын мәгънәсе илә шагыйрь булса, бу җирдәге вак, гади тормыш илә канәгатьләнә алмый,— дип язды ул үзенең «Татар шагыйрьләре» исемле хезмәтендә.— Аның хыялы әллә кач, ерак, югары һәм хыялый галәмгә алып китә, ләкин хакыйкатьтән китә алмый, һаман шулай үзе сөймәгән, нәфрәтләнгән вак, түбән тормыш эчендә яшәргә мәҗбүр була. Шуннан туа аның истирабы, бу тормыштан зарлануы, ачы әрләнүләре. Шуннан бик күп шагыйрьләрнең әшгары аһ-зар илә, тормышка ләгънәт илә тула. Чөнки тормыш аның теләгәнен бирми, юанычлар калдырмый». (21—22 битләр). Шуның шикелле үк, Ибраһимовның да күп кенә уңай геройлары идеал белән тормыш арасындагы каршылык газабын кичерделәр.

Искелек белән яңалык, прогресс белән реакция арасындагы көрәш идеясе безнең классик әдәбиятның тормышчан төп эстетик чыганагы һәм терәге булды. Ләкин шул көрәш эченә килеп кергән уңай, яңа геройның тормышка карашы һәм рухи дөньясы күпчелек очракта иҗтимагый һәм сыйнфый, тарихи һәм оптимистик бөтенлеккә ирешә алмады. Димәк, гармоник яңа герой идеал булып кына калды әле. Әмма шуның белән бергә, аны туктаусыз эзләү һәм аңларга теләү дә көннән-көн көчәйде. Г. Ибраһимов 1914 елда «Безнең көннәр»не язганда, аеруча Зариф Булатовны шундый геройларның берсе итеп күз алдында тоткандыр дип уйларга кирәк.

Тик социалистик революциядән соң гына Ибраһимов бүгенгесе белән киләчәге нык бәйле оптимистик һәм гармоник геройларны тапты. Болар — тормыштагы геройларның төгәл күчермәләре түгел, ә тормыш геройлары белән язучының идеалында туган геройларның синтезыннан, уртаклыгыннан гыйбарәт. Менә шул ноктада аларның романтик хыял аша узган һәм камилләштерелгән реалистик типиклыгын ачыграк күреп була да инде. Г. Ибраһимов үзенең яңа геройларын эре сызыклар белән калку итеп бирү принцибын яклады. Ләкин бу — гыйсъянчыларның һәм шулай ук пролеткультчыларның титаник герой концепциясеннән принципиаль рәвештә аерыла. Монда Горький белән якынлык һәм уртаклык күбрәк иде.

Образны синтетик гомумиләштерүне Горький, пролеткульт принципларына каршы буларак, шәхестән, конкрет кешедән һич тә аерып карамады. Аның карашында «идеаль герой» ниндидер масса эчендә югалырга, эрергә тиешле абстракт бер төшенчә түгел. Әдәбияттагы яңа герой чорның һәм революцион сыйныфның иң әһәмиятле сыйфатларын, уй-тойгыларын үзенең көчле рухи дөньясы аша гәүдәләндерергә тиешлеген таләп итте ул. Бу, һичшиксез, геройны калку, эре итеп күрсәтүне яклаган эстетик концепция иде. Һәм аңарда социалистик сәнгатькә хас реализм белән романтизм синтезының бер төп сыйфаты чагылды. Г. Ибраһимов та шул ук юнәлештә иҗат итте һәм татар әдәбиятының шундый рухта үсешенә зур йогынты ясады. Ләкин чорның яңа героен эзләү һәм сурәтләү бер юлдан гына китте дигән сүз түгел әле бу. Революция тудырган яңа геройлар дөньясы никадәр зур һәм бай булса, шуңа нисбәтән әдәбиятта да аңа төрле яклап, төрле ноктадан килергә омтылыш көчәя һәм катлаулана барды. Заман героеның идея-мораль йөзен ничек аңлау һәм сәнгатьтә ничек чагылдыру мәсьәләләре күп язучыларның игътибарын үзенә тарта килеп, безнең әдәбиятта да полемик сызыкларны, төрле тенденцияләрне тудырды. Бу, үз чиратында, язучыларның конкрет тормыш материаллары эченә, геройлар дөньясына тагын да тирәнрәк керә баруларын

таләп итә иде. Шулай ук заман героена бәйләнештә яңа эстетик идеалны аңлауның уңай һәм кире яклары, кыенлык һәм каршылыклары да үзләрен нык сиздерделәр.

Революция белән күтәрелгән яшь талантлардан аеруча Ш. Усманов иҗатында яңа геройны реалистик күрсәтү өчен көрәшнең шул чорга бик тә характерлы булган кайбер тенденцияләре чагылып калды. Аңарда, революция героикасы һәм романтикасы, барыннан да элек, чынбарлыкның чуар көндәлеге һәм массаларның соры стихиясе эчендә туа, дигән хакыйкатьне расларга омтылыш көчле булды. Әгәр дә Г. Ибраһимов тормыш каршылыклары аша үткән яңа геройның бөтенлегенә, гармоник шәхес булып формалашуына төп игътибарын юнәлтсә, Ш. Усманов исә мондый геройның зур иҗтимагый-сыйнфый көрәштә нинди идея-мораль кыенлыклар, каршылыклар белән очрашуын калку итеп күрсәтергә теләде. Мондый теләк үзенең төп эстетик максаты белән шулай ук яңа геройның гармоник образын эзләүгә бәйләнгән иде. Бу ноктадан карaганда, Ш. Усмановның прозасы өчен «Легион юлы» дилогиясе бик тә характерлы. 20 нче еллар дәвамында языла килеп, 30 нчы еллар башында тәмамланган бу әсәрнең фактик җирлегендә төрле милләт вәкилләрен бер бөтен революцион коллективка әйләндергән көрәш юлы — акларга каршы сугышларда үткән героик походы ята. Ул походтан чорның драматизмы, тарихи мәгънәсе, политик рухы һәм мораль-гуманистик эчтәлеге бәреп тора. Вакыйгалар агылышына һәм коллектив геройның гомуми настроениесенә игътибар беренче планда булганлыктан, аерым геройлар язмышының эзлеклелегенә, бөтенлегенә ирешү максат ителми. Тарихның киеренке, катлаулы шартларында революцион массаның корыч ихтыяры формалашу — менә шул «Легион юлы»ның үзәк эстетик сызыгы. Әледән-әле күренеп киткән геройлар шушы ихтыярның ничек гәүдәләнешен күз алдына китерүне конкретлаштыралар.

«Без бөтен авырлыкларга каршы барырга риза. Илдә революциянең яшәве картага куелган заманда, без бу далада кулларыбызны баглап утырасыбыз килми. Акларда көчле артиллерия булса, бездә штык бар. Караңгы төндә, туплар бернәрсә эшли алмаган вакытта, штык белән һөҗүм итәрбез. Далада салкын булса, йөгереп җылынырбыз. Яйсанның салкын өйләрендә туңып утыруга караганда, далада сугышып үлүне артык күрәбез», — ди ул, күп вакыт исеме дә билгеле булмаган герой. «Сөйләүче унтугызегерме яшьләрендәге егет иде. Ул күн тужурка кигән, ачык күкрәге, салкында кызган тимер күк, янып тора. Аның корыч чыңлавы шикелле ачык тавышы шыгрым тулган зал эчендә яңгырый, һәрбер сүзе тимер ук булып йөрәккә кадала иде». Менә шундый романтик герой, гади көрәшче образлары Ш. Усмановның да игътибар үзәгендә. Шуның белән бергә, аны да яңа геройның авыр көрәш шартларында үз эчке каршылыкларын җиңеп үсүе, рухи формалашуы кызыксындыра. Әмма язучы моны аңлауга һәм хәл итүгә икенчерәк ноктадан килә. Аның шушы юнәлештәге эзләнүләренә бер матур үрнәк итеп, бигрәк тә «Гает корбаны» (1924) исемле хикәясен күрсәтәсе килә. Хәйрүш солдат язмышында искелек белән яңалыкның бәрелеше бик тормышчан итеп күрсәтелгән. Революциягә чын күңелдән хезмәт итсә дә, Хәйрүш дини тойгы һәм ышанулардан, ягъни иске психологиядән азат түгел әле. Шуның аркасында ул аклар кулына эләгә. Бу фаҗига геройның рухында эзсез калмый. Ул үзенең ялгышуын, иске йолаларның корбаны булуын төшенә һәм революцион бурычның бар нәрсәдән югары икәнлеген аңлап үлә. Менә шундый антитеза аша яңа геройның эчке дөньясындагы каршылыклы бер хәлне һәм үзгәрешне күрсәтергә омтылыш Ш. Усманов иҗатында яхшы ук сизелеп калды. Яңа геройның эчке рәсемен, мораль йөзен билгеләүче төп сызык итеп, иҗтимагый бурыч, революцион идеал белән шәхси, интим теләкләрнең бәрелеше алынды. Моны гадәттә семья һәм мәхәббәт мәсьәләләренә бәйләп күрсәтүгә басым ясалды.

Яңа геройның иҗтимагый бурычы белән шәхси теләкләре арасындагы бәйләнеш, уртаклык, гармония мәсьәләсе революциянең башында ук инде безнең әдәбиятта күренгән иде. Моңа, мәсәлән, Ф. Бурнаш поэмаларында күп урын бирелде. Көрәш эченә ашкынучы егетне сөйгән кызының китмәскә үгетләве, ә егетнең ил һәм халык каршында патриотик бурычын изге санап фронтка китүе һәм кызның да, ниһаять, риза булып, икесенең дә көрәшкә һәм мәхәббәткә мәңге ышанычта калулары кебек коллизия гражданнар сугышы чоры поэмаларында күп кабатланды, традицион-романтик сюжетның характерлы бер күренеше булды. Монда әле революцион идеал белән мәхәббәт арасындагы каршылык вакытлы бер күренеш, тиздән хәл ителәчәк конфликт булудан узмый. Көрәш һәм мәхәббәт гармониясе яңа геройлар мөнәсәбәтендә тулы-

сынча өстенлек итәчәге алдан ук билгеле. Гомумән алганда исә, моны «сугышчының үсешен эчке яктан күзәтүгә, психологизмга омтылу»[1] дип бәяләргә мөмкин.

Шул ук чорда күренә башлаган икенче тенденция революцион-сыйнфый көрәш идеясенең шәхси теләк һәм мавыгулардан өстенлеген катгый рәвештә раслаудан, болар арасындагы уртаклыкны, гармонияне хәтта инкарь итүдән дә гыйбарәт иде. Ш. Усмановның беренче пьесаларында ук бу тенденция бар. Аеруча мәхәббәт-семья сызыгы буенча «Бай кызы» (1922) пьесасында ул кискен куелды. Кызыл комиссар Хәлил, мәхәббәт хисләренә бирелеп, бай кызына өйләнә һәм мещанлык колы булу куркынычы алдында кала. Ләкин ул үзенең хатасын аңлый һәм кабаттан көрәшкә китә. Шул рәвешчә, яңа кешенең революцион романтикасы мещанлык тынычлыгына каршы алынып, геройны авыр хәлгә куйган эчке конфликт социологик антитезаның билгеле схемасы белән хәл ителә. Ә ул схеманың асыл мәгънәсе — иске сыйныф вәкилләре белән яңа кешеләр — революционерлар арасында шәхси уртаклык була алмый, дигән караштан гыйбарәт иде.

«Бай кызы»ннан соң язылган кайбер хикәяләрендә Ш. Усманов бу концепцияне яңа геройның үз эчке дөньясындагы каршылыклар планында карарга теләде. «Ил кызы» һәм «Краском мәхәббәте» (1923) хикәяләрендә сурәтләнгән кызыл көрәшчеләр, үзләре яши торган шартларның авыр булуына карамастан, бәхетле мәхәббәт һәм семья турында да хыялланалар. Ләкин зур көрәш чынлыгы бу хыялларны җимерә, бу очракта да революцион идеал шәхси теләкләрдән өстен булып кала. Язучы фикеренчә, хәзерге вакытта шәхси бәхет турында уйлау яңа кеше, яңа герой идеалы белән сыеша алмый. Гомуми эш өчен мондый бәхет корбан ителергә тиеш. «Памирдан радио» (1925) повестендагы Җаббар — үзен әнә шундый идеалга багышлаган бер романтик герой.

Хәзерге чорда яңа герой каршында көрәштән башка бернәрсә дә юк, дигән карашны бу очракта «революцион аскетизм»нан аерып калдыру кыен. Чөнки яңа геройның гражданлык бурычын, революциягә хезмәт итүен аның шәхси бәхетенә һәм теләкләренә каршы куеп карау — нигездә суллык күренеше. Шулай да мондый аскетизмны аерым язучыларның бер уйдырмасы, яңа геройны үзләренчә ясарга омтылулары дип кенә аңлау да хата булыр иде. Аның белән бөтен бер революцион буын кешеләре сугарылганлыгын истә тотарга кирәк. Шулай ук тарихның, тормышның кинәт борылышы, текә агышлы чорларында иҗтимагый максатлар белән шәхси теләкләр аралыгы тагын да киңәю һәм тирәнәю мөмкинлеген дә онытырга ярамый. «Революцион аскетизм» әнә шул аралыкны күрә, әмма аны бетми торган бер күренеш итеп аңлый яки бетәргә мөмкинлегенә ышанып җитми.

20 нче елларның яңа героендагы менә шундый каршылыкка әдәбиятның игътибар итүен һич тә урынсыз һәм әһәмиятсез дип булмый. Чөнки ул яңа чынбарлык һәм яңа идеаллар белән бәйләнгән иде. «Революцион аскетизм» настроениеләрендә иске тормыш төбеннән күтәрелеп чыккан кешеләрнең бер өлешенә хас драматизм — бөек идеаллар белән тормышның вак, көндәлек, үтүчән ихтыяҗлары арасындагы мәңгелек каршылыкларны, гармониясезлекне юкка чыгару хыялы һәм газабы чагылды. Шуңа күрә «революцион аскетизм» яңа геройның мораль йөзен һәм иҗтимагый характерын билгеләүче унай бер күренеш иде дигән гомуми нәтиҗәне дә ясап булмый.

Яңа геройның иҗтимагый һәм мораль гармониясен табу, билгеләү һәм күрсәтү мәсьәләсен аңлауда, шул рәвешчә, татар әдәбиятында төрле тенденцияләр мәйданга чыкты. Югарыда искә алынганнан аермалырак булган, бик тә характерлы икенче бер тенденцияне, мәсәлән, Г. Ибраһимов иҗатында күрергә мөмкин. Аның да яңа геройлары революцион идеалны, бурычны югары куялар. Бу яктан алар совет әдәбиятының уртак эстетик концепциясеннән үсеп чыгалар. Әмма алар шул идеал белән бәйле шәхси теләкләрне дә инкарь итмиләр, киресенчә, шулар арасындагы гармониягә омтылалар һәм аны табалар. Октябрьгә кадәрге иҗатында язучы моны хәл итә алмады. «Безнең көннәр»нең беренче редакциясендә инде моны икенчерәк юнәлештә аңларга теләүнең беренче әһәмиятле билгеләре күренде. Давыт Урмановның «революцион аскетизмы» белән Җиһангирның интим-мәхәббәт романтикасы каршы куелып, боларның икесе дә зур һәм катлаулы тормыш чынлыгыннан, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдән читкә

[1] Х. Госман. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. 1960 ел, 158 бит.

алып китә торган мавыгулар итеп күрсәтелә. Романның соңгы редакциясендә язучы үз геройларының бу линиясен тагын да ачыклады [1]. Аның фикеренчә, уңай геройның гражданлык характеры шәхси-интим теләкләреннән аерым була алмый. Киресенчә, сыйнфый-революцион идеал яңа геройның шәхси, субъектив дөньясы формалашуга да хәлиткеч йогынты ясый. Аның иҗтимагый һәм шәхси теләкләре, беренче нәүбәттә, халык азатлыгы һәм бәхете өчен көрәштә тыгыз мөнәсәбәткә керәләр, шунда кешенең рухи тулылыгы, бөтенлеге булып җитлегәләр. Нәкъ шундый көрәштә Ибраһимов уңай геройларының күпчелеге үз шәхси тормышларының мәгънәсен һәм матурлыгын таба. «Яңа кешеләр»дәге Батырхан һәм «Кызыл чәчәкләр хикәясе»ндәге Солтан, «Тирән тамырлар»дагы Фәхри һәм Садыйк, «Безнең көннәр»дәге Булатов һәм Ника, революцион идеал белән бергә, үзләренең шәхси теләк һәм мөнәсәбәтләрендә дә матурлык, гыйффәтлелек, яшәү һәм көрәш илһамы күрәләр. Семья бәхетен һич тә кире кагарга теләмиләр. А. Шамов та «Рәүфә» (1926) дигән хикәясендә ярлы семьядан чыккан Рәүфә белән кулак семьясы арасында уртак рухи теләкләр булмау драмасын сурәтләп, «Днепр буенда» (1927) исемле повестенда исә үзләрен революцион идеалга багышлаган ике яшь кешенең — Хәлим белән Рахильнең мәхәббәт матурлыгын күрсәтте. Аңарда да «революцион аскетизм»га каршы тенденция ачык иде.

Яңа геройның иҗтимагый, революцион идеалы белән шәхси омтылышлары бәйләнеше кешенең яңа җәмгыятьтә үз урынын ничек аңлавы һәм табуы кебек зур мәсьәләдән аерылгысыз. Шуңа күрә ул әдәби геройлар дөньясы белән генә чикләнә алмый; геройларның идея-мораль каршылыклары булып кына калмый, ә аерым язучыларның үзләре өчен дә революцион идеал белән яңа этик-эстетик идеалларны аерылмаслык итеп аңлау юлы бик такыр һәм ачык булмаганлыгын күрсәтә иде. Моның характерлы бер чагылышын Һади Такташ иҗатында күрергә мөмкин. Яңа чынбарлык белән иске романтик традицияләр арасындагы тирән каршылыкны ерып чыгу өчен көрәшкә бик күп иҗади көчен салып, бу шагыйрь үзенең һәм әдәби героеның заман белән бәйләнеше һәм революция алдында идея-мораль җаваплылыгы мәсьәләсен бик тә кискен гәүдәләндереп үсте. Аның башлангыч иҗатында геройның азатлык һәм мәхәббәт идеалы традицион-трагик яктырылышында калды әле. Мәхәббәт — кеше рухи ирегенең югары бер идеалы мәгънәсендә алга куелып, иске тормышның законнары һәм әхлакый нормалары белән ул һич тә сыеша, килешә алмый, дип чыкты шагыйрь. Атаклы «Җир уллары трагедиясе»нең дә бер төп идея сызыгы шуннан гыйбарәт иде. Мәхәббәт — кеше матурлыгының әхлакый нигезе булу һәм аның иҗтимагый бурыч белән бәйләнеше турындагы фикер Такташның күп кенә әсәрләре аша үтте. «Күмелгән кораллар» (1927) драмасында аңа кадәр Ш. Усманов һ. б. тарафыннан күтәрелгән проблема алынды. Бай малае Солтан белән Советлар властен яклаган мөгаллимә Сәгыйдә арасындагы мәхәббәт — семья мөнәсәбәтләре сыйнфый идеалларның капма-каршылыгы белән һич тә сыеша алмыйлар. Үзенең баласына ата булырга тиешле Солтанны Сәгыйдә революция хакына нәфрәт белән кире кага һәм халыкка дошман дип саный.

Иҗтимагый бурыч белән шәхси теләкләрнең бәйләнеше мәсьәләсе безнең тормышның тыныч шартларында үзенең икенче яклары һәм көтелмәгән кыенлыклары белән килеп басты. Яңа геройның тормыш позициясен турыдан-туры революцион-сыйнфый көрәшкә бәйләп караганда, бу мәсьәләнең чишелешендәге беркатлылык та һәм турылык та күзгә бәрелеп торды. Чагыштырма дәрәҗәдә ул җиңелрәк тә кебек. Ә менә социализмны тыныч шартларда төзегәндә, яңа кешенең тормыш позициясен тагын да әчтәнрәк, аның рухи тирәнлегеннән эзләргә һәм табарга кирәк иде. Шундый максат белән Такташ «Югалган матурлык» (1928) драмасын язды. Бу әсәрдә яңа кешеләрнең иҗтимагый һәм шәхси теләкләре арасында хәл ителүе кыен булган һәм тирән драматик каршылык барлыгы турында сөйләнә. Совет инженеры Газизнең һәм аның сөйгән хатыны комсомолка, студентка Галиянең семья бәхете фаҗигале җимерелүен күрсәтеп, автор яңа герой язмышында иҗтимагый һәм шәхси теләкләр гармониясе ничек булырга тиеш? дигән сорауга җавапны ачык калдырды. «Мин кешелек дөньясы алдында беренче ана булырга тиеш идемме, әллә җәмагать эшчесеме?» — дигән сорау газаплый Галияне, һәм шуңа дөрес җавап таба алмау аркасында, ул үзенең яшьлек

[1] Бу хакта тулырак анализны М. Хәсәновның «Галимҗан Ибраһимов» (1964) дигән хезмәтеннән карарга мөмкин (289—291 битләр).

матурлыгына, сәламәтлегенә һәм ана булу бәхетенә хыянәт эшләп, һәлакәткә бара. «Революция гаилә мәсьәләсендә безнең алга бик күп проблемалар, бик күп каршылыклар китереп куйды», — дип, кешелекнең яңа буынын тәрбияләүдә совет семьясының бурычы искиткеч зур һәм җаваплы икәнлеген аңлаган Газиз дә: «Ир плюс хатын— трагедия... Әллә нәрсә... Бүгенге гаилә төзелергә өлгерми җимерелә бара...» кебек сүзләрдән югары күтәрелми. Һичшиксез, яңа геройның эчке тормышын, рухи мөнәсәбәтләрен төзү эше җиңел генә бармый, яңа шартларда аның кыенлыкларына күз йоммаска кирәк, дигән карашны яклый Такташ һәм үзенең бөтен иҗатына хас булган зур гуманистик идеяне үткәрергә тели. Монда шулай ук яңа геройның мораль-психологик табигатен билгеләүдә ул елларда кабул ителгән социологик схемадан читләшергә омтылыш та бар иде. Ләкин алынган теманы традицион-романтик һәм трагик планда караудан катгый рәвештә читләшә алмавы язучының үзен дә, геройлары шикелле үк, каршылыклы хәлгә куйгалады.

Заман героеның рухи матурлыгын һәм бөтенлеген эзләү, аны сәнгатьтә сынландыру проблемасы Такташ иҗатын 20 нче еллар азагына табан тулысынча биләп алды. Шагыйрь поэзиядәге яңа матурлыкның сере һәм художникның беренче мәртәбә шул матурлыкны ачудагы роле турында сөйли. Аны объектив һәм субъектив каршылыкларны кичереп үсүче заман героен сурәтләү кызыксындыра. Мондый герой барыннан да элек конкрет тормыш шартларында үзенең эш-кыйланышлары белән бирелгәндә генә ышандырырлык, реалистик булырга мөмкин. Менә шушы момент Такташ поэзиясендә ачылып киткән лирик эпосның да үзенчәлеген билгеләсә кирәк. Моның бер матур үрнәге — «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927) поэмасы. Мәхәббәт һәм семья иреген мещаннарча аңлауга каршы куелган бу әсәрдә яңа җәмгыять кешеләренең иҗтимагый идеалы белән морале арасында тыгыз бәйләнеш булуы раслана. Әмма бу бәйләнеш, гармониянең тууы тормыш каршылыкларыннан, геройларның рухи ялгышу һәм газапларыннан башка һич тә булырга мөмкин түгел. Зөбәйдә белән Мәхмүт арасындагы мәхәббәт тарихы да шундый җирлектә ачыла.

«Типларны берьяклы итмәскә, аларның эчке каршылыкларын ачарга...» «Нәфис дөреслек нигезендә кешенең бөтен эчке каршылыклары белән җанлы психологик типлар тудырырга», — менә шундый әһәмиятле таләпләрне Такташ гомумән безнең әдәбият һәм шул җөмләдән үз иҗаты каршына да куйды. Аның «Мәхәббәт тәүбәсе», «Мокамай», «Киләчәккә хатлар» һәм «Камил» кебек күренекле әсәрләре шул таләпләрне тормышка ашыруның гүзәл мисаллары булдылар. Боларда заман кешеләренең катлаулы эчке драматизмы һәм язмышы күз алдына китерелеп, Такташ иҗатының буеннан-буена килә торган проблема — шәхес белән коллектив, аерым кеше белән җәмгыять арасындагы гармоник мөнәсәбәт кебек гуманистик караш яктылыгында хәл ителә. Нәкъ шуңа бәйләнештә «Такташны барыннан да элек кешенең рухи хәле, психологиясе кызыксындыра башлады»[1]. Шагыйрьнең лирик герое да шул ук юнәлештә үсә килеп, ул үз замандашының көр күңелле дусы, якын юлдашы һәм туры сүзле киңәшчесе булып формалашты.

Дөнья матур,
Шушы дөньяның мин —
Ирке чикләнмәгән юлчысы;
Давыллы елларның, зур көрәшнең
Матурлыгын җырлар җырчысы... —

(*«Бүгенге матурлык», 1927*)

дип игълан итте ул герой үзенең эстетик кредосын. Заман сулышын һәм аның чын геройларына лаеклы уй-хисләрне сәнгать дөньясына киң колачлап алу — менә шундый зур максат шагыйрьнең бөтен игътибарын үзенә тартты. Элеккерәк чорга хас булган һәм билгеле шигъри чаралар белән генә мондый максатка ирешеп булмаячак, эпостан аерылгысыз лирикага, психологизмга йөз белән борылырга кирәк иде. Шуңа күрә эпик геройны гына түгел, лирик геройны да тарих фонында һәм көндәлек тормыш

[1] Х. Госман. Егерменче елларда татар поэзиясе, 1964 ел, 335 бит.

эчендә гәүдәләндерүгә ирешүне Такташ яңа сәнгать өчен бик әһәмиятле бурыч итеп аңлады. Шулай итеп, 20 нче еллар дәвамында татар әдәбиятында туплана килгән реалистик тәҗрибәләр яңа геройның тормышчанлыгын һәм рухи портретын билгеләүгә дөрес юнәлеш бирделәр. Такташ бу юнәлешкә поэзиядә киң юл ачучылардан берсе булды. Аның шигъри тавышы һәм геройлары бүгенге шау-шулы зур тормыш эченнән киләчәккә юнәлделәр.

Без бу мәкаләдә социалистик революциянең беренче ун елындагы татар совет әдәбиятында яңа герой образы ничек туды? дигән сорауга җавап бирүне максат иткән идек. Бу максат, билгеле, үткәнгә гади бер экскурс, әйләнеп карау булып кына кала алмый. Ул чор әдәбиятында урын алган яңа герой, бүгенге эстетик таләпләр югарылыгыннан караганда, күп ягы белән әле җитлекмәгәндер дә. Әмма, ничек кенә булмасын, ул герой — тарихның зур сынауларында туып һәм чыныгып, үзеннән соң безнең әдәбиятка килгән күп геройларга үрнәк һәм юлдаш булды. Аның революцион идеалы бөек һәм рухи-мораль дөньясы нык, таза булганлыктан, ул заман авырлыкларын һәм басымнарын курыкмыйча күтәрде. Шуңа күрә 20 нче еллар әдәбиятының яңа герое бервакытта да үлмәс.

Без яңа җир, яңа кеше өчен
Җирдә зур дау алып барабыз!.. —

дигән иде Такташ. Татар совет әдәбиятының беренче яңа герое да — яңа җир һәм яңа кеше өчен көрәш давылларында чыныккан солдат, гражданин һәм гуманист. Мондый каһарманны тарих һәм кешелек онытмый.

## *Латыш халык мәзәкләре*

### БАЛА КАЯН БЕЛСЕН?..

Бер яшь хатын бала таба. Үзенең тәҗрибәсе юк, кешедән сорашырга теләми, ә баланы карарга кирәк.

Шулай бер көнне ул баласын коендырырга әзерләнгәндә күрше әби аның суына бармагын тыгып карый, һәм бармак бик каты пешә.

— Әллә акылдан яздыңмы син? Кайнап торган суда бала коендыралармы?

— Куй әле, әбекәй, суның кайнармы-салкынмы икәнен нәп-нәни бала кайдан белсен ди?

### СИКЕРЕП ТОРДЫ

Анасы кызын уята:

— Тор, бәбкәм, әнә әтәчләр кычкыра!

— Кычкырсын! Әтәчнең башы бәләкәй аның, шуңа күрә йокысы тиз туйгандыр.

— Тор, кызым, тор, әнә көн яктырып килә.

— Яктырсын, аның бит кичкә хәтле эше күп.

— Тор димен, балакай, әнә инде кояш чыкты.

— Чыксын, аңа ерак аралар узарга кирәк.

— Тор, юньлем, аш пеште.

— Әни әйткәнне тыңламый булмый, торырга кирәк шул. Минем зур кашык кайда икән?

### АТ КАЙДА?

— Бар әле, атка азык салып кер! — ди атасы улына.

Малай чыгып китә дә бик озак торып керә.

— Печән салдыңмы атка?

— Салдым.

— Су эчердеңме?

— Эчердем.

— Бар, алайса, хәзер җигә башла атны.

— Ә кайда соң ул ат, әти?

Р. Сверигин

# ФАТИХ ХӨСНИ

Әгәр дә без аның таныш булмаган әсәреннән берәр өзек алып укысак, китапның титул битен күрмичә үк, бу китапны Фатих Хөсни язган, дип әйтер идек. Ф. Хөснинең стиле шулкадәр үзенчәлекле, аны башка бер генә язучы белән дә бутарга мөмкин түгел. Бу үзенчәлек Ф. Хөсни бик яратып куллана торган тел әйләнмәләрендә, чагыштыруларда, детальләрдә һәм башка сәнгать бизәкләрендә генә дә түгел, бәлки язучының үзенә генә хас фикерләвендә дә, тормышны үзенчә сурәтләвендә дә һәм кешеләргә мөнәсәбәтендә дә ачык күренеп тора.

Гади кешеләрнең рухи дөньясына зур игътибар, аларның хисләрен, кичерешләрен, шатлык һәм кайгыларын оста тасвирлау, лиризм һәм ташып торган юмор — Ф. Хөсни иҗатындагы күзгә ташланып торган кайбер сыйфатлар әнә шулар. Билгеле, бер мәкаләдә язучы иҗатының һәр ягын җентекләп тикшерү мөмкин булмас иде. Без бирегә язучының иҗади юлына гомуми күзәтү ясауны һәм аның характер, образ төзүдәге эзләнүләрен күздән кичерүне генә максат итеп куйдык.

Ф. Хөсни, үз әсәрләренең геройлары итеп, тормышта еш очрый торган, гади, тыйнак, саф күңелле кешеләрне ала һәм аларны реаль шартларда, җанлы һәм тормышчан итеп сурәтли. Язучының зур иҗат юлы тигез һәм шома гына булмады, әлбәттә. Бу юлда аның вакытлы ялгышлары зур иҗат уңышлары белән аралашып килде. Ләкин бер нәрсә бәхәссез: Ф. Хөсни һәрвакыт үз юлы белән барырга, художник буларак үз сүзен әйтергә теләде.

Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов, Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази кебек үк, Фатих Хөсни дә татар совет прозасы үсешенә зур өлеш керткән язучы. Аның «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» романнары, «Йөзек кашы», «Авыл өстендә йолдызлар», «Җәй башы», «Минем тәрәзәләрем» повестьлары һәм күп сандагы хикәяләре укучыларга чын рухи азык булып хезмәт итә һәм аларның эстетик зәвыкларын тәрбияли.

Ф. Хөсни иҗаты күп кырлы. Ул тамашачыларга сәхнә әсәрләре авторы буларак та билгеле. 1929 елда ук «Усаллар» исемле драма язган иде. Соңрак аның «Урманда», «Әбли авылы», «Кияүләр», «Еллар һәм юллар» пьесалары буенча эшләнгән спектакльләр республика театрлары сәхнәләрендә барды. Ф. Хөсни бу жанрда бүгенге көндә дә уңышлы гына эшләп килә. Әле күптән түгел генә «Бертуган Таһировлар» исемле пьеса тәмамлады. Әдәбият сөючеләр Ф. Хөснине әһәмиятле һәм кызыклы мәсьәләләрне күтәргән публицистик, әдәби тәнкыйть мәкаләләре буенча да яхшы беләләр. Аның үзәк матбугатта чыккан мәкаләләре әдәби җәмәгатьчелек өчен һәрвакыт зур вакыйга була. Гадәттә аның мәкаләләре кызыклы бәхәсләр, дискуссияләр уята.

Язучы һәрвакыт тормыш белән тыгыз бәйләнештә булырга омтыла. Зур шәһәрләрнең культура сарайларындамы, колхоз клубларында яки авыл мәктәпләрендәме — ачык чырайлы, оптимист табигатьле, уен-көлкегә оста бу кешене халык һәркайда үз итеп каршылый. Үз чиратында, халык һәм аның тормышы Ф. Хөсни өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чишмәсе булып тора.

Ф. Хөсни әдәбиятка шигырьләр белән килеп керде. 1926—30 елларда «Авыл яшьләре», «Безнең юл», «Атака», «Яңалиф» журналларында аның утыздан артык шигыре басылып чыга. Ләкин яшь шагыйрь поэзия өлкәсендә яңа сүз әйтә алмады. Гади генә фикерне дә катлауландырып әйтү, кабартылган, канатлы сүзләр эзләү, башка шагыйрьләргә турыдан-туры охшарга тырышу — Ф. Хөсни шигырьләренә менә шулар хас иде.

Ф. Хөсни үзенең каләмен әле бер, әле икенче өлкәдә сынап карый. Ул очерклар, поэмалар, нәсерләр һәм пьесалар яза, ләкин бу жанрларның берсендә дә тукталмый.

Язучы бөек илнең үсешен тулырак күрсәтү өчен яңа чаралар эзли. Аны бигрәк тә авылдагы зур борылыш, крестьян психологиясен үзгәртү өчен барган көрәш кызыксындыра.

1931 елда Ф. Хөсни укучыларга «Җир тыңлый» романының беренче кисәген тәкъдим итә. Бу әсәр илдәге зур үзгәрешләрне матур әдәбиятта чагылдыру теләге белән, тарихи вакыйгалар турында аларның кайнар эзеннән язарга тырышу нәтиҗәсендә туган иде.

Роман — проза жанрының бик катлаулы төрләреннән берсе. Ә егерме өч яшьлек язучының тормыш һәм әдәби тәҗрибәсе зур түгел иде әле. Нәтиҗәдә идеясе һәм художество эшләнеше ягыннан шактый зәгыйфь әсәр барлыкка килде. Колхозлашу хәрәкәте, авылдагы яңа мөнәсәбәтләр, яңа кешеләр тасвирланырга тиешле булган бу романда язучы үз алдына куйган бурычны үти алмады. «Җир тыңлый» романы үз вакытында матбугатта бик кискен рәвештә тәнкыйть ителде. Билгеле, ул әсәрдә язучының кайбер кызыклы гына күзәтүләре һәм, әле борынлап кына килә торган булса да, сәнгатьчә бизәкләре дә бар иде. Ләкин алар тәнкыйтьнең гомуми фонында югалып калдылар.

Яшь язучының беренче китабы уңышсызлыкка очравы аны бик нык уйланырга мәҗбүр итте. Әле аңа бик күп укырга, тормышны зур түземлелек белән өйрәнергә кирәк иде.

Утызынчы еллар Ф. Хөсни өчен гаять бай тормыш һәм иҗат мәктәбе булды. Кызыл Армия сафларында хезмәт итү, комсомол бригадалары составында авыл районнарына барып, халыкка культура хезмәте күрсәтү, зур төзелешләрдә, завод-фабрикаларда булу, газета-журнал редакцияләрендә эшләү Ф. Хөснигә шифалы йогынты ясады, аның тормыш тәҗрибәсен арттырды.

1934 елда аның беренче хикәяләр җыентыгы, соңыннан «Ана хикәясе» (1936), «Минем күгәрченнәрем» (1938) исемле җыентыклары басылып чыкты.

Үзенең беренче хикәяләрендә автор интеллигенция турында язды. Ул үзе дә бу елларда Казан финанс-экономика институтында укый һәм шунлыктан интеллигенция вәкилләре белән якыннан таныш иде. «Профессор трагедиясе» хикәясендә ул революциягә кадәрге Россия шартларында тәрбияләнгән профессор Григорьевка совет чынбарлыгында үскән кеше өчен иң гади булган әйберләрнең ят, авыр, чишелә алмаслык булып күренүен сурәтләде. Бу хикәядә карт галимнең трагедиясе, аның психологиясендәге каршылыклар шактый табигый күрсәтелгән.

Ф. Хөснинең беренче әсәрләре өчен абстракт күренешләр, символлар белән эш итү, тормышның караңгы яклары турында язарга тырышу хас иде. Болар берсе дә Ф. Хөснине әдәбиятның олы юлына алып чыкмадылар әле. Бу — шул еллардан алдарак әдәбиятта чагылган бунтарьлык идеяләренең, гыйсъянчылыкның соңгарак калган шаукымы гына иде.

Ләкин язучы символика һәм абстракциядән арына барды, конкрет тормыш мотивларына торган саен җитдирәк игътибар итә башлады. Тормыш күренешләрен конкретрак, кешеләрне якын итеп, йөрәк җылысы белән сурәтләп, лиризм белән сугарып язылган «Чишмә» (1939), «Чия төше» (1938) хикәяләре әнә шуның ачык мисалы иде.

Утызынчы елларда совет кешеләренең тормышында һәм психологиясендә булган зур үзгәрешләр Ф. Хөсни иҗатында да чагылыш тапты. Аның ул елларда язган әсәрләренең күпчелеге тормыш алып килгән яңалыкларны тасвирлауга багышланган.

«Чакыру билеты» (1937) хикәясендә клубта үзешчән сәнгать көчләре концертын карап утыручы Гыйззәт карт, гармоньда уйнаучы малайны күреп: «Бакчы, Кәкре Елга авылының Хәйрулла малае ич бу. Кара син аны, арба чәкүшкәсе чаклы малай, өздерә дә сала. Хәйрулла малае дип кем әйтер. Хәйрулла үзе йөзгә чаклы саный да белми торган иде бит ул», — ди. Революциядән соң халыкка культура килүне язучы Гыйззәт картның берничә сүзе аша әнә шулай матур итеп әйтеп биргән.

Бүгенге көн геройларын эзләү, күркәм сыйфатларга ия булган хезмәт кешеләре образларын иҗат итәргә омтылу Ф. Хөснинең утызынчы елларда язылган әсәрләрендә үк сизелә иде. Әмма аларда герой характерын ачып бирү сыйфатларының аерым билгеләре генә бар иде әле.

Язучы үзенең уңай герой идеалын бу елларда шактый берьяклы аңлады. Аның геройлары җәмгыятьтән, әйләнә-тирәдәге шартлардан канәгать булмаган шәхес була-

рак күз алдына килеп баса иде. «Идел тынычсызлана» (1932) хикәясендәге балыкчы картның улы әнә шундый. Балыкчы карт, элекке тормыш гадәтләреннән аерыла алмыйча, башка кешеләр артельгә берләшкәндә качып Идел буенда ялгыз яши башлый һәм көннән-көн кешелек сыйфатын югалта бара. Шушы юлга ул үзенең улын да өстери. Ләкин егет әтисенең ялгыш юлы белән бармаячагы турында ачыктан-ачык әйтә һәм балыкчылар артеленә китә.

Шундый ук бунтарь табигатьле кешене — йөрәге яшь булган карт скрипкачыны «Җырчы кыз» (1937) хикәясендә дә очратабыз. Бу беренче хикәяләрнең геройларында әле романтик шартлылык ачык күренеп тора.

«Гармоньчы» (1940) повестенда да образның күңел байлыгын һәм гадел булмаган тормыш тәртипләреннән канәгатьсезлеген басым ясап күрсәтергә тырышу сизелә. Мәшһүр артист Фәйзулла Туишев тормышына багышлап язылган бу әсәрендә Ф. Хөсни соңыннан үз иҗатында төп урын алган уңай геройга якын килергә тели. Авторның маҗаралар белән тулы, гадәттән тыш вакыйгаларга бай булган тормышны тасвирларга уйлавы очраклы түгел иде. Бу уңай әдәби тип язучы күз алдында кыюлык, талант, җиңел ирешелгән уңышлар ярдәмендә тормыш кыенлыкларын җиңеп баручы булып гәүдәләнә. Уңай геройны бу рәвешчә күзаллау ялгыш иде. Нәтиҗәдә, кыенлыкларны зур ихтыяр көче һәм тырышлык белән җиңеп чыгучы батыр йөрәкле халык улы урынына, тормыш дулкыннары өстендә генә йөзеп, язмыш ирке кая таба куса, шунда китүче, талантлы, әмма үзенең урынын таба алмаган кеше образы барлыкка килде. Гармоньчы халык интересларыннан читтә, бирегә художник күңелен халык тормышының гаять зур лирик байлыгы белән бәйли торган җепләр юк, ул үзенең тар максатлары, кечкенә шәхси идеаллары белән генә яши.

«Гармоньчы» повесте Ф. Хөсни иҗатындагы төп юнәлештән читтә тормый. Ул хезмәт иясе вәкиле образын иҗат итәргә тырышуның бер мисалы булды. «Йөзек кашы» (1942) повестендагы Айдар образы конкретрак һәм тормышчанрак итеп бирелде. Монда инде герой искиткеч сыйфатларга ия булган кеше түгел, ул — бик күпләрнең берсе. Автор аны реаль тормыш күренешләре, табигый буяулар һәм картиналарда сурәтли алды.

Бөек Ватан сугышы елларында Ф. Хөсни халыкта фашизмга каршы үч, нәфрәт тойгылары уятуга багышланган әсәрләр иҗат итте. Ул, газета хәбәрчесе буларак, фронтларда булды. Тыныч тормышта гади, тышкы яктан башкалардан бер нәрсә белән дә аерылып тормаган кешеләрнең сугышта искиткеч батырлыклар күрсәтүен тасвирлаган «Сержант» (1943) хикәясен язды.

Ф. Хөсни хикәяләрендә совет кешеләренең тылдагы батырлыкларын сурәтләгән эпизодларны да күп очратырга була. «Хуторда» (1944) хикәясендә юл кыенлыкларыннан, салкыннардан курыкмыйча, фронтка икмәк ташып, ил каршындагы изге бурычларын үтәп йөрүче совет хатын-кызлары образлары бирелә.

Сугыштан соңгы елларда да Ф. Хөсни хикәя жанрына турылыклы булып калды. Аның хикәяләрендә совет кешеләренең тормышы, аларның киң ихтыяҗлары чагыла. Бу әсәрләрдә алгы планда халык, җәмәгать эшен үз эше итеп санаучы кешеләр — хезмәткә намус белән караучы, күпләргә үрнәк булырлык колхозчылар образлары тора.

«Тынгысыз кеше» (1949) хикәясендә сурәтләнгән Габдрахман картның урманга очып киткән корт күчен тотып, аны колхозга тапшыруы, җимеш бакчалары үстерүе, колхоз эшенә ваемсыз караучыларны тәнкыйтьләве аеруча җылы тасвирланган.

Язучы геройларның хезмәткә булган мөнәсәбәтләренә зур игътибар итә. «Ак перчатка» (1958) хикәясендә шәһәрдән авылга кайткан яшь кыз Сәҗидәнең чын матурлыгы аның «ак» эштән дә, «кара» эштән дә курыкмыйча эшләвендә чагыла.

Ф. Хөсни геройларының рухи дөньяларын аларның хезмәткә һәм мәхәббәткә мөнәсәбәтләре аша ача. Бу хәл аның новеллалары өчен бик характерлы. Кагыйдә буларак, мондый хикәяләрдә вакыйгалар ике сюжет сызыгы буенча үсә. Аларның беренчесе аша геройның хезмәтне сөюе чагылса, икенчесе кешеләрнең шәхси тормышта да бәхетле булулары турында сөйли. Ягъни, язучы эш һәм мәхәббәтнең герой тормышындагы гармониясен күрсәтергә тели. Аның хикәяләрендәге ике сюжет сызыгы бер-береннән аерылып тормый.

«Тургай», «Алтын көз», «Ферма кызы Халисә» кебек хикәяләрнең геройлары — яшьләр. Алар зур тормышта яшиләр, халык файдасына тырышып хезмәт итәләр, сөя

һәм сөелә беләләр. Геройларның яшьлек хисләре, самими матур кичерешләре хезмәт романтикасы белән бик табигый аралаша. Бу хикәяләрдә яшәү, хезмәт шатлыгы, яшьләрнең дөньяны яратуы, мәхәббәт хисләре бик ачык сизелеп тора.

Ф. Хөсни — балалар әдәбиятын үстерүгә дә билгеле бер өлеш керткән язучы. Ул балаларның кызыклы дөньяларын оста тасвирлый, аларның үзләре булып уйлый белә. «Җәйге кич», «Урман сукмаклары», «Без ни өчен беренче җиһаддан биздек», «Чыбыркы» хикәяләре әнә шундыйлар.

Ф. Хөснинең художник буларак осталыгы «Җәяүле кеше сукмагы» романында бик ачык күренде. Шунлыктан бу романдагы төп образның бирелешенә киңрәк тукталыйк.

«Җәяүле кеше сукмагы»нда Октябрь революциясенә кадәр һәм революция чорында татар авылларында барган катлаулы социаль процесслар, изүчеләр дөньясын астынөскә әйләндерүче яңа кешеләрнең үсүе сурәтләнә. Бу романны шул чордагы тормыш күренешләрен, социаль конфликтларны әдәбиятта тирәнрәк һәм киңрәк итеп күрсәтергә тырышуның бер үрнәге дип карарга кирәк. Вакыйгаларны киң социаль фонда һәм кешеләрнең интим дөньяларын социаль мөнәсәбәтләр белән тыгыз бәйләнештә бирү Ф. Хөсни иҗатында беренче шушы романда күренде.

Автор революциягә кадәрге татар крестьянының газаплы тормышы, аңарда гаделсез иҗтимагый тәртипләргә каршы протестның көчәюе, кешенең үз горурлыгын таптатмаска омтылуы, тормышның дәһшәтле сынауларын намус белән үтүе турында яза. Гади крестьян егетенең кыен һәм борылмалы юллар аша бәхеткә килүен реалистик картиналарда тасвирлый.

Әсәрдәге төп герой — Сәфәргали Ф. Хөсни иҗатындагы иң тулы һәм һәрьяклап эшләнгән образ. Моңа кадәр язылган әсәрләренең берсендә дә язучы революциягә кадәрге хезмәт иясе образын — крестьянны сурәтләгән вакытта болай зур ышандыру көченә, образның тулы эшләнгән булуына һәм тормышчанлыгына ирешмәгән иде әле. Билгеле, Сәфәргали образының аерым сызыклары язучы әсәрләрендәге башка уңай («Гармоньчы» повестендагы Фәйзулла, «Йөзек кашы»ндагы Айдар образларында) геройларда да бар иде. Ләкин ул геройларның тормыш максатлары таррак, бәхет турындагы карашлары да шәхси бәхет белән генә чикләнгән иде. Әйтик, «Гармоньчы»дагы Фәйзулла турында сөйләгәндә автор, барыннан да бигрәк, аның талантына игътибар итә. Герой тормышның катлаулы вакыйгалары эчендә кайный, ләкин үзенә кирәкле юлны таба алмый, ул бөтен барлыгын музыка дөньясына биргән, үз әйләнә-тирәсендәге социаль хәрәкәт аны бик аз кызыксындыра. Шәхеснең илһам көче, талантының халык һәм аның иҗаты белән тыгыз бәйләнештә генә чәчәк ату мөмкинлеге әсәрдә тиешенчә күрсәтелми.

«Җәяүле кеше сукмагы»ндагы Сәфәргали исә тулырак һәм реальрәк булуы белән аерылып тора. Сәфәргалинең тормыш эволюциясе социаль шартлар белән мотивлаштырып бирелә. Образның гомумиләштерү көче зур. Сәфәргали үткән юл — бер крестьян егетенең юлы гына түгел, ә миллионлаган крестьяннарның дәреслеккә бару юлы.

Ф. Хөсни, башка әсәрләрендәге кебек үк, биредә дә үзәк фигура итеп хезмәт иясе вәкилен, крестьян улын ала. Аңарда халкыбызның бик күп күркәм сыйфатлары бар. Ул тормышны сөя, матуррак яшәргә тели, аның тормышка карата таләпләре зур. Шушы геройның тормышта чыныгуы, характерының формалашуы романда тулы күрсәтелгән. Укучы күз алдыннан геройның балачагы, яшьлеге, мәхәббәте һәм революциягә кадәрге татар авылындагы җанлы тормыш картиналары, эксплуататорларның халыкны җәберләүләре, империалистик сугышның рәхимсез күренешләре һәм революциянең саф җилләре үтә. Шулай итеп, герой характерының формалашуы иҗтимагый фонда бара.

Әсәрнең беренче битләрендә Сәфәргалинең малай чагы күрсәтелә. Баланың кечкенә эчке дөньясы, психологиясе зур осталык белән ачылган. Сәфәр белән беренче очрашуда ук без аның нечкә табигатьле, саф күңелле бер малай икәнлеген беләбез. Менә шушы әле ныгып җитмәгән характер тормыш дулкыннары уртасына ыргытыла һәм төрле көчләрнең йогынтысы астында кала. Бу яшь үсенте тормыш давыллары астында бөгелеп, сынып калырмы, әллә көрәштә чыныгып, үсеп китәрме — укучыны әнә шул кызыксындыра.

Төрле очрашулар малайның дөньяга карашын киңәйтә баралар. Ул крестьян өйләрендәге хәерчелекне, ярлы крестьян хатынының актык икмәген тартып алырга то-

ручыларны күрә. Әтисе Корбангалинең ярлыларга карата теләктәшлеге һәр яхшылыкны кабул итәргә торучы бала күңеленә уңай йогынты ясый. Кешеләргә карата рәхимлелек, ярлылар турында кайгырту Сәфәргалинең малай чактан ук аерылмас сыйфатлары булып әверелә.

Сәфәргали күңеленең киңлеген күрсәткән, аның тормышына якты нур сипкән әйбер — егетнең Зәйтүнәгә мәхәббәте. Ф. Хөсни бу мәхәббәтнең бөреләнеп чәчәк атуын, геройларның күңел дөньясының иң нечкә тирбәлешләренә кадәр чагылдырып тасвирлый. Чын мәхәббәт хисе геройның күңелен сафландырып тора һәм ул үзенең бөтен бәхетен, киләчәген Зәйтүнәгә мәхәббәтендә күрә. Ләкин гаделсез строй, көчленең чикләнмәгән власте аның мәхәббәтен дә тартып ала. Һәм Сәфәргали тыелгысыз ачу белән Сәлмән бай тегермәнен яндыра, хуҗасын һәм авылны ташлап китә. Шулай итеп, социаль стройга каршы бунт ясала. Ләкин бу аңлы рәвештә эшләнгән эш түгел, Сәфәргали моны сукыр ярсу белән, ачудан эшли.

Язучы Сәфәргалинең аңсыз ярсуының ничек итеп аңлы протест белән алмашынуын күрсәтергә тели. Егетнең аңы үсүдә иң әһәмиятле рольне большевик Мәрәк Фәсхи уйный. Аның сүзләренең дөреслеге һәм фронттагы сугыш дәһшәтләре, мәгънәсез үлемнәр Сәфәргалине җитди рәвештә уйланырга мәҗбүр итә. Егет революция ягына чыга. Кызганычка каршы, автор герой характерындагы кискен борылыш моменты турында ашыгычрак сөйләп уза. Романның бу кимчелеген тәнкыйтьче Р. Мостафин дөрес билгеләде. Ул бу кимчелекне әсәр ахырында язучының геройны сюжет схемасына буйсындыруы белән аңлатты.

Гомумән алганда, Сәфәргали образын язучының зур иҗат казанышы дип санарга кирәк. Нәкъ менә шушы образның эшләнеше «Җәяүле кеше сукмагы» романының идея-эстетик һәм эмоциональ көчен билгеләүче төп сәбәпләрнең берсе булды.

«Җәй башы» (1950) һәм «Авыл өстендә йолдызлар» (1952—53) повестьларында Ф. Хөсни бүгенге колхоз авылы тормышын сурәтләде. «Авыл өстендә йолдызлар»да «гади хезмәт кешесенең каршылыкларны җиңә бару процессында формалашуы үзәк проблема итеп алына һәм ул хезмәт, семья, мәхәббәт мәсьәләләре җирлегендә психологик планда чишелә»[1]. Илленче еллар башындагы татар әдәбияты өчен бу яңа күренеш иде. Моңа кадәрге күп кенә әсәрләрдә герой фәкать эш, производство шартларында гына күрсәтелде, аның шәхси тормышы бер читтә кала бирде. Хәлбуки, образны бер яктан гына характерлап, аның тулылыгына ирешеп булмый. «Җәй башы» повесте бу кимчелектән арынып бетмәгән булса, «Авыл өстендә йолдызлар» повестенда исә Ф. Хөсни Айдар, Тәзкирә, Халидә һәм Гафиятулла образларының психологик бөтенлегенә ирешә. Тәзкирә, Айдар, Халидә мөнәсәбәтләре аша капма-каршы фикердә торучы кешеләр конфликты бирелә. Айдар һәм Тәзкирә — эчкерсез, саф күңелле, хезмәткә, иптәшләренә зур хөрмәт белән карый торган кешеләр. Аларның бәхете дә җәмгыятькә тырышып хезмәт итү белән тыгыз бәйләнгән.

Революциягә кадәр яшәгән татар хатын-кызының кызганыч язмышы, караңгы тормышы, кимсетелүе классик әдәбиятыбызда киң чагылган иде. Яшьлекләре, мәхәббәтләре, хыяллары патриархаль гадәтләр тарафыннан җәберләнгән, кимсетелгән хатын-кызлар образлары Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, М. Гафури, Г. Ибраһимов кебек язучылар әсәрләрендә зур осталык белән тасвир ителде.

Ф. Хөсни геройларының язмышы бу классик язучылар тарафыннан иҗат ителгән геройларныкыннан бик нык аерылып тора. Беренче карашка, «Җәяүле кеше сукмагы»ндагы Зәйтүнә генә шул татар кызларының кызганыч язмышларын уртаклаша сыман. Ләкин совет тормышында ул да үзендә яңадан аякка басарлык көч таба, иске тормыш богауларын өзеп ташлый һәм җәмгыятьнең файдалы, актив членына әверелә. «Йөзек кашы»ндагы Вәсилә дә тормышта үзенә урын таба. Дөрес, бу мәсьәләләр әлеге әсәрләрнең төп сюжет сызыклары рәвешендә бирелмиләр әле — ул кызларның ничек итеп берсенең яхшы укытучы, икенчесенең оста хирург булып җитешүләре тасвирланмый. Ә инде «Җәй башы» повестендагы Мөнирә, «Авыл өстендә йолдызлар»дагы Тәзкирә, «Утызынчы ел»дагы Нәҗия, Гайния кебек образларда аларның хезмәткә мөнәсәбәте, иҗтимагый карашлары һәм шәхси дөньялары бер-берсе белән бәйләнештә

[1] Нур Гыйззәтуллин. Характер һәм конфликтлар. «Совет Татарстаны», 1955 ел, 11 май саны.

бирелә. Болар — совет хатын-кызының гүзәл сыйфатларын шактый тулы чагылдырган образлар.

Герой тормышының бөтен мәгънәсе мәхәббәткә генә кайтып калса, бу, әлбәттә, берьяклылык булыр иде. Гадәттә, мондый очракларда образ төссезләнә. Бу күренеш Ф. Хөсни әсәрләренең күпчелеге өчен хас түгел. Аның повесть һәм романнарының күбесендә мәхәббәт төп сурәтләү объекты итеп түгел, ә кешенең бай рухи дөньясының бер ягы итеп алына.

Ф. Хөсни — үз иҗатына зур таләпчәнлек белән карый торган язучы. Әсәрне тәмамлау белән генә тынычланмый ул, аңа кат-кат әйләнеп кайта, төзәтә, яхшырта. Мәсәлән, ул «Йөзек кашы», «Авыл өстендә йолдызлар» әсәрләренең яңа вариантларын эшләде һәм алар беренчеләреннән шактый ук аерылып торалар. Язучы, үз теле белән әйткәндә, «иҗат кырында сөрелә башлап та, сөрелеп бетмичә ташланып калдырылган һәм файдасыз әрем үсеп утыра торган кишәрлекләр булуын» теләми. 1958—62 елларда Ф. Хөсни «Утызынчы ел» исемле романын иҗат итте. Бу әсәрдә «Җир тыңлый» романының кайбер сюжет сызыклары, персонажлары һәм аерым ситуацияләре сакланган. Шулай да «Утызынчы ел» үзенең беренче варианты белән чагыштырганда танымаслык булып үзгәргән. Бу үзгәрешләр әсәрнең композицион төзелешенә дә, образларның идея функцияләренә дә, язучы кулланган сәнгатьчә чараларга да кагылалар. Кыскасы, аның бу романын өр-яңа, мөстәкыйль әсәр дип санарга мөмкин.

«Утызынчы ел»ның үзәгенә бик әһәмиятле иҗтимагый-социаль конфликт куелган. Әсәрдә колхозлашу елларында авылда барган гаять зур үзгәрешләр, сыйнфый дошман калдыкларын юк итү, яңа кеше өчен көрәш мәсьәләләре киң чагылыш тапкан. «Шул катлаулы чорның иҗтимагый-политик вакыйгаларын логик эзлеклелек белән күзәтү, алардан да бигрәк мине кешеләр, язмышлар, аларның үзара үрелеше: көрәш, якагаяка килү, ялгышлар һәм күз яшьләре, кыскасы, янә бер кабат кешеләр, аларның язмышлары кызыксындырды», — ди язучы романга кереш сүзендә. Бу чыннан да шулай.

Әле күптән түгел генә басылып чыккан «Минем тәрәзәләрем» повесте үзенең формасы, төзелеше ягыннан Ф. Хөснинең башка роман һәм повестьларыннан нык аерылып тора. Бу — автобиографик повесть. Монда Ф. Хөсни, язучы буларак, үзенең тормыш һәм иҗат юлына әйләнеп карый, әдәбият юлына ничек аяк басуы, дөньяга карашы ничек формалашуы, кыенлыклар белән ничек көрәшүе турында кызыклы һәм мавыктыргыч итеп сөйли. Әсәрдә фактик материаллар бик күп. Ләкин автор үзенең биографик материалларын теркәп баруны гына максат итеп алмаган. Ул үз заманындагы тормышка художникларча бәя бирергә омтыла.

Әсәрнең буеннан-буена Ф. Хөснигә хас булган юмор һәм ирония сизелеп тора. Бу ирония еш кына авторның үзенә юнәлтелә һәм, үз чиратында, укучы белән язучы арасындагы контактны ныгытырга ярдәм итә. Җиңел, матур тел белән язылган бу әсәрне ләззәтләнеп укыйсың.

«Минем тәрәзәләрем» повестендагы бер әһәмиятле моментны билгеләп үтмичә булмый. Сүз шәхес культы һәм язучының аңа мөнәсәбәте турында бара. Коммунистлар партиясе шәхес культының никадәр зарарлы икәнлеген халыкка аңлатты, бу ямьсез күренешне гаепләде һәм аның калдыкларына каршы көрәш ачты. Шәхес культын, аның зарарлы нәтиҗәләрен партия позицияләреннән торып гаепләү, тормышыбызда ленинчыл принципларны яклау темасы совет әдәбиятында киң яктыртыла.

Ф. Хөсни дә үзенең автобиографик повестенда менә шушы темага мөрәҗәгать итте. Автор нинди генә катлаулы шартларда да совет кешеләренең социализм эшенә, туган партиясенә ышанычлары какшамау турында яза.

Соңгы елларда татар әдәбиятында истәлекләр, мемуарлар жанры җанлана башлады. М. Максуд, генерал Сафиуллин, генерал Булатов язмалары янына бүген «Минем тәрәзәләрем» өстәлде. Бу жанрдагы әсәрләрне кимчелекләрдән азат дип әйтеп булмый әле. Төп идеядән читкә китү, тормыш вaклыкларын тасвирлауга кирәгеннән артык урын бирү, композицион бөтенлек җитмәү «Минем тәрәзәләрем» повесте өчен дә хас. Әсәрнең сюжет төзелешенә артык зыян китермичә, язучының балалык елларын сурәтләгән яки торак шартларын яхшырту өчен тырышып йөрүе турындагы эпизодларны кыскартырга мөмкин иде кебек. Әсәрнең иң әйбәт урыннары — язучының иҗаты, дөньяга карашлары, уйланулары һәм Һ. Такташ, Г. Ибраһимов, Г. Гали кебек күренекле әдипләр белән очрашулар турында язылган битләр.

Ф. Хөсни әсәрләренең укучы күңеленә тәэсир итү көче бик зур. Аларда тормыш күренешләрен җентекләп һәм төгәл сурәтләү белән беррәттән, кеше күңеленең иң нечкә якларына тирән үтеп керү дә бар. Язучының иҗат арсеналы бай, сәнгатьчә чаралары күп төрле. Аның профессиональ осталыгы бигрәк тә халык теленнән уңышлы файдалануда сизелә. Ф. Хөсни халык телендәге чагыштырулар, тәгъбирләр, фразеологик әйләнмәләр, мәкальләрне бик урынлы һәм мул куллана. Билгеле, аларны санап чыгу юлы белән генә Ф. Хөснинең тел осталыгын күз алдына китерергә мөмкин түгел. Чөнки халык тормышын, аның телен яхшы белү, халыкка якынлык язучының бөтен стилен сугара, аның язу алымының органик бер кисәге булып тора. Халыкның тел байлыгы аның интонациясендә дә сизелә. Гүя автор үзе әнә шул геройлар белән янәшә, бергә яшәп үскән, гүя алар белән бергә уйлый.

Автор геройлар телен индивидуальләштерүгә зур әһәмият бирә. Индивидуаль сөйләм кешеләрне бер-берсе белән бутамас өчен генә түгел, ә башка зуррак максатлар белән кулланыла. Ул персонажларның төп характер сыйфатын, социаль карашларын яки аның позициясен ачыклау өчен кирәк.

«Утызынчы ел» романында Галләм хаҗиның икейөзлелеге аның сөйләме аша бик яхшы бирелә. Бурычка он сорап килгән Гайния белән сөйләшкәндә, ул яхшы атлы булып күренергә тели: «Бурада тарткан он булса, — дип башлады ул җайлап кына,— онын анысын алып китәрсең, үз мөселманыңнан жәл түгел, китап та шулай кушкан, кабасы ризыгыңны мохтаҗлар белән бүлешеп кап, дигән» [1].

Ә менә монысы кызу канлы, бар белгәнен, нәрсә уйлаганын турыдан-туры ярып сала торган Гафи сүзләре:

«Кайсы контра әйтте сиңа, колхозда кәҗә-сарык җыялар дип? — дәррәү кызып китүдән ул беравык сүзләрен әйтә алмас булды. — Явно контра коткысы. Бүгенгесе көндә, әйтик, производство коралы дип кәҗәне кайсы дурагы әйтә алыр икән, әгәр контра булмаса?» [2]

Тормыш дөреслегенә ирешү өчен язучы һич әһәмиятсез кебек күренгән вак детальләрне дә игътибарсыз калдырмыйча, үзенең күңел складына сала барырга тиеш. «Тормышта ишетелгән үткен сүз, күңелле җыр кисәге, характерлы пейзаж, җәйге яңгырдан юылып, аеруча бизәнеп калган табигать күренешләре, такмак, табышмак, башкаларны кабатламый торган жест һәм тагын бик күп, бик күп башка әнә шундый «вак-төякләр» — язучы аларның барысын да, барысын да терки, хәтеренә сеңдереп калдыра, кирәк чагында алардан файдалана, үзенә кирәкләрен сайлап ала, эшкә куша» [3].

Әсәрдәге күренешләрнең, вакыйгаларның, кешеләрнең тормыштагыча, ышандыргыч итеп күрсәтелүенә Ф. Хөсни иҗатында бик мул кулланыла торган шундый конкрет деталь-штрихлар ярдәм итә дә инде.

Геройның кыяфәтен яки психологик хәлен бирү өчен автор еш кына чагыштыру куллана, һәм, шулай итеп, картиналарның ачыклыгына ирешә. Менә «Утызынчы ел» романында Котдус Вафинны характерлаган бер мисал:

«...Карчыгадай үткен күзләре белән тагын китапка, китап азагындагы кәкре-бөкре юлларга кадалды». («Утызынчы ел», 209 бит.)

Ф. Хөсни туган як урманнарына, кырларына гашыйк, бу матурлыкны ул үз төсендә, кабатланмый торган буяуларында укучыга да җиткерергә тырыша. Язучы ел фасылларын, табигать күренешләрен зур эмоциональ көч һәм лиризм белән тасвирлый.

Сөйгәнен озатырга килеп тә, очраша, аңлаша алмый калган Айдарның («Авыл өстендә йолдызлар», 166 бит) күңелен төшенкелек билэп ала. Ул уйга батып, тимер юл буенда басып торганда андагы табигать күренешен автор менә болай сурәтли:

«Станция алдындагы клумбада чәчәкләр инде әллә кайчан куырылганнар, көзге җил аларның буш сабакларын селкеткәләп куя, күктә өер-өер яңгыр болытлары йөри, кояш әллә нигә бер болытлар арасыннан күренеп, «әле мин исән, әле мин сезнең белән» дигән сыман, салкын гына елмаеп куйган була да, аннары тагын югала, кыскасы, чын мәгънәсендә көз һәм, шуның өстенә тагын, Айдар шушы салкын кояш астында

---

[1] Ф. Хөсни. Утызынчы ел. Казан, 1963, 12 бит.
[2] Шунда ук, 141 бит.
[3] Ф. Хөсни. Уйланулар. 91 бит.

ялгыздан-ялгыз басып калган иде. Эче пошудан җанын кая куярга белмичә, яшен суккан багана кебек, байтак кына вакыт шунда поезд китеп югалган якка таба карап торды ул». Күрәсез, табигать күренеше геройның эчке кичерешләрен ачыклауга ярдәм иткән. Һәм бу шулай булырга тиеш тә. Чөнки Ф. Хөсни үзе әйткәнчә, «хикәядә пейзаж картинасы, табигать тасвиры, сюжетның органик бер кисәге буларак, хикәядә сурәтләнә торган персонажларның рухи халәтләрен төсмерләүгә хезмәт иткәндә, димәк, бөтен бер организмның аерылгысыз бер кисәге булганда гына үзен аклый ала». (Ф. Хөсни. Уйланулар, 104 бит.)

Күңелендә беренче мәхәббәт уты кабынган Котдус («Утызынчы ел» романы) кышкы салкын иртәдә ерактагы станциягә җәяү чыгып китә. Таңны ул урманда каршылый. Бу таң атуның гүзәллеген Котдус кебек дөньяга гашыйк булган кешеләр генә бөтен тулылыгы белән күрә алалар. Шаян бизәкләр, гадәттән тыш чагыштырулар бу очракта тулысынча акланган, чөнки алар бу минутта югары хисләр дөньясында гизгән Котдусның күңеле аша биреләләр. Яңа чыгып килүче кояшны ул мыекларын сузган песи баласына охшата, «ә каен кәүсәләре битләренә кершән яккан яшь кызлар кебек күренәләр... ә күк үзе, урман юлы өстеннән, агач ябалдашлары арасыннан, як-яктагы ярларына сыенып, тулып аккан зәңгәр су кебек» («Утызынчы ел», 216 бит.)

Табигатьне болай күзаллау нәкъ менә романтик табигатьле, нечкә күңелле Котдуска ятышып тора, аның күңел байлыгының киңлеге турында сөйли.

Ф. Хөснинең иҗат юлы шактый катлаулы һәм ул уңышлардан гына тормый. Вакыты-вакыты белән аның каләме ялгышкаладьг да, кайбер очракларда язучы тормышның олы агымыннан читтәрәк тә барды. Ләкин болар үсү юлында очрый торган ялгышлар иде.

Язучы иҗатындагы кимчелекләрнең берсе итеп, аның иҗтимагый әһәмияте зур булмаган мәсьәләләргә кайбер очракларда кирәгеннән артык игътибар итүен һәм тормышның вак-төяк мәсьәләләре белән күбрәк мавыгуын әйтергә кирәк. Ф. Хөснинең, тормышны реаль, җанлы рәвештә сурәтләгән хикәяләре белән берраттән, әһәмиятсез күренешләрне тасвирлаган хикәяләре дә күренгәләде. Нигезенә зур идеяләр, кеше характеры, тормыш конфликтлары салынмаган әсәрләрне әдәби чаралар, тел шомалыгы, композиция төзүдәге осталык та коткарып кала алмый (мисал өчен «Яшь әтәч», «Күршеләр», «Ата каз» хикәяләрен алырга була). Мондый әсәрләрдә язучының таланты, күзәтүчәнлеге бушка эшли, үзе әйтмешли «туптан чыпчыкка ату» булып кала. Аның иҗатындагы бу җитешсезлекне тәнкыйтьчеләрдән Г. Халит һәм И. Нуруллин дөрес күрсәтеп үттеләр.

Ләкин, кабатлап әйтик, болар Ф. Хөсни иҗатында төп юнәлеш түгел. Ул үзенең геройларын «кечкенә кешеләр» дип атаса да, аның күп әсәрләре бу кешеләрнең кечкенә түгеллеген бик ачык раслый. Аның геройлары югары мораль сыйфатларга ия булган хезмәт кешеләре, намуслы совет кешеләре. Язучы әнә шул иң гади, тормышта безгә көн дә очрый торган кешеләрнең матурлыклары турында сөйли.

Ф. Хөсни иҗатының иң кыйммәтле ягы — аның кешеләргә булган мәхәббәте, аларның эчке дөньяларын бөтен тулылыгы белән сурәтләргә тырышуы. Аның иҗатында хезмәт ияләренең уй-кичерешләрен, хисләрен тасвирлау, аларның характерларын тудыру игътибар үзәгендә тора. Ул, гуманист язучы буларак, кеше күңелен зур бер дөнья итеп карый, кешенең гүзәл якларын күрергә омтыла, горурлыгын яклый, бөеклеген исбат итә.

Соңгы елларда илебездәге башка милләт халыкларына да Ф. Хөснинең үзенчәлекле иҗаты белән танышырга мөмкинлек туды. «Җәяүле кеше сукмагы» романы рус һәм казах телләрендә, «Йөзек кашы», «Авыл өстендә йолдызлар» повестьлары, күп кенә хикәяләре рус телендә басылып чыкты. Бу көннәрдә «Утызынчы ел» романы Мәскәүдә зур тираж белән басылып ята.

Язучы зур иҗат планнары белән яши. Киләчәктә дә ул безне бүгенге совет кешесенең гүзәллеге турында сөйли торган яңадан-яңа әсәрләре белән шатландырыр дип ышанабыз.

# Китап күзәтү

## ЛЕНИН ҺӘМ ТАТАРСТАН

Бөек Ленинның җәмгыятьне революцион үзгәртеп кору өчен, коммунизм өчен көрәш турындагы теоретик мирасын һәрьяклап өйрәнү — совет тарих фәне алдында торган иң мөһим бурычларның берсе.

Бөек Октябрьның 50 еллыгы һәм Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулу көннәре якынлашу уңае белән бу бурыч хәзер аеруча зур әһәмияткә ия булып тора.

Коммунистлар партиясе тарихының барлык этапларында да Ленинның бөек ролен дөрес итеп күрсәтү буенча совет тарихчылары шактый зур эш башкардылар. СССР Фәннәр академиясенең Казандагы тел, әдәбият һәм тарих институты һәм КПССның Татарстан өлкә комитеты Партия архивы тарафыннан әзерләнеп, әле күптән түгел генә басылып чыккан «В. И. Ленин и Татария»[1] исемле җыентыкны да Ленинианага билгеле бер дәрәҗәдә өлеш кертү булды дияргә кирәк. Ленинга бәйләнешле урыннардагы документларны туплап чыгаруда бу җыентык асылда безнең илдә беренче тәҗрибәләрнең берсе булды.

Җыентыкка Ленин әсәрләрендә, Ленин турындагы җыентыкларда һәм документаль материалларда игълан ителгән Татарстанга бәйләнешле документлар кертелгән. Болардан тыш, КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Марксизм-ленинизм институтының Үзәк архивыннан, Октябрь революциясенең Үзәк дәүләт архивыннан, КПССның Татарстан өлкә комитеты Партия архивыннан һәм Татарстан АССРның Үзәк дәүләт архивыннан табылган, шулай ук үзәк һәм республика матбугатында игълан ителгән материаллар тупланган.

Җыентык 318 документны эченә алган. Шулардан тыш, табылган документларның бер өлеше җыентыкның кереш өлешендә һәм өстәмәләрдә файдаланылган. 90 документ беренче мәртәбә басылган, шуның егерме җидесе — Ленинныкы.

Җыентык түбәндәге бүлекләрдән тора[2]: Ленин документлары; Ленин турындагы документлар; хезмәт ияләренең хатлары, телеграммалары һәм резолюцияләре; Ленин турындагы истәлекләр; өстәмәләр.

Җыентыкның беренче бүлеге аеруча зур әһәмияткә ия. Анда В. И. Ленинның үзе тарафыннан язылган яисә кул куелган 122 документ

---

[1] В. И. Ленин и Татария. Документлар, материаллар һәм истәлекләр җыентыгы. Төзүчеләре М. А. Сәйдәшева, И. В. Бурнашева, Казан, 1964 ел, 358 бит.

[2] Җыентыкка кереш сүзне СССР Фәннәр академиясенең Казандагы тел, әдәбият һәм тарих институты директоры М. К. Мөхәррәмов һәм фәнни сотрудник М. А. Сәйдәшева язган.

урнаштырылган. Истәлекләр бүлегендә Анна Ильинична, Мария Ильинична һәм Дмитрий Ильич Ульяновларның, М. П. Голубева, В. В. Воровский, В. В. Адоратский, Ш. А. Манатов, Г. С. Гордеев, С. Сәедгалиев, А. П. Шувалова, В. М. Бахметьев һ. б. истәлекләре бирелгән. Китап В. И. Ленинның 20 ләп фотографиясе һәм Ленин документларының фотокопияләре белән иллюстрацияләнгән.

Җыентыкка тупланган материаллар В. И. Ленинның 1887 елдан 1924 елга кадәрге чорда Казан партия оешмасы һәм Казан крае хезмәт ияләре белән тыгыз элемтә тотуы турында киң мәгълүмат бирә. Алар революцион хәрәкәтне үстерүдә, Совет властен урнаштыруда һәм ныгытуда, гражданнар сугышы елларында Идел буе районнарын чит ил интервентларыннан һәм акгвардиячеләрдән саклауда, милли республика төзелешендә һәм Татарстан АССР да социалистик үзгәртеп корууларны тормышка ашыруда В. И. Ленинның роле ни кадәр зур булуын бик ачык чагылдыра.

Җыентыктагы документларның байтагы (сиксәнгә якыны) В. И. Ленинның Казанда һәм Кокушкинода яшәгән вакыттагы (1887 елның июленнән 1889 елның маена кадәр) тормышын һәм революцион эшен күрсәтүгә багышланган. Мәгълүм булганча, яшь Ильичның бу чордагы тормышы һәм революцион эшчәнлеге совет тарихи әдәбиятында гомумән алганда шактый тулы яктыртылган. Әмма бу җыентыкны төзүчеләр күп кенә яңа, моңарчы беркайда да басылмыйча архивларда яткан материалларны да тапканнар. Алар, барыннан да элек, патша властен борчуга сәбәпче булган хәл — 1887 елда Казан студентлары арасында революцион хәрәкәтнең үсүе турында сөйләүче документлар. Студентлар хәрәкәтен булдырмый калу өчен, мәсәлән, патша хөкүмәте төрле чаралар күргән, хәтта хәрби частьлар китерүгә кадәр барып җиткән (№ 272—288 документлар [1]). Җыентыктагы материаллар, шул исәптән яңа табылганнары да, Владимир Ильичның Сембер гимназиясендә иң яхшы укучылардан берсе булганлыгын тагын бер тапкыр раслыйлар. Моны патша властеның мәгариф органы вәкилләре дә танырга мәҗбүр булалар.

Гадәттән тыш сәләтле булуын искә алып, аңа математика яки табигать фәннәрен өйрәнергә киңәш итсәләр дә, яшь Володя аңлы рәвештә университетның юридик факультетына укырга керә. Туганы Н. Веретенниковның нигә юридик факультетны сайладың, дип соравына каршы В. И. Ленин: «Хәзер шундый вакыт, хокук фәннәрен һәм политик экономияне өйрәнергә кирәк. Башка вакытта, ихтимал, мин бүтән фәннәрне сайлаган булыр идем»,—дип җавап бирә (№ 246). Күп кенә документлар В. И. Ленин Казан университетында укый башлаган чорда андагы шартларның гаҗәеп дәрәҗәдә кыен булуын, алдынгы студентларның бик нык эзәрлекләнгәнлеген тагын бер тапкыр дәлилләп торалар. Университетка кергәндә нинди дә булса оешмаларда яки түгәрәкләрдә катнашмаска сүз биргән булса да, анда укый башлавының беренче көннәрендә үк Володя революцион эшкә керешеп китә. Полиция департаментының 1888 елның 3 апрелендә язылган документында, мәсәлән, узган ел ахырында Казан да «бик зарарлы юнәлештәге түгәрәк» оешканлыгы һәм җәзаланып үтерелгән Александр Ульяновның энесе, Казан университеты студенты Владимир Ульяновның да шул түгәрәктә член булып торганлыгы әйтелә. Ул түгәрәк «Петербургтагы дәүләткә каршы юнәлтелгән түгәрәкләр белән бәйләнеш тоткан» диелә (№134).

1887 елның 4 декабрендә Казан университетында булган атаклы студентлар сходкасын оештыручы һәм анда иң актив катнашучы кеше дә Володя Ульянов булган. Менә шуңа күрә дә студентлар инспекторы Потапов үзенең бер докладында болай дип язган: Владимир Ульянов

[1] Алда документларның номерларын гына күрсәтеп барачакбыз.

«әле сходкадан ике көн элек үк үзенең ниндидер әйбәт булмаган нәрсәгә әзерләнеп йөрүен сиздерде; аеруча шикле студентлар белән сөйләшеп, вакытын тәмәке тарту бүлмәсендә үткәрде; өенә кайтып-килеп йөрде, башкалар соравы буенча нәрсәләрдер алып килде һәм, гомумән, үзен бик сәер тотты. Ә 4 декабрьда беренчеләр рәтендә актлар залына ташланды һәм, Полянский белән бергәләп, башкаларны рухландырырга теләгәндәй кулларын болгап, икенче катның коридоры буйлап чабып йөрде; сходкадан киткәндә үзенең университетка керә торган билетын калдырып китте» (№ 136).

Патша власте вәкилләре сходкада катнашучы студентлардан бик каты рәвештә үч ала. Мәгариф министры Делянов 1887 елның 5 декабрендә «әйбәт уйлаучыларны коткару өчен юньсезләрне кызганмаска» кушып, махсус телеграмма җибәрә (№291). Володя Ульянов шундук университеттан чыгарыла һәм Казан төрмәсенә ябыла. Аннары Казаннан 40 километрдагы Кокушкино авылына сөргенгә озатыла. Кокушкинода да аның өстеннән яшерен күзәтү алып барыла (№ 131).

1888 елда Володя Ульянов яңадан Казанга кайта һәм Н. Е. Федосеев тарафыннан оештырылган марксистик түгәрәкләрнең берсендә катнаша башлый, актив революцион эш алып бара (№150). Шулай итеп, В. И. Ленинның революцион эшчәнлеге Казанда башлана.

Соңыннан, инде Казаннан киткәч тә В. И. Ленин Казан социал-демократларына һәм, гомумән, Казан краенда булган хәлләргә туктаусыз игътибар биреп, ярдәм итеп тора. Моның чыннан да шулай икәнлеге җыентыкта В. И. Ленин хезмәтләреннән алып урнаштырылган документлардан бик ачык күренә. Мәсәлән, В. И. Ленин үзенең «Россиядә капитализмның үсеше» дигән зур хезмәтендә, Россиядәге капиталистик мөнәсәбәтләрнең ничек үсүен күрсәтү өчен, Казан губернасыннан да мисаллар китерә. (Бу китап, басылып чыккан елында ук, Казанга да килеп җитә.) Күп кенә документлар В. И. Ленинның өч рус революциясе чорында да Казан краендагы эшче һәм социал-демократик хәрәкәтләрне зур игътибар белән күзәтеп баруы турында сөйли. Әйтик, «Приближение развязки» исемле мәкаләсендә Казан эшчеләренең 1905 елгы чыгышларына В. И. Ленин патша властен бәреп төшерүгә һәм кораллы восстаниягә китергән вакыйга дип югары бәя бирә [1]. В. И. Ленинның кушуы буенча, беренче рус революциясе елларында Н. К. Крупская да Казан РСДРП комитеты белән тыгыз элемтә тота (№№ 303—309). Казан губернасында III Думага сайлауларны анализлап, В. И. Ленин үзенең «IV дәүләт Думасына сайлау кампаниясе» исемле хезмәтендә IV дәүләт Думасына сайлаулар кампаниясе вакытында эшчеләр демократиясе башкарырга тиеш булган конкрет бурычларны билгели.[2] РСДРПның VII (Апрель) Бөтенроссия конференциясендә ясаган чыгышында да, большевиклар партия оешмасының урыннардагы эшен характерлап, В. И. Ленин «Казандагы иптәшләр»нең социалистик революция алдында торган бурычларны дөрес аңлауларын билгеләп үтә [3].

Бу документларны «Ленин и Татария» исемле җыентыкка кертеп, төзүчеләр бик яхшы иткәннәр. Ләкин 1917 елга кадәрге чорга караган документларның, кызганычка каршы, төзүчеләр игътибарыннан читтә калганнары да бар. Мәсәлән, РСДРПның Казан комитеты тарафыннан «Пролетарий» (1905 елгы) исемле Ленин газетасының барлык саннары да алынган булу турындагы Марксизм-ленинизм институтының Үзәк партия архивында саклана торган хат [4] җыентыкка кертелмәгән.

---

[1] В. И. Ленин. Соч. изд. 5-ое, т. 12, стр. 77.
[2] В. И. Ленин. Соч. изд. 5-ое, т. 21, стр. 52—55.
[3] В. И. Ленин. Соч. изд. 5-ое, т. 31, стр. 378.
[4] К. Зародов. Ленинская газета «Пролетарий» (1905 г.). Госполитиздат, 1955 г., стр. 32.

Ә ул хатта сүз «Пролетарий» газетасының Казан большевиклары һәм эшчеләре арасында зур җанлану тудыруы турында бара бит, югыйсә.

В. И. Ленин 1907 елның 25 январеннан 19 ноябрена кадәр РСДРП ның Мәскәү, Петербург, Казан һәм башка шәһәр комитетлары органы буларак чыккан «Пролетарий» газетасының редакторы булып эшли һәм Казан большевикларының матбугат органы белән турыдан-туры үзе җитәкчелек итә. 1906—1908 елларда чыккан «Вперед» газетасы белән дә шул ук хәл була. Менә бу фактлар да җыентыкта чагылдырылмаган.

Марксизм-ленинизм институты Үзәк партия архивында саклана торган солдат Ефим Федотов хатын да (1917 елның җәендә партиянең Үзәк органына мөрәҗәгать итеп, В. И. Ленинны һәм «Правда» газетасы сотрудникларын кайнар котлап язылган хат ул) җыентыкка кертергә кирәк иде шикелле. Җыентыкта В. И. Ленинның нинди хезмәтләре Казандагы большевистик һәм демократик матбугатта басылып чыкканлыгы һәм нинди хезмәтләре чит илдән алып кайтып бастырылуы һәм таратылуы турында җитәрлек мәгълүмат юклыгын да мактап булмый, әлбәттә. (Мәсәлән, легаль татар матбугатында В. И. Ленин исеменең инде 1906 елда ук күренә башлавы билгеле [1].)

Бөек Октябрь революциясенең җиңүе һәм ныгуы, социалистик Ватаныбызны коралллы саклау чорында В. И. Ленинның Татарстан белән бәйләнешен чагылдыра торган материаллар җыентыкка шактый күп кертелгән. Яшь Совет дәүләтен оештыручы В. И. Ленин урыннарда, шул исәптән Казан губернасында да, Совет властен ныгыту белән җитәкчелек итә. Советлар республикасының оборонасын оештыручы бик зур хәрби стратег буларак, ул революция язмышы хәл ителә торган гражданнар сугышы фронтларындагы иң җаваплы урыннарны тиз генә сизеп алып, совет халкын шул фронтлардагы дошманны тар-мар итүгә мобилизацияли. 1918 елның җәендә В. И. Ленин гражданнар сугышы фронтларының иң җаваплы урыны — Казан — Урал — Самара тирәләрендәге Көнчыгыш фронт булуын басым ясап әйтә. Кызыл Армиянең сугышчан көчен һәм мораль-политик хәлен яхшырту өчен бу фронтка В. И. Ленин инициативасы белән Петроград, Мәскәү һәм башка промышленность үзәкләреннән һич кичекмәстән пролетариатның яхшы вәкилләре җибәрелә. В. И. Ленин Казан фронтын тиешенчә тәэмин итү белән бик нык кызыксынып тора.

Казан ак чехлардан азат ителгәч, В. И. Ленин бу хәлгә бик шатлана һәм, Казанны азат иткән кызылармеецларны җиңү белән котлап, телеграмма җибәрә. Аннан соң да В. И. Ленин Татарстанның хәле белән туктаусыз кызыксынып, аның турында кайгыртып тора. Моның шулай икәнлеге 1918 елда акгвардиячеләр белән сугыш вакытында таркалган совет органнарын торгызу өчен Совет хөкүмәте тарафыннан Казан губерна башкарма комитетына бирелгән 5 миллион сум күләмендәге ярдәмнән дә ачык күренә (№50).

1919 елда Көнчыгыш фронт яңадан гражданнар сугышының иң җаваплы урынына әйләнә. Бу уңай белән В. И. Ленин «Көнчыгыш фронттагы хәл буенча РКП(б) Үзәк Комитеты тезислары»нда Колчак армиясенә каршы көрәш программасын бик ачык итеп аңлатып бирә (№55). Җыентыктагы материаллар ул чорда да В. И. Ленинның Көнчыгыш фронтка, аерым алганда Татарстан җирендә бара торган сугыш хәрәкәтләренә, бик зур игътибар бирүен һәм конкрет ярдәм итеп торуын бик ачык күрсәтәләр. Шулай да Оборона Советы Председателе В. И. Ленинның 1919 елның 16 апрелендә Идел буе совнархозларына, шул исәптән Казан совнархозына да, җибәргән телеграммасы нигәдер җыентыкка

[1] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казань, 1964 г., стр. 227.

кертелми калган [1]. (Ул телеграммада Көнчыгыш фронт армияләрен тәэмин итүгә бәйләнешле таләпләрне һәм заказларны үз вакытында үтәүгә һәм Идел буе, Урал хәрби округларында оештырылучы частьларга кирәк кадәр кием-салым булдырырга күрсәтмә бирелгән.)

Җыентыктагы күп кенә материаллар В. И. Ленинның Казан краендагы фронтка якын булган һәм акгвардиячеләрдән азат ителгән районнарда халык хуҗалыгын торгызу һәм юлга салуда, тылдагы совет халкын фронтка ярдәм итәргә мобилизацияләүдә, промышленность предприятиеләренең туктаусыз һәм мөмкин кадәр күбрәк эшләвен тәэмин итүдә, ягулык мәсьәләсен хәл кылуда һәм халык хуҗалыгында бөлгенлекне бетерү өчен көрәштә бик әһәмиятле күрсәтмәләр биреп, ул күрсәтмәләрнең үтәлүе белән һәрвакыт кызыксынып торуы турында сөйли. Әйтик, В. И. Ленин инициативасы белән 1918 елның июлендә Паратский затонындагы Балтик заводын (суднолар төзүче һәм ремонтлаучы Паратский мастерскойларын да кушып) торгызу турында карар кабул ителә. 1920 елның 2 ноябренда, шулай ук В. И. Ленин җитәкчелегендә, Халык Комиссарлары Советы хәрби киемнәр эшләп чыгаручы Казан кием-салым мастерскойлары эшчеләрен бүләкләү мәсьәләсен тикшерә (№ 97).

В. И. Ленинның хәрәкәттәге армияләрне һәм илебезнең промышленность үзәкләрен икмәк һәм авыл хуҗалыгының башка төр продуктлары белән тәэмин итүдә эшчәнлеге турында да җыентыкта күп кенә материаллар урнаштырып, аны төзүчеләр яхшы иткәннәр. Шулай да бу мәсьәләгә карата 1919 елның 1 июнендә В. И. Ленин тарафыннан Казан губпродкомына җибәрелгән түбәндәге телеграмманың җыентыкка керми калуы кызганыч: «Казань. Губпродком. Вне всякой очереди. Немедленно отправьте весь имеющийся зернофураж в Камышин, продбазе Десятой армии, отправка должно быть произведена в порядке боевых грузов. Через пять дней телеграфируйте мне количество отправленного, дни отправки. Предсовобороны Ленин» [2].

Тимер юл транспортын торгызу мәсьәләсе дә В. И. Ленинның игътибар үзәгендә торган. Бу эшне юлга салу максаты белән Совет хөкүмәте В. И. Ленинның турыдан-туры үз җитәкчелегендә оештырылган, республиканың Идел буе районнарында урнашкан Запас армияне файдаланырга карар кыла. Армиянең төп көчләре, штабы һәм политбүлеге Казанда була.

Оборона Советының 1920 ел 23 январендагы карары нигезендә, Запас армиягә мөмкин кадәр тизрәк Мәскәү — Казан — Екатеринбург тимер юлын сафка бастыру бурычы йөкләтелә. Запас армиянең сугышчылары, Казан крае эшчеләре белән берлектә, Совет хөкүмәтенең бу карарын билгеләнгән вакыттан бер ай алдан үтәп чыгалар — Колчак бандалары җимереп киткән (Кама елгасы аша салынган) күперне сафка кертәләр һәм 1920 елның 17 февралендә ул күпердән илнең промышленность үзәкләренә икмәк илтүче поездлар үтеп йөри башлый. Менә шул фидакарь хезмәтләре өчен, 1920 елның 13 мартында Оборона Советының махсус карары белән, В. И. Ленинның Мәскәү — Казан тимер юлчыларына белдергән рәхмәте [3] булса да, ул документ та җыентыкны төзүчеләрнең игътибарыннан читтә калган.

Татарстан нефтен тикшерүдә В. И. Ленинның турыдан-туры катнашуын раслаучы бик кызыклы документларның җыентыкка кертелмәвен дә китапны төзүчеләрнең җитешсезлеге дип әйтәсе килә. Әле гражданнар сугышының иң авыр вакытында ук (1919 елның җәендә), В. И. Ленинның кушуы буенча, академик И. М. Губкин һәм Бөтенроссия Халык

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, ф. 521, оп. 1, ед. хр. 1, л. 7.
[2] ЦГАОР, Ф. 1943, оп. 1. ед. хр. 544, л. 105.
[3] Известия. ВЦИК, № 58 (905) от 16 марта 1920 г.

Хуҗалыгы Советы президиумы члены Ф. Ф. Сыромолотов җитәкчелегендә Казан губернасы районнарында нефть булу-булмауны тикшерү өчен геологик разведка экспедициясе җибәрелә. Ә 1919 елның 26 августында экспедиция җитәкчеләре беренче тикшеренүләрнең уңышлы чыгуын — Идел-Урал районнарында шактый бай нефть ятмалары булуын әйтеп, В. И. Ленинга Казаннан телеграмма җибәрәләр. Шул ук елның сентябрендә Бөтенроссия Халык Хуҗалыгы Советы президиумында доклад ясап, И. М. Губкин Идел-Урал районында, аерым алганда Татарстандагы Сүкәй тирәләрендә, нефть чыгара башлау буенча практик чаралар тәкъдим итә.

Җыентыктагы бер төркем документлар В. И. Ленинның Татарстан культурасын үстереп җибәрүдә, төрле типтагы уку йортларының һәм партия-совет матбугатының эшен юлга салуда да актив катнашуын күрсәтүгә багышланганнар. Бу уңайдан 1919 елның 11 июнендә Ленин имзасы белән кабул ителгән Совнарком карары аеруча әһәмиятле. Ул карар — Казан авыл хуҗалыгы институтына сметадан тыш кредит бирү турында. 1920 елда В. М. Бахметьев белән әңгәмә вакытында В. И. Ленин Казандагы матбугат, полиграфия базасының торышы һәм милли интеллигенция белән бәйләнеш мәсьәләләрен җентекләп сораша. Шул ук вакытта, ул татар әдәбияты классикларының, аерым алганда шагыйрь Габдулла Тукайның, алмашлары бармы дип тә сорый (№ 262, 266, 269 һ. б.).

В. И. Ленин әле революциянең беренче елларында ук Казанда совет тарих фәнен үстерүгә игътибар итә. Аның инициативасы белән Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы тарихын өйрәнү буенча эш башлана: Казан университетының күренекле галиме В. В. Адоратскийга революция һәм гражданнар сугышы тарихы буенча очерклар язу бурычы йөкләтелә һәм урындагы дәүләт органнарына бу эштә аңа һәртөрле ярдәм итәргә күрсәтмә бирелә.

Казан краен Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасына әверелдерүгә һәм 1921 елгы ачлык вакытында Татарстан халкына бик зур ярдәм күрсәтүгә В. И. Ленинның әйтеп бетергесез зур игътибар итүен чагылдырган материалларны шактый күп туплап, җыентыкны төзүчеләр бик яхшы иткәннәр.

1918 елда В. И. Ленинның эсэрлар тарафыннан явызларча яралануы бөтен совет халкында, шул исәптән Татарстан хезмәт ияләрендә дә, бик нык ачу тудыра. Эшчеләр, крестьяннар һәм кызылармеецлар бөек Ленинны яралаган өчен дошманнардан үч алырга ант итәләр һәм даһиның сәламәтлеге турында сорашып торалар. Ә В. И. Ленинның хәле яхшырып, ул яңадан эшли башлагач, 1922 елның 14 октябрендә Казандагы заводы эшчеләре аңа хат язалар: «Сәламәтләнүең уңае белән,— диелгән ул хатта,— сиңа кайнар сәлам җибәрәбез, Россия һәм бөтендөнья пролетариаты җитәкчесенең безнең сафларыбызга яңадан кайтуына без бик шатбыз. *Владимир Ильич,* синең сәламәтлегең безгә көч, куәт һәм ышаныч бирә...» (№ 219). Җыентыкта моннан тыш, 1922 елда Кокушкино авылы крестьяннарының В. И. Ленинга язган хаты һ. б. материаллар да урнаштырылган. Шулай да җыентыкны төзүчеләр ул елларда милли вакытлы матбугатта В. И. Ленинга мөрәҗәгать итеп язылган материалларны күбрәк файдалансалар, тагын да яхшырак булыр иде шикелле. Әйтик, 1918 елда Үзәк мөселман комиссариатының Галимҗан Ибраһимов имзасы белән беркетелеп, В. И. Ленин исеменә адресланган һәм «Чулпан» газетасында басылып чыккан телеграммасының (анда сөекле юлбашчыбыз өчен дошманнардан үч алырга ант итү турында сүз бара) җыентыкта булмавы белән бик үк килешәсе килми. Безнеңчә, Татарстанга турыдан-туры карамаган яки инде моңарчы матбугатта басылган кайбер материалларны кыскарту хисабына булса да, бу документны җыентыкка урнаштырырга кирәк иде.

Ә менә шәхес культы чорында онытылып торган һәм әдәбиятта аз билгеле булган кешеләр турында биографик белешмәләр бирә торган күп кенә материаллар (К. А. Абдрахманов, В. Б. Халатов, И. Т. Гаврилов, И. И. Межлаук, И. И. Ходоровский, Ш. Н. Ибраһимов, А. П. Шувалова һ. б. турында) урнаштырып, җыентыкны төзүчеләр бик дөрес иткәннәр. Дөрес, бу бүлектә дә кайбер җитешсезлекләр сизелеп тора. Мәсәлән, Д. П. Малютин, В. В. Кураев, А. И. Израйлович, Б. И. Гольдберг һәм башкалар турындагы белешмәләр тулы түгел, ә В. П. Булич, Н. П. Брюханов һ. б. лар турында бернинди мәгълүмат та бирелмәгән. Безнеңчә, китерелгән документларның исемлеге дә бирелгән булса, җыентык тагын да отышлырак чыккан булыр иде.

Җыентык кайбер фактик кимчелекләрдән дә азат түгел. Мәсәлән, хәрби мөселман шурасының юкка чыгарылу датасы (351 бит) һәм 17 биттәге В. И. Ленин хезмәтеннән алынган цитатаның чыганагы дөрес күрсәтелмәгән. 175 нче документның кабул ителү датасында һәм текстында да хата бар һ. б. Бөек юлбашчыбызның Татарстан белән бәйләнешен яктыртуга багышланган шушындый мөһим җыентыкның нибары 1300 данә тираж белән генә чыгарылуын да искәртеп китәсе килә. Ихтимал, киләчәктә аны күбрәк тираж белән чыгару мәсьәләсен алга куярга кирәктер.

Йомгак итеп шуны әйтәсе килә: «В. И. Ленин и Татария» исемле бу җыентыкны дөньяга чыгарып, аны төзүчеләр бик зур, бик кирәкле эш башкарганнар. Алда без күрсәтеп үткән кайбер кимчелекләр аның кыйммәтен һич тә киметә алмый. Бу җыентык, бер яктан, фәнни работниклар, пропагандистлар өчен бик яхшы кулланма булып торса, икенче яктан, аны күп санлы укучылар да кызыксынып укыячак. Шул ук вакытта ул Ленинианага кертелгән шактый зур өлеш тә булып тора.

*Т. НАСЫЙРОВ,*
*Г. БЕЛЯЛОВ,*
*тарих фәннәре кандидатлары.*

## *Латыш халык мәзәкләре*

### ТУГАННАРЧА БҮЛЕШҮ

Кечкенә Яниска алма бирәләр.

— Бу алманы сеңелең белән туганнарча бүлеш!

— Ә ничек була ул — туганнарча бүлешү?

— Туганнарча бүлешү — үзеңә әзрәкне алып, сеңелеңә зуррак кисәкне бирү дигән сүз ул.

Янис бераз уйлый да сеңелесенә әйтә:

— Мә, бүл әле шул алманы икебезгә, сеңелкәй, туганнарча итеп!

### БУТАЛЫШ

Тол ир тол хатынга өйләнә. Ирнең дә, хатынның да үз балалары була. Аннары аларның икесеннән балалар туа. Берваныт балалар, үзара ызгышып, кыйнашалар.

Ир әйтә шул чакны хатынына:

— Синекеләр белән минекеләр безнең балаларны кыйнаганнар.

### КӨЧТӘНӘЧ

Бер ата үз баласына күчтәнәч итеп колбаса алып кайта һәм әйтә:

— Яртысын энеңә бир. Бүленгән шатлык — икеләтә шатлык ул.

— Ләкин бит бүленгән колбаса ярты гына колбаса була, әти.

# «МУСА АБЫЙ»

Китап тышында, аркылы-торкылы тимер чыбыклар сузылган караңгы фонда, алсу-көрән буяу белән эшләнгән Муса карап тора. Аның уйчан, шул ук вакытта ачулы, бернинди каршы көчкә бирелмәслек нык, кырыс чырае, туры, үткен күз карашы сине дә көрәшкә чакыра, сиңа да көч-куәт биреп тора сыман... Художник Ю. Лысогорский эшләгән тышлык китапның эчтәлеген төгәл ачып бирә, һәм син аны, кулга алгач та туган беренче хисләрдән аерылмыйча, дулкынланып укып чыгасың.

Шагыйрь Әнвәр Давыдовның, минем белүемчә, бу беренче проза әсәре. Сугыш бара торган Волхов тирәләрендәге төнге урманны шигъри тасвирлау белән башланган бу повестьның эчтәлеге, өстән генә караганда, Муса Җәлилнең героик хәрби биографиясен сөйләп-күрсәтеп бирүгә генә багышланган кебек. Сугыш. Камалышта калу. Яралану. Әсирлек. Концлагерьлар. Төрле газап-җәфалар. Яшерен антифашистик эшләр. Легион һәм аңа Мусалар оешмасы йогынтысы. Зур җиңү. Шик астына алыну. Тотылу. Ябылу. Үлемгә хөкем ителү... Әнә шундый мәгълүм фактларны гади биографик әсәр характерында түгел, ә художестволы әсәр — повесть жанрында төрле вариацияләрдә тагын бер тапкыр күрсәтү дә кирәкле һәм файдалы хезмәт, әлбәттә. Әмма, әгәр ул Муса Җәлилнең безгә инде һаман-һаман күбрәк билгеле була барган шушы үткән юлын иллюстратив рәвештә, яссы һәм шаблон формада кабатлау гына булса, аның кыйммәте шактый кимер иде. Бәхеткә каршы, бу китапка карата алай дип әйтеп булмый.

Повестьның укучыны кызыксындыра торган үзенчәлекле, оригиналь яклары бар. Китапның исеме ук — «Муса абый» — әйтеп тора: ул балалар өчен язылган, «урта яшьтәге мәктәп балалары өчен» диелгән. Бу исә әсәр алдына, автор алдына специфик таләпләр дә куя. Ә. Давыдов шуны искә алып, тиешенчә аңлап эш иткән. Мәсәлән, китапта Муса, авыр яраланып дошман тылында калгач та, иң беренче булып Вил исемле 12—13 яшьлек бер малай белән очраша! Мусаның әле саташу, әле аңга килү хәлендә бу малай белән сөйләшүе... Документларын яндыруын аңардан үтенүе... моның өчен шырпы булмаудан хафалану... Малайның шуннан Мусаның документларын «беркем таба алмаслык итеп» җиргә күмеп куюы... Мусаның, яшь малайны тәмам тетрәтеп-калтыратып, пистолетын үз йөрәгенә терәп атуы, тик анда пуля булмау аркасында гына исән калуы... Шунда немецлар килеп чыгып, Мусаны да, малайны да әсир итеп алып китүләре, аларның байтак лагерьларда бергә газап чигеп йөрүләре...

Кем ул Вил? Язмыш аны нинди зур кеше белән очраштырганын ул аңлап җиткерәме? Алда бу ике арадагы мөнәсәбәт нинди юл белән, ничек дәвам итәр? Менә шушындый сораулар, вакыйгалар, ситуацияләр яшь укучыны аеруча дулкынландырып-мавыктырып, китаптан аерылмаслык итә.

Ә бер карасаң, Вил исемле бу татар малаеның тарихы — үзе бер мавыктыргыч хикәя икән һәм ул повесть сюжетына оста һәм кызыклы итеп үреп тә бирелгән.

Ул гынамы әле. Анда тагын Сережа исемле рус малае, Пауль, Курт исемле немец малайлары да бар. Аларның һәркайсы китапта төрле күләмдә урын алып торалар һәм иң әһәмиятлесе, кызыклысы шунда — алар Мусаларның немец тылындагы эшләре, язмышлары белән тыгыз бәйләнешле итеп тасвирланганнар.

Повестьта балаларга, аеруча Вилгә, шулкадәр күп урын бирелгән ки, вакыт-вакыт синдә шундый тойгылар да тумый калмый: тукта әле, Муса турындагы кырыс язмышка мондый бала-чагаларның нинди катнашы булуы мөмкин, дип сагаеп та куясың. Ләкин бара торгач, укый-уйлана торгач, барысы да аңлашыла, акланыла, ышандыра, төгәл документаль әсәр булмыйча, балалар өчен махсус язылган художество әсәре буларак иҗат ителгән бу повесть агышында алар барысы да үз урыннарына бик уңай гына, җайлы гына барып утыралар.

Бу очракта Мусаның үз тормыш-иҗат биографиясе дә авторга нык кына ярдәм иткән һәм аңа балалар өчен нәкъ менә шундый характердагы повесть язуга мөмкинлек тә, хокук та биргән.

Чыннан да, мәгълүм булганча, Муса тормышта да, иҗатында да балаларга бик якын иде, аларны яратучы, аларның гел алга омтылган нәни рухи тормышларын, төрле бай хыялларын бөтен нечкәлекләре белән һәрьяклап һәм тирәнтен аңлый белүче иде. Ул, озак еллар буе, Мәскәүдә чыга торган «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» исемле журналларның редакторы булып эшләде, зур иҗатында балалар өчен дә бик күңелле, кызыклы, тирән эчтәлекле әсәрләр язды. Муса «...еш кына шулай Мәскәү урамнарында очраган малайлар белән сүзгә керергә, хәтта кайчагында уеннарына катнашып китәргә дә ярата торган иде, кайберәүләрен ул редакциягә алып килә, алардан хәбәрләр яздыра» диелә бу китапның да бер урынында. Аннары, Алиш та киң танылган балалар язучысы бит!

Әсәрнең шушындый ягы, аның специфик сюжеты һәм характеры башта ук чагылып үтә. Менә Ленинград өлкәсендә дошман тылы булып калган Бор исемле авылдан ерак түгел урманда, куе үләнгә күмелеп, бер калкулык кебек кенә булып торган землянка. Татар малае Вил белән рус малае Сережа шунда качып яшиләр, вакыт-вакыт авылга кайтып, азык-төлек алып киләләр. Калган вакытларын сугыш тынганрак урыннардан корал очраса — корал, патрон очраса — патрон җыеп уздыралар. «Башта алар, бик күп корал җыеп, фашистларга каршы икәү кузгалырга исәп тотып хыялландылар, аннан аларга Бор авылының таныш укытучысы Владимир Николаевич очрый, бу коралларның әле бик кирәк булачагын әйтә, шулай итеп, аларның землянкасы бер төркем кыю совет кешеләренең корал арсеналына әверелде, ә малайлар үзләре шул арсеналга корал ташучы да, сакчы да булдылар». Ә хыяллары исә — һаман да герой сугышчы булу...

Менә алар ул авыр фаҗигале еллар турында, немецларның ерткычлыгы турында әкрен генә, ашыкмыйча гына үзара сөйләшәләр, бәхәс алып баралар. Аларның бу аңгәмәләрендә, гамәлләрендә, хыялларындагы кебек үк, заманга хас житдилек тә, балаларга хас беркатлылык та чагыла. Янәсе, бу явыз немецларны берсен дә калдырмыйча атып-кырып бетерергә кирәк... Немец... ә Тельман, Клара Цеткин һ. б. Алары бер-ике генә, андыйларны үзебезгә алдырырга, ә калганнарын бетерергә... Мондый ялгыш фикерләр шунда ук житди каршылыкка да очрый. Һәр халыкта яхшы кешеләрнең күп булуын, тик кайчакта Гитлер кебек начарларының халыкны җәфалавын балаларга аңлатуда шул ук Муса ярдәмгә килә: «Күптән түгел,— ди Вил, — мин татарча бер китап укыдым. «Джим». Муса Җәлил язган... Күп яза ул шагыйрь, әй кызык инде... Ул китапта фашистлар яхшы немецларны төрмәләргә утырталар... Эмма исемле кечкенә кыз-

ның негр курчак белән уйнавын да атасына гаеп итеп куялар...»

Вилнең тарихы — үзе бер мавыктыргыч хикәя, дигән идек. Чыннан да шулай икән. Китап битләрендә ул ниләр генә эшләми, кемнәргә генә әверелми! Ул — безгә таныш татар малае Вил дә, ул — немец малае Вильгельм Кнаппе да, ул — гитлерчы майор Штрауссның тәрбиясендәге ышанычлысы булып, татар әсирләренең ниләр сөйләвен яшертен тыңлап йөрүче «шымчы» Әхмәт тә, һәм ул — асылда — менә дигән совет малае, Мусаларга, Алишларга авыр көрәшләрендә зур гына булышлык күрсәтүче чын патриот малай. «Үзенең ябык җилкәләре белән олылар күтәргән кадәр авыр йөкне күтәрергә мәҗбүр булган бу сабый» образын автор нигездә бик уңышлы итеп күрсәтә алган.

Ничек килеп чыга мондый ситуацияләр, — боларның барысын кечкенә рецензиядә сөйләп бирү мөмкин түгел һәм бу очракта моның кирәге дә юк, аның өчен бу мавыктыргыч кызыклы сюжетка корылган китапның үзен укып чыгарга киңәш итәбез. Тик шуны әйтергә кирәк: Муса турында, аның батырлыгы, тапкырлыгы, балалар дусты булуы һәм шулай булып калуы турында балалар өчен язганда Әнвәр Давыдов реаль тормышка хилаф булмаган иҗат фантазиясен шулай тулы көчкә җәелдереп җибәреп дөрес эшләгән. Зур хыяллар да, романтика да, төрле маҗаралар да, хәтта детектив элементлар да бар анда һәм аларның берсен дә кире кагып булмый, алар урынлы, кирәкле кулланылганнар, ә балалар, яшь укучылар, мондый китапларны мавыгып, бирелеп укыйлар, һәм шул ук вакытта аңардан дөнья кадәр файдалы нәрсәләр алып калалар, чөнки анда төп образ — Муса абыйлары бит һәм китапта ул үзенең бөтен батырлыгы-матурлыгы белән тасвирланган. Повестьта Мусаны ул төрле хәлләрендә күрә. Аның «судан утка, уттан суга» (китапның бер главасы да шулай атала) ташланып, корычтай чыныгуын күрә анда яшь укучы. Муса — сугышчы, Муса — журналист, Муса — шагыйрь, Муса — яраланганнан соң әсирлектә җәфа чигүче... Ләкин бөек рухи көчен берни сындыра алмый аның; көчле агитатор һәм оста конспиратор Муса шундый кыен шартларда да дошманга каршы аяусыз көрәшче булып кала. Ул үзе болай вакыт-вакыт бик тыныч кебек күренә, әмма аның эчендә «океан дулкыннары кебек көчле хис кайнавын, уйларының давыл кебек айкалуын сизү» кыен түгел. Батыр йөрәкле, олы җанлы Муса, тормышны үлеп яратучы нечкә күңелле шагыйрь Муса үлемгә нәфрәт белән карый, гомуми бөек максат хакына, якын дуслары хакына үзен корбан итүгә һәрвакыт әзер тора. Ә Муса кайда гына, нинди генә шартларда булмасын, андый дусларны бик күп таба, үзенә җәлеп итә, гашыйк итә — шундый тылсымлы көч бар аңарда, һәм повестьта аның бу сыйфаты да җитәрлек чагылган.

Китап кайбер кимчелекләрдән дә азат түгел, әлбәттә. Гомумән алганда җиңел, ачык тел белән язылган булса да, урыны-урыны белән кытыршы җөмләләр дә очраштыргалый. («Кыска гына исәнләштеләр», «Тыныч бөеклекне артык сүз белән борчыйсы килми», «Зур фронтта артык начар үзгәрешләр тормаса» һ. б.)

Эчтәлегенә кагылышлы кайбер урыннары да беркадәр уйландырмый калмый. Мәсәлән, әсирлектә Мусага турыдан-туры Ватанга хыянәт эшләргә тәкъдим итәләр. Бу — бәхәслерәк момент. Безгә инде мәгълүм булганы бүтәнчәрәк бугай: башта аның мәшһүр шагыйрь Муса Җәлил икәнлеге ачыла (ә китапта ул һаман «Гумеров» булып йөри), шунда аңа «Идел-Урал» газетасында эшләргә тәкъдим итәләр. Конспирация өчен уңай шарт шул була Мусага һәм ул шунда, үз тирәсенә патриот дусларын туплап, дошман көчен таркатуга юнәлдерелгән киң эш җәеп җибәрә. Мәсьәләнең инде ачык мәгълүм булган шул ягы повестьта ничектер җитәрлек күрсәтелмәгән.

Вил кайбер урыннарда, яшенә, балалыгына хас булмаганча, бик олы акыллы итебрәк күрсәтелгән

һәм бу аның, образ буларак, ышандыру көчен беркадәр киметми калмый. Аның барлык төп характерын, әсәрдә башкарган эшләрен, төрле мажаралы вакыйгаларда катнашуын һ. б. тулы килеш саклаган хәлдә, аны кирәгеннән артык «акыллы баш» итмичә, балалык психологиясенә, уй-фикер дәрәҗәсенә зыян китермичә сурәтләгәндә тагын да уңышлырак образ булып кабул ителер иде.

Ә менә бүтәнчәрәк характердагы кайбер күренешләр турында авторга мондый гаепләрне ташлау урынсыз булыр дип уйлыйм. Мәсәлән, Мусаның Розенберг белән политик бәхәсе, ихтимал, андый ук төстә булмагандыр, реаль күзлектән караганда мона ышандыруы да жиңел түгел. Әмма художникның бу очракта, ике идеология бәрелешен күз алдында тотып, бәхәстәге диалогларны китерүен аклап була, чөнки бу Мусаны шагыйрь буларак кына түгел, бәлки аның коммунист, патриот булуын да тулырак характерлауга хезмәт итә.

Өстән генә караганда, Берлин рестораныңда Мусаның Шәфи Алмаз белән очрашуы да чынлыкта булмагандыр, яки ул очрашу бүтән урында яки бүтәнчәрәк булгандыр, дигән фикер тууы мөмкин. Әмма повестьтагы вакыйгалар агышы мондый шикләнүнең үзен дә шик астына ала бугай. Чөнки анда тагын әсәрдә мәгълүм роль уйный торган майор Штраус, тагын легион, тагын безнең Вил — Вильгельм — Әхмәт телгә алына һәм шуларга бик җитди реаль вакыйгалар бәйләнеп китә. Аларны, шулай ук, мондый характердагы әсәрдә кулланылуы мөмкин булган алымнар дип карарга ярый.

Ә гомумән «Муса абый» повесте — безнең балалар әдәбиятының уңышлы әсәрләреннән берсе. Ул яшь укучыларыбызның кулыннан төшми торгандыр, аны алар яратып укыйлардыр һәм әсәр аларда батырлык, матурлык, тапкырлык сыйфатлары тәрбияләүдә яхшы йогынты ясый торгандыр дип уйлыйм.

Муса турында моңача иҗат ителгән опера һәм пьесаларга, истәлекләр һәм монографияләргә, картина һәм поэмаларга бу балалар повестеның да өстәлүе — куанычлы вакыйга. Ә тиздән безне тагын да яңа бер шатлыклы вакыйга көтә: зур шагыйрьләребездән Шәйхи Маннур Муса Җәлил турында киң полотнолы роман төгәлләде. Герой-шагыйрь Муса Җәлил әнә шулай, торган саен, олы әдәби образ булып та әверелә һәм тормышта, әдәбият-сәнгатьтә дә мәңгеләшә бара. Зур көрәшебездә, бөек максатка бару юлыбызда ул шулай безнең алдынгы сафларыбызда атлый.

*Газиз Иделле*

# ШИГЫРЬ ТӨЗЕЛЕШЕ ТУРЫНДА ҖИТДИ ХЕЗМӘТ

Күренекле галимебез Хатип Госманның татар шигырь төзелешен тикшерүгә багышланган китабы[1] басылып чыкты. Ул моңа кадәр дә журналларда бастырган мәкаләләрендә бу мәсьәләнең бик үзенчәлекле якларын тотып алу сәләтен күрсәткән иде. Ләкин алар әле аерым күзәтүләрдән узмый иде. Китап исә үз алдына гомумиләштерү, мәсьәләнең асылын ачу, принцибын билгеләү бурычын куйган. Шунлыктан фикерләр биредә бик ачык төс алган.

Барыннан да бигрәк, автор татар шигырьләрен ритмик структурасы ягыннан, ягъни ритм тудыручы төп чараларга карап, ике зур төркемгә бүлә һәм шуларның беренчесен **халык шигыре**, икенчесен **классик шигырь** дип атый. Халык шигыре дигәнендә ритм, башлыча, цезураларның билгеле бер тәртиптә урнашуыннан килеп чыга, бу тәртип үзгәрсә, ритмик яңгыраш та үзгәрә. Шулай итеп, бу шигырьнең үз эчендә генә дә бик күп вариация булырга мөмкин. Классик шигырь дигәнендә сүзләр һәрвакытта да ике цезура арасына гына сыеп бетми, пауза ясаласы урынга килеп утырган очраклары да бик күп була. Икенче төрле әйткәндә, сүз киселеп, аның бер өлеше тынышның алгы ягында, икенчесе арткы ягында кала, нәтиҗәдә пауза тәртибе бозыла. Бу очракта инде ритм башка чара ярдәмендә — ачык иҗекләрнең, ягъни сузык авазга беткән иҗекләрнең, горизонталь һәм вертикаль тәртиптә симметрия булып тезелүеннән килеп чыга. Ритм тудыручы андый иҗекләрне автор ритмик ачык иҗекләр дип атый. Кайвакытта берүк әсәрдә шушы чараларның икесе дә, ягъни паузалар да, ачык иҗекләр дә берләшергә мөмкин. Монда ике бизәк бергә кушыла дигән сүз.

Болардан аеруча икенче төр, ягъни классик шигырь мәсьәләсе күп бәхәсләр кузгатканлыктан, автор да, билгеле, төп игътибарын классик шигырьне анализлауга юнәлдергән. Иң әүвәл, Х. Госман «Классик шигырь төзелеше кайдан килеп чыккан?» дигән сорау куя да, гарәптән дип раслаучылар[2] белән гыйльми полемикага кереп, аның төрки теленең үз җирлегендә туганлыгын исбатлый. Моның өчен ул төрки халыкларының фәндә мәгълүм булган иң борынгы язма истәлекләренә, фольклорына мөрәҗәгать итә һәм, Н. Исәнбәт кебек үк, классик шигырь халыкның борынгы үз мәкальләреннән үсеп чыккан дигән нәтиҗәгә килә. Һәм галимнең бу фикере дәлилле, төпле, гыйльми нигезле.

---

[1] Хатип Госман. Татар шигыре (тарихи күзәтү). Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1964 ел. 4000 данә. Бәясе 28 тиен.

[2] Хамраев М. Х. Основы тюркского стихосложения. Алма-Ата, 1963. Ә. Исхак. Тукайның шигъри осталыгы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1963.

Кузгатылган мәсьәлә буенча фәнни дөрес карашка килүнең ике җәһәттән теоретик-практик әһәмияте бар. Беренчедән, гарәп теленең нормаларын төрки теленә тагарга мөмкин булмаган кебек, озын-кыска иҗекләргә корылган гарәп шигырь төзелеше кануннарын да төрки шигыренә күчерергә мөмкин булмаганлыгы исбатлана, ялгыш карашның нигезе җимерелә һәм хакыйкать үз көчен ала. Икенчедән, әгәр М. Х. Хамраев төрки телләргә гарәп шигырь системасы ислам дине белән, Ә. Исхак татар әдәбиятына Г. Тукай иҗаты белән кертелде дип расласа, Х. Госман классик шигырьнең әле ислам белән бәйләнеш булмаган чакта ук туа башлавын күрсәтә һәм, шулай итеп, бу системаның халык теле, иҗаты җирлегендәге бик ерак традициясен ача, икенче төрле әйткәндә, классик шигырь системасының милли җирлеге, туфрагы бик ныклы булуын, гасырлар буенча төзелә килүен ышандырырлык итеп аңлата.

Ярый, классик шигырьнең туып үскән ватаны ачыкланды, ди. Ә соң, шундагы ачык иҗекнең ритмны оештырудагы роле, йогынтысы нәрсә белән исбатлана? Ритмик ачык иҗекне, ритмик буыннар чиген ничек танырга, ничек... тотып карарга? Бу хакта методик күрсәтмәләр бармы? Әлбәттә, теләсә нинди шигырь системасындагы кебек үк, монда да иң әүвәл эстетик сизгерлек, күңел белән тою сәләте, ритм хисе кирәк. Х. Госман моңа өстәп тагын башка билгеләрне күрсәтә. Мәсәлән, ритмның ачык яки ябык иҗек килүенә битараф карамаганлыгы шигырь юлында иҗекләрнең аваз бүлешүендә дә күренә. Әйтик, Тукайның «Туган тел» шигыреннән «Әткәм-әнкәмнең теле»... дигән сүзләр «әт-кә-мән-кәм-нең...» дип укыла икән, монда «әткәм» сүзендәге «м» авазы, бары тик ритм таләбе белән генә, «кәм» иҗеген «кә»гә калдырып, аны ачып җибәрү өчен генә икенче сүзгә күчә. Кыскасы, моны шигырь таләп итә. Икенче билге — ритмик ачык иҗекнең басымсыз булуы. Димәк, ритмик ачык иҗекне басымсыз иҗектән эзләргә кирәк икән. Билгеле, тагын да тирәнгәрәк төшеп тикшергәндә болардан да ныклырак, ачыграк билгеләр табылырга мөмкин. Күренеп тора, ритмик буыннар чиген билгеләүдә формаль күрсәткечләрнең роле ачылып бетмәгән әле. Минемчә, монда ярым паузаның да ролен бөтенләй үк кире кагып булмый. Классик шигырьдә ул, ритм ясаучы төп чара булып хезмәт итмәсә дә, ритмик буын чикләрен, аның башын һәм ахырын, икенче төрле әйткәндә, стопаны дөрес билгеләүгә ишарә кыла торгандыр.

Классик шигырьдәге башка чаралар: рифма, эчке рифма, аллитерация-ассонанс, строфа, поэтик синтаксис (анафора, эпифора, ялгау, рефрен) һәм башкалар турыдантуры ритмикага, шигырь төзелеше системасына карамыйлар. Ләкин Х. Госман һәр конкрет очракта аларның шигырь аһәңенә йогынты ясавын, бер үк художестволы бизәкнең күп функция үтәп килүен күрсәтеп бара. Х. Госман шигырьне аның нечкәлекләрен тирән аңлаган галим буларак та, сизгер күңелле шагыйрь буларак та тикшерә. Моңа тагын галим теленең образлылыгы, җанлылыгы, төгәллеге һәм ачыклыгы килеп өстәлә.

Мәсьәләгә яңача якын килгәндә, яңа төшенчәләрне аңлатучы үзенчәлекле терминнар тууы табигый хәл. Х. Госман китабында да шактый алар. Күбесе уңышлы (ритмик буын, строфа калыбы, иҗекләрнең аваз бүлешүе һ. б.). Тик менә татар шигыренең ике төп төрен, аларның принципларын аңлатучы **«ритмик ачык иҗекләр»** һәм **«буынара ачыклыклары»** дигән терминнарның гына бер-берсенә охшаш булуы, хәтта тегендә дә, монда да бер үк «ачык» сүзенең кабатлануы, бер-береннән аерылып тормавы гына бик әйбәт түгел. Яңгырашлары белән үк аерылып тормагач, бу терминнар очраган саен аларның мәгънәсе хакында уйланып торырга туры килә.

Китапның төп әһәмияте нәрсәдә? Беренчедән, ул проблематик темага язылган. Ләкин автор мәсьәләне күтәреп кенә калмаган, аны фәнни,

нигезле рәвештә хәл итүгә ирешкән. Ул татар шигырь төзелешенең объектив закончалыгын ачкан, нигез принципларын билгеләгән.

Икенчедән, гәрчә китапның исеме татар шигыре турында гына фикер йөртүне вәгъдә итсә дә, җисеме бөтен төрки халыклары поэзиясен иңләп ала, нәтиҗәләр шуңа нигезләнеп ясала. Шулай итеп, әлеге закончалыклар һәм принциплар бер татар шигыренә генә карамый, алар төрки телдә сөйләүче халыкларның: азербайҗан, төркмән, үзбәк, кыргыз, казакъ, башкорт, уйгурларның шигъри төзелешенә дә хас. Димәк, китапның әһәмияте татар әдәбияты белән генә чикләнми.

Х. Госман төп теманы ачу процессында, юл уңаенда гына, яңадан яңа проблемалар куеп бара, алга таба эзләнүләрнең юнәлешен билгеләп уза. Аларны да әллә кем килеп хәл итеп бирмәс. Х. Госман татар шигыренең башка үзенчәлекләрен дә тикшерер һәм ачар дип ышанасы килә.

*Ф. ХАТИПОВ*

## *Латыш халык мәзәкләре*

### АЛДАШМАУ

— Синең кебек кечкенә чакта, улым, мин беркайчан да алдашмый идем.

— Ә кайчан алдаша башладың син, эти?

### СӘЕР ҖАВАП

— Әгәр мин вәгъдә иткән акчаны сорап күрше керсә, син аңа: «Акча шкафка бикләнгән, әтием урамга чыгып китте, ачкыч аңарда», — дип әйтерсең, улым.

Күрше килеп керә дә малайдан: «Әтиең кайда?» — дип сорый. Аптырап һәм каушап калган бала аңа бик сәер җавап бирә:

— Акча урамга чыгып китте, ачкыч акча белән йөри, эти шкафка бикләнгән.

### ТАВЫК ҺӘМ ЙОМЫРКА ТУРЫНДА

— Безнең тавыгыбыз, улым, йомырка салмый башлады, без аны суярбыз ахры.

— Ә суйгач ул, әни, йомырка сала башлаячакмы?

### НИК КӨЛӘСЕҢ?

Бер малай суга төшә. Өч ир кеше аңа бау ташлыйлар. Үзен ярга өстерәп чыгаргач, бала шаркылдап көлә башлый.

— Ник көләсең?

— Шуны уйлап көләм: әгәр мин бауның очын кулымнан ычкындырган булсам, өчегез берьюлы егылыр идегез бит.

### ЮГАЛГАН БӘРӘН

Бер малай болында сарык көткән. Көндез бер бәрәне югалгач, кичен ул йорттан-йортка кереп шуны эзләп йөри икән.

— Бәрәнең нинди иде? — дип сорыйлар малайдан.

— Былтыргы бәрән, тәкәбезнең сеңелесе, әби сарыгыбызның кызы иде.

### МАЛАЙЛАР ҺӘМ КУЯН

Ике малай болында уйныйлар. Куаклар арасыннан кинәт бер куян сикереп чыга.

— Янка! Куян ник куак төбендә утырган?

— Чөнки куак башына менеп утыра алмый, ул бит сиңа карга түгел.

# «ИЗГЕ ХӘЗРӘТ ТАРИХЫ»

Юморист һәм сатирик Гамил Афзал поэзиягә килеп кергән елларында ук укучыларның күңелен яулап алды. Аның һәрбер яңа шигыре диярлек безне нииндидер көтелмәгән ягы белән гаҗәпләндерүенә, шатландыруына өйрәнеп үк киттек бугай. Шагыйрьнең горур һәм хөр күңелле конюх Сабирҗаны, ялкау кызлары, Әсмабикәсе, тәвәккәл әбисе, чүлмәк ясаучы малайлары, өй саен эчеп йөрүче колхоз бригадиры, үзе яучы булып сөйләшкән гашыйк егете һ. б., һ. б. тип-характерлары онытылырлык түгелләр. Г. Афзалның андый шигырьләрен укыганда, рәхәтләнеп көләсең. Ул шигырьләрдә искелек калдыкларыннан арыну шатлыгы яңгырый, бүгенге совет кешеләренең күтәренке рухы чагыла.

Әмма соңгы елларда Г. Афзалның «көлке капчыгы» бушый башламадымы икән, дип сорасаң да урыны бар шикелле. Эш нәрсәдә? Әллә татар поэзиясе алга китеп, Г Афзал безне бик шаккатыра алмый башладымы? Бәлки аңа тематикасын киңәйтергә, яңартырга кирәктер? Әллә шагыйрь яңа эзләнүләр чоры кичерәме, яңа темаларны яңача ачарга тырышамы?

Татар поэзиясенең соңгы елларда күзгә күренеп үсә баруы да дөрес: хәзер һәркайсы шагыйрьнең диярлек тематик колачын бик киң җәйгән чагы. Әмма шуны әйтергә кирәк: Г. Афзал да иҗади эзләнүләр юлыннан, үсү юлыннан бара.

Белинский поэзиянең иң югары жанры итеп драманы атый. Ә Г. Афзалның һәрбер көлкеле шигыре кечкенә бер сәхнә әсәрен хәтерләтә бит. Моңарчы аның көлкеле шигырьләрендә ике, өч, дүрт тип-персонаж катнаша иде. (Шул ук «Әсмабикә җаным, ахирәт», «Тәвәккәл әби», «Дон-Жуан Ногманнар»ны гына искә алыйк.)

Шагыйрьнең яңа җыентыгының [1] «Минем көзге» дип аталган бүлегендә исә «тулы метражлы» комик драма булырдай вакыйга бар. Ул — «Изге хәзрәт тарихы». Шагыйрь поэтик колачын киңәйтеп җибәргән, сатира көчен һич тә югалтмыйча, җитди темага зур күләмле җитди әсәр язган. Автор дин тәгълиматына оста пародия тудырган, динчеләрнең азгынлыгын, аларның фәкать ашка, акчага табынуларын оста сурәтләгән, аларның эчке дөньясын тышка әйләндереп күрсәтү өчен оста алым тапкан. Әсәр «Соңгы мулланың хикәясе» дип тәкъдим ителә. Мулла үлгән, имеш тә, теге дөньяда җавап бирә... Бу мулла — бүген дә әле безгә очраштыргалый торган надан, алдакчы, ялагай муллаларның берсе. Каршына гөрзи тотып килүчеләр турында ул «Нөнкир иптәш белән Мөнкир иптәш» дип кенә сайрый.

И ходаем, гөнаһ как булмасын,
Бер догa да белмим икән мин,— ди ул.

Малай чакта бераз «әлпи-тиси» кимергән, кукай-фәлән урлаштырган; егет булгач өйләнмичә генә «сөю» ягын чамалаган; гаилә аның өчен «камыт»; комсомолда дин сүгеп йөргән; аннан «файда» чыгара алмагач, юлын алмаштырып, «кесә» өчен генә яши башлаган. Бер гүзәлгә өмет саклап йөргән җиреннән...

Сыра сатып торган юан затка
Өйләндем дә куйдым, егетләр.
Патефон уйнатып туй ясадык,
Квартир аныкы,
Тормыш көйләнде.
Тик хәзергә чаклы аңламадым:
Әллә мин,
Әллә ул өйләнде,—

ди ул.

[1] Гамил Афзал. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты, 1964 ел.

Хезмәттә ул зам да булган, пом да, бухгалтер да, буфетчы да; начальникларыннан поза күчергән, корсак, мыек үстергән, «Уйлап-нитеп тормый, кем ни кушса шунда йөгергән». Корсак шиңеп, җилкә югара башлагач, аны ходай үзе килеп «коткара».

...Начармыни «изге хәзрәт» булу
Синең кебек каткан кишергә!

Мулланың «теге дөнья»да җавап бирүләре исереп саташу галәмәте булып чыга. Әсәрне көлә-көлә укыйсың. Шагыйрь диннең мәгънәсезлеген фаш итә.

«Минем көзге» бүлегендәге «Хуҗа Насретдинның тәрҗемәи хәле», «Асыл кош», «Әкрен генә барган көйгә» исемле шигырьләрдә дә Гамил Афзалның үткен каләмен таныйсың.

«Могҗизалар чоры» дигән беренче бүлектәге «Җиңү яулау җиңел түгел», «Кеше күңеле», «Җилгә каршы» исемле шигырьләрдә зур хис, тирән уйланулар бар.

«Күңел тибрәнгәндә» бүлегендәге «Татарстан таңнары» шигыре үзенең композиторын көтә булса кирәк. Туган яклар, туган җирләргә багышланган бу шигырь халык җырларына хас саф, җылы моң белән сугарылган. «Тегүче кызлар җыры», «Шәфкать нурында» шигырьләре дә көй сорыйлар.

«Кайгы белән шатлык көрәшкән», «Уйсу үзәннәрдә әнгер-меңгер» шигырьләрендә шагыйрьнең күңел эченнән генә уйлану-моңланулары чагыла. Әмма «Тал иелә» шигырендә көтмәгәндә нинди дер төшенкелек сыман бер мотив моңны ялганга чыгара. Монда хис олылыгы җитми:

Ил диеп тә,
Җил диеп тә
Толымнар туза икән,
Яшь гомер уза икән...—

ди шагыйрь үкенү кебек бер хис белән. Ил диеп узган яшь гомер үкендерми ул, горурландыра.

Җыентыкта «Ленин варислары», «Йөрәк сызлый» исемле зур политик темаларга багышланган шигырьләр бар. Алар киң караш, зур хис, кайнар гражданлык пафосы белән язылганнар. Ләкин алардагы гомумилек, абстракт образлар шигырьнең тәэсир көчен йомшарта.

Г. Афзалның иң көчле ягы юморсатирада. Бу өлкә — аның үз стихиясе.

Шагыйрьнең яңа темаларга язган яңа әсәрләрен көтәбез, аңа яңа уңышлар телибез.

*М. Рафиков*

*Галимҗан Ибраһимов*

# НӘШРИЯТКА ХАТЛАР

*Соңгы елларда Г. Ибраһимовның туганнарына, каләмдәш дусларына язган байтак хатлары матбугатта игълан ителде. Ул хатларның язучы иҗатын һәм тормышын өйрәнүдә әһәмиятләре шактый зур. Г. Ибраһимовның тормыш юлына һәм иҗатына караган һәртөрле материаллар әледән-әле табыла торалар. Язучының бу санда бирелгән хатлары, телеграммалары да беренче тапкыр дөнья күрәләр. Ул хатлар әдәбият һәм сәнгатьнең Үзәк дәүләт архивында (Мәскәүдә) саклангannар (613 фонд[1], 1 опись, саклау берәмлеге 4850, 1—62 битләр).*

*Г. Ибраһимовның хатлары бу фондка ничек килеп эләккән соң?*

*Мәскәүдә, Дәүләт матур әдәбият нәшриятында утызынчы елларда Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» (1931) «Казакъ кызы» (1934), «Татар хатыны ниләр күрми» (1935 елда) кебек әсәрләре Гайшә Шәрипова тәрҗемәсендә русча басылып чыга. «Безнең көннәр» романын чыгару да күздә тотыла. Г. Ибраһимов үзенең әсәрләре басылган вакытта Дәүләт матур әдәбият редакциясе белән хат алыша, тыгыз бәйләнеш тота.*

*Бу хатлар, телеграммалар Г. Ибраһимов әсәрләренең русча басылу тарихын ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Язучының үз әсәрләренең тәрҗемәләренә мөнәсәбәтен ачыклау, тәрҗемә теориясе буенча карашлары, тәрҗемә принциплары турында фикер йөртүе ягыннан да әһәмиятле алар. Г. Ибраһимов автор рөхсәтеннән тыш башкарыла торган һәртөрле тупас «эшкәртү»ләргә, бозуларга коммунистик принципиальлек белән каршы чыга, оригиналның рухын һәм эчтәлеген төгәл бирә торган тәрҗемә өчен сугышчан төстә көрәшә. Нәшрият эчендәге волокитаны, бюрократизмны тәнкыйть итә.*

*Г. Ибраһимов хатларын язучының әдәби мирасын туплау комиссиясенә һәм журнал редакциясенә Нил Юзиев тапшырды. Хатларга язылган искәрмәләрне дә ул төзеде. Хатлар ачың тәрҗемәсендә бирелә.*

## 1

ГИХЛ.

19 октябрь, 1932 ел, Ялта.

СССР халыкларының иҗат редакциясе. Әхмәт Яркиев иптәш [1]!

Сездә 1933 өчен татар совет әдәбиятыннан тәрҗемәләр арасына миннән (10 табак) «Татар хатыны...» [2] кертергә уйлана дип ишеттем.

Әгәр кертелсә, «Татар хатыны...» түгел, «Казакъ кызы» романы бирелергә тиеш. Моны миннән тәрҗемәсен бик сорыйлар. Царизмның колония сәясәтен ачу ягыннан да әһәмияте бар. Шәрыкны өйрәнүгә материал күп. Кыскасы, миннән кертсәгез, әлбәттә, «Казакъ кызы» керер. Минем фикерем шул. Җавап көтәм.

Ком. сәлам: *Галимҗан Ибраһимов.*

---

Бу хатны Галимҗан Ибраһимов Ялтадан Дәүләт матур әдәбият нәшриятының СССР халыклары иҗаты редакциясенә 1932 елның 19 октябрендә язып җибәргән. Ул, ачык хат рәвешендә, язучының үз кулы белән татарча язылган.

[1] Хат шагыйрь Әхмәт Ерикәйгә адресланган. Ә. Ерикәй бу вакытта нәшрият редакциясендә эшли. «Яркиев» дип ялгыш язылган.

[2] «Татар хатыны ниләр күрми» повесте. Сүз нәшриятның 1933 елгы матур әдәбият китаплары басу планы турында бара.

---

[1] 613 фонд — Дәүләт матур әдәбият нәшрияты, ягъни ГИХЛ (Государственное издательство художественной литературы) фонды. Архивның бу фондындагы 4850 берәмлекле папкага Г. Ибраһимовның ГИХЛ редакторларына язган хатлары, телеграммалары һәм әсәрләренең русча басмалары чыгуга бәйләнешле төрле материаллар тупланган.

## 2

15 апрель, 1933 ел, Ялта.

Дәүләт матур әдәбият нәшриятына, СССР халыклары иҗаты редакциясенә.

Иптәшләр!

Минем романның («Казакъ кызы») 1933 елгы планга[1] кертелүе турында мин сездән ике тапкыр хәбәр алган идем.

Бүген очраклы рәвештә бер бик сәер детальне белеп алдым: янәсе, авыр тәрҗемә ителә торган бу роман тәрҗемә өчен карт журналист Ф. Кәримовка[2] бирелгән икән. Мин үзем аны яхшы беләм. Ул, шиксез, кайчандыр, Октябрьга кадәр, зур сүз остасы иде. Ләкин ул бөтен гомере буена тик **төрки-татар жаргонында гына**[3] язды. Аның беркайда да, беркайчан да рус телендә бер китап та, хәтта мәкалә дә язганы булмады. Никадәр ачы булса да, мин турыдан-туры әйтергә тиеш: ул «Казакъ кызы»н тәрҗемә итә алмаячак!!

Бу эшне рус **совет** әдәби телен **үзләштерү** шартларында тәрбияләнгән иптәшләргә тапшырырга кирәк.

Мин, автор хокукыннан файдаланып, бу эшкә катнашырга мәҗбүр булдым. Иптәшләр, әгәр сез чынлап бу әсәрне аңа тапшырган булсагыз, мин, автор буларак, бу эшне аннулировать итүегезне үтенәм. Мин болай да китапларымның рус телендә канәгатьләнмәслек редакциядә чыгулары белән артык газапланган инде. Тәҗрибәле тәрҗемәчегә тапшырырга кирәк.

Җавап көтәм.

Җавап салу өчен открытка җибәрәм.

Ком. сәлам белән: «Казакъ кызы» романының

авторы *Галимҗан Ибраһимов.*

---

**Бу хат Г. Ибраһимов тарафыннан рус телендә язылган.**

**[1] ГИХЛ планына кертелүе турында сүз бара.**

**[2] Язучы, журналист, тарихчы, педагог Фатих Кәрими (1870—1937).**

**[3] «Жаргон» дигән атаманы бу урында язучы «тел, сөйләм» мәгънәсендә, революциягә кадәрге татар теле мәгънәсендә куллана. Фикеренә басым ясар өчен, Г. Ибраһимов аерым сүзләрнең астына бер яки ике тапкыр сызып та куйган.**

## 3

26 июль, 1933 ел, Ялта.

Иптәш Черняк!

«Казакъ кызы» тәрҗемәсенең бер өлешен (15 бит) алдым. Сезгә бер үтенеч: басарга **тапшырмый торыгыз.** Тәрҗемә дүрт аякка да аксый. Тагын бер сәер хәл: ни өчен кереш сүзне алып ташладыгыз? Ул чиктән тыш кирәк. Ләкин монысы әле вак нәрсә. Иң әһәмиятлесе шул: тәрҗемә шундый булып чыккан, әгәр ул әлеге көенчә басылса, авторны да, сезне дә кыйнаячаклар.

Җентекләп язылган хат — ике көннән соң.

*Г. Ибраһимов.*

---

**Бу хатны Г. Ибраһимов рус телендә язган. Ачык хатның беренче битенә түбәндәге адрес язылган: «Москва, ул. 25 Октября (Б. Никольская), д № 10, ГИХЛ, редакцию творчества нар. СССР.**

**тов. Чернякову».**

**Г. Ибраһимов Черняков дип бу очракта дөрес язмый, аның дөресе — Черняк. Черняк Б. Х. — ГИХЛның грузин, татар, еврей, башкорт әдәбиятлары буенча редакторы.**

4

30 июль, 1933 ел, Ялта.

Мәскәү, ГИХЛ, правление.
Күчермәсе: СССР халыклары иҗаты редакциясенә.

«Казакъ кызы» романының тәрҗемәсе һәм Фрелихның[1] эшкәртүе һич тә канәгатьләнерлек түгел. Басарга ярамаслык тупас хаталар һәм бозулар күп. Автор буларак, тәрҗемәне бастыруга катгый рәвештә каршы киләм һәм наборга төшерми торуыгызны үтенәм. Хат аша һәм үзем Мәскәүгә баргач җентекләп аңлатырмын.

*Ибраһимов.*

---

Г. Ибраһимов бу телеграмманы ике адрес белән җибәргән. Архивта телеграмма кәгазендә саклана, рус телендә.

[1] Фрелих О. Н. — «Казакъ кызы» романын әдәби эшкәртүче итеп билгеләнгән кинорежиссер.

5

28 август, 1933 ел, Ялта.
Мисхор, «Горное солнце» санаторие.

ГИХЛ, правление.
Иптәш Накоряковка[1].

Иптәш Накоряков!

Минем «Казакъ кызы» романын СССР халыклары иҗаты линиясе буенча тәрҗемә итү турындагы Сезнең хатыгызны **(сезнең № 4444)** алдым.

Сез Мәскәүгә килүемне тизләтүне сорыйсыз. Мин үзем Мәскәүдә август урталарында булырмын дип уйлаган идем. Ләкин, авыруымның көчәеп китүе сәбәпле, вакытлыча санатория шартларына күчәргә мәҗбүр булдым.

Мәскәүгә 18 сентябрьдән дә соңга калмыйча барырмын дип өметләнәм.

Ком. сәлам белән: *Г. Ибраһимов.*

---

[1] Накоряков Н. Н. — Дәүләт матур әдәбият нәшриятының директоры. Хәзер пенсиядә.

6

Кореиздан телеграмма.
3 сентябрь, 1933 ел.

Мәскәү, ГИХЛ, Накоряковка!
Күчермәсе: Рябининага[1].

Милли секторның сәер ультиматив хатын алдым. Каты авыруымның көчәюе сәбәпле, хәзер санаториядәмен. Сентябрь ахырларында Мәскәүдә булачакмын. Мин барганга кадәр кулъязмамны **һич ничек тә** типографиягә төшермәгез!

*Ибраһимов.*

---

[1] Рябинина А. П. — Дәүләт матур әдәбият нәшриятының милли секторы мөдире. Ул бу урында Ватан сугышыннан соң да эшләде. Соңгы елларда пенсиядә.

## 7

ВКП(б) Үзәк Комитетына, иптәш Кирпотинга [1].
Күчермәләре: Совет язучылары союзының оргкомитеты
иптәш Фадеевка [2].
ГИХЛ, иптәш Накоряковка.
Милли сектор — иптәш Рябининага.

1933 елның 4 августында ВКП(б) Үзәк Комитетына иптәш Стецкийга [3] дөрес тәрҗемә ителмәгән «Казакъ кызы» исемле тарихи романымны (революциягә кадәрге Казагыстан тормышыннан) басуны туктатырга үтенеп һәм бу мәсьәләдә ГИХЛ милли секторының дөрес эш итмәвен күрсәтеп телеграмма җибәргән идем.

ГИХЛ 10 августта (33 ел) мин Мәскәүгә килгәнчегә кадәр минем китапның наборга тапшырылмаячагы турында телеграф аша хәбәр итте. Соңга таба ГИХЛның милли секторы үзенең 15 августта № 4444 хатында: 1) аның хәрәкәтләре нәрсәдә дөрес түгеллекне аңлатуны, 2) тәрҗемәдәге хаталарны конкрет рәвештә күрсәтүне сорый.

Хәзерге чорда партиянең төп лозунгларыннан берсе булып бөтен өлкәләрдә дә эшнең сыйфаты мәсьәләсе исәпләнелә һәм шуның өчен дә мин ГИХЛның югарыда күрсәтелгән моментлар буенча соравын канәгатьләндерүне үземнең бурычым саныйм. ГИХЛның милли секторының әлеге мәсьәләдә дөрес булмаган хәрәкәтләрен нәрсәдә күрәм соң мин?

Мәсьәлә шулай тора: 1933 елның апрель аенда, минем «Казакъ кызы» романының бер карт татар журналистына [4] тәрҗемәгә бирелүе турында читтән очраклы рәвештә генә ишетәм. Моңа мин бик гаҗәпләндем. Чөнки әлеге кеше татарчадан рус теленә тәрҗемә квалификациясен бөтенләй үзләштермәгән. Ул үз гомерендә рус телендә хәтта бер мәкалә дә язып карамаган. Югарыда күрсәтелгән һәм тулысынча табигый сәбәпкә таянып, аның белән договорны юкка чыгаруны һәм квалификацияле тәрҗемәчегә тапшыруны сорап (андыйлар ГИХЛ хезмәткәрләре арасында да бар), милли секторга язма рәвештә мөрәҗәгать иттем. Моңа иптәш Черняк [5] «тәрҗемәче белән шулай ук Олих Фрелих та эшләячәк» дип җавап бирде. Бу хәл мине тагын да ныграк аптырашта калдырды. Отставкадагы кинорежиссер, матур әдәбият өлкәсендә бернинди тәҗрибәсе (квалификациясе) булмаган һәм татар телен бөтенләй белмәгән гражданин Фрелих ничек итеп романны, өстәвенә шундый катлаулы, авыр тәрҗемә ителә торган әйберне, татарчадан русчага тәрҗемә итсен (яки «эшкәртсен») икән! Мин кабат каршы килдем, ләкин нәтиҗәсе булмады. Милли сектор җавап бирмәде.

Ниһаять, 16 июльдә шушы тәрҗемәнең 15 битен һәм редактор иптәш Черякның тәрҗемә белән бергә җибәргән хатын алдым. Миңа барысы да ачыкланып китте. Черняк төп-төгәл түбәндәгечә яза: «Август башларында без романны наборга тапшырырга җыенабыз. Тышлыкта «Татарчадан тәрҗемә, О. Н. Фрелих эшкәртүендә (подстрочник буенча)» дип куелачак». Гражданин Фрелих милли сектор тарафыннан минем китапны эшкәртү өчен чакырылган икән ләбаса (!) Бу чиктән тыш сәер хәл. Минем бервакытта да үземнең романны эшкәртергә ризалык биргәнем юк. Әгәр инде эшкәртү кирәк дип табыла икән, аны һич тә Фрелихка түгел, ә лаеклы квалификацияле кешегә — марксистик-ленинчыл идеологиядә чыныккан һәм рус телен дә, татар телен дә белгән кешегә тапшырырга кирәк иде. Автор ризалыгыннан тыш эшкәртү методын бу очракта һич ярый торган эш дип санамыйм. Шундый «эшкәртү»не Фрелихка тапшыру исә бөтенләй сару кайнатырлык. «Эшкәртү» нәтиҗәсендә дөрес булмаган һәм бозылган тәрҗемә килеп чыккан.

1933 елның 30 июлендә телеграф аша түләнгән җавап белән ГИХЛдан мин Мәскәүгә килгәнчегә кадәр китапны наборга тапшыр-

мый тотып торуларын сорадым. Җавапны алты көн көттем һәм кө͏тә-көтә дә ала алмагач, китапны наборга тапшыртмауны үтенеп, ВКП(б) Үзәк Комитетына иптәш Стецкийга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булдым. Милли секторның автор фикере белән исәпләшергә тиешлеге һәм аның телеграммасына җавап бирергә тиешлеге (җитмәсә түләнгән җавап белән) һәркемгә ачык бит. Ә эш башкача килеп чыкты. Милли сектор ВКП(б) ҮКына апелляциядән соң гына җавап бирергә тиеш тапты. (ВКП(б) Үзәк Комитетына апелляцион телеграмма 4/8—33 җибәрелгән, ә ГИХЛның миңа җавабы — 10/8—33).

Гражданин Фрелих «эшкәртүеннән» кайбер мисаллар китерим.

Китапның башында эпиграф итеп шигырь китерелгән. Анда үзенең таулары һәм елгалары белән дала тасвирлана һәм ахырда: шушы дала мине тудырды дип әйтелә. Фрелих эшкәртүендә: «Так гора Аскар — мать моя родная» булып чыккан. Биредә икеләтә хата киткән. 1) Тау түгел, ә дала тудырган һәм 2) тәрҗемәче һәм эшкәртүче аңлаганча аскар сүзе тау исемен аңлатмый. Аскар сүзе «зур» [большое-громадное] дигәнне аңлата, ягъни ул аергыч сүз.

Китапның беренче фразасы: «Казакъның уртача байлыклы, күп адәмле ике ыругсы бар иде», — дип башлана. Үзенең «эшкәртүендә» Фрелих ни өчендер «уртача байлыклы» дигән принципиаль, социаль әһәмияткә ия булган сүзләрне алып ташлап, үзеннән «по соседству кочевали» дигән бөтенләй кирәк булмаган сүзләрне өстәгән. Бу рәвешчә алу китаптагы вакыйгаларның ары табан тасвирлануына бөтенләй каршы килә, чөнки бу ике ыругның күрше булуы мәҗбүри түгел.

Ул «летовка» дигән сүзне куллана: «с летовкой на летовку» һәм киң халык массасына аңлашылмаган бу сүзләрне еш кабатлый.

Оригиналның шул ук беренче битендә кайбер бай кабиләләр үзләрен Чыңгыз нәселеннән киләләр дип данлап, югарыда күрсәтелгән ике кабиләне кыерсыталар, аларның җәйләүләрен, суларын, җирләрен басып алалар, дигән мәгънәне аңлаткан җөмлә бар. Фрелих эшкәртүендә исә бу Чыңгыз кабиләләре «җәйләү һәм су җитмәүлектән җәфа чигүчеләр» булып чыга. Моның белән китаптагы вакыйгаларның бөтен мәгънәсе бозыла. Чөнки романда изелүче кабиләләрнең рус самодержавиесе сатраплары ярдәмендә даладагы бөтен кабиләләр өстеннән властьны үз кулларына яулап алган югары катлам-аристократик Чыңгыз токымнарына каршы алып барган кискен көрәшнең барышы турында сурәтләнә. Фрелих үзенең «эшкәртүендә» бу изүче-хакимнәрне «җәйләү һәм су җитмәүдән интегүчеләргә» әверелдергән.

«Эшкәртү»нең икенче битендә картның ике кабиләнең якынлашырга тиешлеге турында читләтеп кенә алып барган сөйләшүендә дә ышанмаслык буталчыклыклар киткән. Картның «яңа туганлык»ның «дошман йөрәгенә ут салачагы, ә башыннан акылын чыгарачагы» турында әйткән сүзләре аеруча сәер яңгырыйлар. Ә моны гади итеп «сарманнар белән кара-айгырларның кода булып кушылулары дошманның йөрәгенә ут салыр, башыннан акылын алыр» рухында әйтергә кирәк иде.

7 биттә кыз тарафыннан шушы рухта: «Кайбер адәм бар: йөзе булмаса сүзе, акылы белән күңелне ала, гайрәте, ирлеге белән йөрәгеңне тарта» дигән бик гади һәм ачык фикер әйтелә. Фрелих «эшкәртүендә» ничектер сәер килеп чыккан: «Не всем пригожим родиться — так другой сердце потянет к себе умом, обхожденьем, ухваткой мужской своей». Дала кызының шундый ачык һәм гади фикерләрен ни өчен һәм кем өчен шулай тотанаксыз итеп бозарга кирәк булгандыр, һич тә аңлашылмый.

Тагы да мисаллар китереп торуның кирәге юктыр дип уйлыйм, чөнки югарыда китерелгәннәр дә тәрҗемәче һәм эшкәртүче эшенең сыйфаты турында ышандырырлык итеп сөйлиләр. Минем тарафтан карап

чыгылган битләр әнә шундый бик тә уңышсыз, үле сүзләрдән тора. Бу төгәлсезлекләр һәм өстәүләр, автор фикерен чиксез күп бозулар ни өчен кирәктер, һич аңлашылмый. Күрәсең, бу Фрелихча «эшкәртү» дип атала торгандыр инде.

Мондый «эшкәртү»дә автор үзенең китабын бөтенләй таный алмаячак. Шундый хәлдә аны рус совет укучысына тәкъдим итү белән автор килешми, чөнки ул партиянең продукция сыйфаты турындагы директиваларын хыянәтчел төстә онытып, СССР халыклары иҗатын чыгаруның производство планын формаль үтәү йөзеннән сыйфаты начар булган продукция чыгаруны аңлатыр иде һәм шуның өчен автор коммунист буларак романны Фрелих эшкәртүендә тәкъдим ителгән рәвештә чыгару белән килешә алмады.

Моңа кадәр минем хезмәтләремнән дүрт әсәр тәрҗемә ителде һәм басылды (аның өчесе ГИХЛ басмасында). Аларның тәрҗемәләрен мин бик үк алай канәгатьләнерлек дип санамыйм. Минем «Казакъ кызы» тарихи романының Фрелих эшкәртүендәге русча тәрҗемәсе исә тәрҗемә ягыннан чагыштыргысыз түбән тора.

Шуның өчен мин бу китапны шул хәлендә бастыру белән килешә алмыйм.

Автор: *Г. Ибраһимов.*

---

Бу хат русча язылган. Ул машинкада басылган һәм ахырда Г. Ибраһимовның имзасы куелган хәлдә саклана. Язылу вакыты күрсәтелмәгән. Эчтәлегеннән чыгып, бу хатның 1933 елның август-сентябрь айларында язылуын ачыкларга мөмкин.

[1] Машинкада «Киропотин» дип ялгыш басылган. Кирпотин В. Я. — шул вакытта ВКП(б) Үзәк Комитетында эшли, әдәбият белеме галиме.

[2] Язучы Фадеев А. А. (1901—1956) — ул вакытта совет Язучылары союзын оештыру комитетында эшли.

[3] Стецкий А. Н. — шул елларда ВКП(б) Үзәк Комитетының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире. 1915 елдан КПСС члены.

[4] Сүз Фатих Кәрими турында бара.

[5] ГИХЛның редакторы.

[6] Г. Ибраһимовның рус телендә «Тирән тамырлар» (1931), «Табигать балалары» (1928), «Адәмнәр» (1923) әсәрләре басыла. Язучы шулар турында сүз алып бара булса кирәк.

## 8

25 октябрь, [1933][1], Ялта.

Мәскәү, ГИХЛ, милли сектор, Рябининага.

Әйбәт кенә кайтып життем. Саклык кассасындагы хәзерге счетны хәбәр итәм: НР 22855.

6 нчы саклык кассасы. Ялта.

Сәлам белән *Ибраһимов.*

---

Бу телеграмманы Г. Ибраһимов Мәскәүдән Ялтага кайтып житкәч жибәргән булса кирәк. Ул үзенең сентябрь ахырында Мәскәүгә барачагы турында алдагы хатларының берсендә хәбәр иткән иде. Күрәсең, ул Мәскәүгә октябрь урталарыннан соң гына бара алган.

[1] Квадрат жәяләр искәрмәне төзүче тарафыннан, ә гади жәяләр Г. Ибраһимов тарафыннан куелганнар.

## 9

15 ноябрь, 1933 ел, Ялта.

Мәскәү, ГИХЛ, милли секторга.

Рябинина! Минем романның тәрҗемәсе ничек баруы турында телеграф аша хәбәр итүегезне сорыйм.

*Ибраһимов.*

---

Г. Ибраһимовның бу телеграммасы телеграмма кәгазендә саклана.

10

26 ноябрь, 1933 ел, Ялта.

ГИХЛ, милли секторга.

Тарсис[1] имзасы куелган телеграмманы алдым. Ул «тәрҗемә эшенең барышы турында хәбәр итегез», дип яза.

Бу бик тә сәер килеп чыга бит. Сезнең анда тагын ниндидер аңлашылмаучылык туган булса кирәк. Эш шулай тора: иптәш Накоряковның ризалыгы белән, иптәш Рябинина «Казакъ кызы» романының тәрҗемәсен иптәш Шәриповага[2] тапшырырга һәм аның белән договор төзергә килешенгән иде. Сезнең телеграммадан тәрҗемәнең договоры һаман төзелмәве аңлашыла.

Иптәшләр! Миңа бу эшне милли сектор инде икенче тапкыр өзә шикелле тоела.

Бу эшне ашыктыруыгызны үтенәм.

Җавап өчен открытка салам.

Автор *Г. Ибраһимов.*

---

Бу хат Г. Ибраһимовның үз кулы белән русча язылган төп нөсхәсендә саклана. Ахырда «Ялта, ул. Халтурина, 5» дип, язучының шул чактагы адресы да күрсәтелгән.

[1] Тарсис В. Я. — тәрҗемәче һәм ГИХЛның шул чактагы редакторы.

[2] Шәрипова Гайшә — тәрҗемәче, хәзер Казагыстан язучылар союзы члены, Алма-Атада яши.

11

26 декабрь... Ялта.

Мәскәү, ГИХЛ, милли секторга.

Безнең үзара килешү нигезендә Рябинина минем романның тәрҗемәсен Шәриповага 23 октябрьдан да соңга калмыйча тапшырырга һәм аның белән договор төзергә тиеш иде. Бу эшне ашыктыруыгызны сорыйм.

*Ибраһимов.*

---

Г. Ибраһимовның бу телеграммасы телеграмма кәгазендә саклана.

12

[Ялта.]

ГИХЛ, милли секторга.

Кадерле иптәшләр!

Сезнең хатыгызны алдым. «Казакъ кызы»н тәрҗемә итү, минемчә, тәмамланып килә торгандыр. Минем Мәскәүдә булган чакта иптәш Накоряков һәм Рябининалар белән Шәрипованың тәрҗемәсен тәҗрибәле рус стилисте тарафыннан редакцияләнәчәге турында килешенгән иде. Килешенгән шартларның бу моменты үтәлер дип ышанам.

Якын айларда гына Мәскәүгә барырлык хәлдә түгелмен: миндә плеврит бик көчәеп китте һәм хәзер мин Ялтаның хирургия больницасында ятам.

Тәрҗемәнең барышы турында сезнең хәбәрегезне көтәм.

Иптәшләрчә сәлам белән: *Г. Ибраһимов*

---

Бу хат язучының үз кулы белән язылган нөсхәсендә саклана. Хатның язылу вакыты күрсәтелмәгән.

13

22 сентябрь, 1933 ел, Ялта.

Мәскәү, 25 октябрь урамы, 10.
Госиздат. Мозольковка[1].
«Безнең көннәр» романын тәрҗемә итү өчен кем белән договор төзелде?

*Ибраһимов.*

---

Г. Ибраһимов бу телеграмманы Ялтадан җибәргән. Телеграмма кәгазендә саклана.

[1] Мозольков — Мозольков Е. С. — ул елларда Дәүләт матур әдәбият нәшриятының редакторы булып эшли. Белорус әдәбияты белгече, тәрҗемәче.

14

28 февраль, 1934 ел, Ялта.

ГИХЛ, милли секторга.

Кадерле иптәшләр!

Иптәш Шәрипова миңа «Казакъ кызы» романының бер өлешен җибәргән иде. Ләкин мин хирургия больницасында ятам, хәлем бик авыр, ул тәрҗемәне укырлык һәм бәя бирерлек хәлдә түгелмен. Шул сәбәпле, автор буларак, мәсьәлә минем яктан түбәндәгечә хәл ителә:

Тәрҗемәнең сыйфаты өчен бөтен җаваплылык тәрҗемәчегә һәм милли секторның редакторына йөкләтелә. Соңыннан минем тарафтан претензияләр булмаячак. Бу турыда хәбәр итәргә тиеш табам. Чөнки иптәш Накоряков белән «тәрҗемә автор карап чыкканнан соң гына басарга җибәреләчәк» дип килешенгән иде. Хәзер бу шарт төшеп кала.

Тик авторның өч кисәтүе бар:

1. Эпиграф шигырьне алып ташларга. Ул кирәк түгел.
2. Беренче бүлекнең беренче җөмләсе уңышсыз тәрҗемә ителгән, аны төзәтергә кирәк.
3. Китапның исеменнән соң, титул биткә, шулай ук беренче бүлеккә «Революциягә кадәрге казакъ тормышыннан» дигән сүзләрне өстәргә кирәк.

Бу уңай белән әйтергә теләгәннәрем менә шулар иде.

Китап совет язучылары съездына[1] чыгып өлгерер дип ышанам.

Иптәшләрчә сәлам белән: *Г. Ибраһимов.*

---

Бу хат машинкада басылган һәм язучының үз имзасы куелган кәгазьдә саклана.

[1] Сүз Совет язучыларының 1934 елда үткән беренче съезды турында бара.

15

17 май, 1935 ел, Ялта.

Мәскәү, 25 октябрь урамы, 10.
Госиздат. Накоряковка.
«Татар хатыны ниләр күрми» романы ни өчен шулай озак чыкмый тора?. «Безнең көннәр» романын тәрҗемә итү мәсьәләсе ничек?

*Галимҗан Ибраһимов.*

---

Телеграмма кәгазендә саклана.

## 16

20 март, 1936 ел, Ялта.

Гослитиздат.

СССР халыклары редакциясе.

Кадерле иптәш Асадуллаев [1]!

Миңа мәгълүм булган белешмәләргә караганда, «Безнең көннәр» романын тәрҗемәгә кемгә тапшыру мәсьәләсе хәзергәчә хәл кылынып бетмәгән икән. Мин, автор буларак, бу эшне Совет язучылары союзы члены, тәҗрибәле тәрҗемәче иптәш Г. Шәриповага тапшырырга тәкъдим иткән идем. Ул озак еллар дәвамында Дәүләт нәшриятында даими хезмәттәшлек итеп килә. Минем Дәүләт матур әдәбият нәшриятында басылган өч романымны да Шәрипова тәрҗемә итте. Дәүләт матур әдәбият нәшрияты үткәргән конкурста ул премия дә алды. Татарстан Совет язучылары союзы председателе иптәш К. Нәҗми миңа иптәш Беспаловның [2] татарчадан русчага тәрҗемә итү конкурсында кем премия ала, шуңа «Безнең көннәр» романының тәрҗемәгә тапшырылачагы турында әйтүен язды. Ул хәзер бүләкләнде [3]. Бөтен нәрсә тизрәк кирәксез волокитаны туктатырга һәм Шәриповага бу бик җаваплы эшне тапшырып, практик эшкә керешергә кирәклек турында сөйли. Әмма бер төп шарт белән: тәрҗемәгә политик яктан көчле, грамоталы, партияле редакторның җитәкчелек итүе зарурый.

Тагын бер нәрсә. Әгәр тәрҗемәчегә гонорар күләме мәсьәләсендә фикер аерымлыклары килеп чыкса, мин түбәндәгене тәкъдим итәм: сез бит бу басма өчен, автор буларак, минем белән договор төзеячәксез. Менә шул автор гонорарыннан тәрҗемәче гонорарына билгеле бер күләмне өстәгез. Мәсәлән, әгәр сез тәрҗемәчегә табагына 250 сум бирергә уйлаган булсагыз, хәзер автор гонорары хисабыннан 300 итеп бирегез. Тәмам туйдырып бетергән волокитаны тизрәк туктату өчен менә шуны эшләргә кирәк.

Сезнең җавапны көтәм.

Коммунистик сәлам белән: *Галимҗан Ибраһимов.*

---

Бу хатны Г. Ибраһимов русча язган. Хатның ахырына «Ялта, Боткинская, 23» дип адрес язылган. Дәүләт матур әдәбият нәшрияты Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романын тәрҗемә итүне һәм басуны планлаштыра. Ләкин ул, төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә, үз вакытында тәрҗемә ителми кала. Ул сәбәпләрнең кайберләре бу хатта да күренә. «Безнең көннәр» романы рус телендә 1962 елны гына Р. Фәизова тәрҗемәсендә дөнья күрде.

[1] Асадуллаев — Дәүләт матур әдәбият нәшриятының СССР халыклары бүлеге редакторы.

[2] Беспалов — Беспалов И. В. (1900—1937) — рус совет тәнкыйтьчесе. 1934 елдан башлап 1937 елга кадәр Дәүләт матур әдәбият нәшриятының (Гослитиздат) баш редакторы булып эшли.

[3] Шәрипова Гайшәнең Дәүләт нәшрияты үткәргән конкурста бүләкләнүе турында сүз бара.

# ГАДЕЛЛЕК ҺӘМ МӘХӘББӘТ ПОЭЗИЯСЕ

*(„Дастан Бабахан" әсәренә 550 ел тулу уңае белән)*

Бөтендөнья әдәбиятында атаклы булган Шекспир, Шиллер, Пушкин, Толстой, Фирдәүси, Низами, Нәвои, шулай ук бүтән әдип һәм шагыйрьләр үзләренең үлемсез әсәрләрендә гаделлеккә һәм эчкерсез мәхәббәткә чиксез зур урын биргәннәр. Аларның бу мәсьәләләрне үз вакытларында күтәреп чыгулары хаксызлыкка, эксплуатациягә каршы, кешенең иң гүзәл сыйфаты булган мәхәббәтне акча, дәрәҗә, байлык һәм власть өчен корал итеп куллануга каршы кискен протестның бер күренеше иде.

Моннан 550 еллар элек Сайяди псевдонимлы шагыйрь тарафыннан лиро-эпик һәм трагик жанрда язылган «Дастан Бабахан» исемле әсәр дә шул ук гаделлек һәм саф мәхәббәтне яклап язылган әдәби мирас.

Әсәрнең сюжеты бик борынгы заманнарда туган һәм төрки халыкларына гына түгел, гомумән Көнчыгыш халыкларына да билгеле булган Таһир белән Зөһрә арасындагы мәхәббәтне гәүдәләндерүгә багышланган. Көнчыгыш халыкларында бу сюжетка язылган һәм Таһир-Зөһрә конфликтын төрлечә чишелештә күрсәткән әсәрләр дә бар. Мәсәлән, азербайҗаннарда чыккан «Таһир-Зөһрә» әсәрендә Таһир һәм Зөһрә исән чакларында ук үзара кушылып, бәхетле гомер итәләр.

Ә төркмән шагыйре Молланепесның (1810—1861) «Зөһрә-Таһир» романында алар башта үтереләләр, аннары бер изге кешенең догасы белән яңадан тереләләр. Сайяди вариантында исә аларның җаннары гына бергә кушыла. Сайядига нисбәтен бирелә торган «Таһир-Зөһрә»нең берничә варианты бар. Шул вариантларның берсе — «Дастан Бабахан» дигәне XVIII йөз ахырларында Биби Ганбәр мелла Йосыф кызы исемле шагыйрә тарафыннан Куян авылында күчерелеп алынган. Ләкин бу кульъязма, ул чорда татарча китаплар басу эше юлга салынмаганлыктан, дөньяга чыга алмаган. 1870 елларда Күшәр авылының Әхмәт Уразаев-Курмаши дигән кеше, «Таһир-Зөһрә»нең төрекчә вариантыннан файдаланып, үзенең «Таһир-Зөһрә» исемле әсәрен яза. Аннары ул әсәр күп тапкырлар басылып, халык арасына таралып китә. Курмаши каләме белән эшкәртелгән «Таһир-Зөһрә» бу сюжетка язылган әсәрләрнең бер варианты булса да, ул Сайяд углы Кылыч каләме белән язылган «Дастан Баба хан»нан бик нык аерыла. Бу аерымлык әсәрнең төзелешендә дә, эчтәлек һәм вакыйгаларның үстерелешендә дә бик ачык күренә.

Курмаши әсәрендә дә, ул файдаланган Истамбул нөсхәсендә дә ханның һәм вәзирнең исемнәре юк. Авторның үзенең исеме, шулай ук баласы юклыгы турында да бер сүз дә әйтелми, бәлки: «Төрле хәбәрләрне сөйләүчеләр сөйлиләр ки...» — генә диелә.

Хан һәм вәзир, балалары булсын өчен, бик күп изгеләргә сәдакалар — меңәр-меңәр алтыннар өләшәләр. Ниһаять, бакчада боларга бер изге кеше очрый. Үзләре әйтмәсәләр дә, ул боларның хан белән

вәзир икәнлекләрен, балалары юклыкка кайгырып йөрүләрен белә. Аларга бер алма биреп, шуны икегә бүлеп ашарга (балалары булсын өчен) куша, ләкин балалары тугач, аларны бер-берсеннән аермаска киләклеге турында әйтә. Аерсалар, зур фаҗигалар туачагын да искәртә. Хан, моңа да мең алтын бирим дип, кесәсенә кулын сузганчы, әлеге «изге» кеше юк була.

Курмаши әсәрендә Таһир чиксез көчле итеп сурәтләнә, ул ханның меңнәрчә гаскәрен кыра, тик Зөһрә кушкач кына хан гаскәрләренә бирелә.

«Дастан»да исә бала өчен акча түләүләр юк. Анда ханның Баһир исемле вәзире бала сорап ходайга ялвара да, шунда ук йокыга китә; төшендә һәр йкесенең балалары буласын күрә; ханга барып бу сөенечле хәбәрне сөйли; хан шунда аңа балаларны бер-берсеннән мәңге аермаска сүз бирә, ә вәзир, моңа ышанмаса да, ханга каршы килми. Таһир да бу әсәрдә алай чиктән тыш көчле түгел, һәм ул хан гаскәрләре белән сугышмый да.

Курмашида хан үзенең вәгъдәсендә торырга тели һәм Зөһрәне Таһирга бирү өчен туй әзерлекләре күрә башлый, ә ханның хатыны моңа каршы төшә: дистәләрчә шаһзадәләр сорап торганда, кызын вәзир улына бирергә теләми, моңа аның горурлыгы ирек бирми. Ханны болай гына күндерә алмагач, төрле сихерчеләр китереп, ханны сихерләтеп Таһирдан күңелен кайтара.

«Дастан»да исә Зөһрәнең анасы Таһир ягында тора, «кызың сөйгәч, син дә сөяргә тиеш» дип, ханны үгетли. Димәк, монда ханның хатыны — чын һәм шәфкатьле ана. Зөһрәне Таһирдан аеруга ачык социаль мотивлар сәбәп була. Бердән, хан үзен ак сөяк, югары раса, ә вәзирне һәм аның улы Таһирны кара сөяк, түбән раса дип карый. Икенчедән, әгәр кызын вәзир улына бирсә, олы хан — каан[1] алдында дәрәҗәсе төшүдән курка, шуңа күрә Зөһрә тугач та, Таһир тумас борын ук, вәзирнең ир баласы булса, вәгъдәсен бозарга карар бирә.

> Үз-үзидин әйтер: шаһ ирермән[1],
> Бу татар илигә хан ирермән.
> Вәзирем Баһир ирде[2] *кара углы*,
> Ки бу Таһир ирер һәм аның углы.
> Рәва ирмәс[3], вәзире берлә ханы
> Кода булса, мәламәт тартса[4] җаны.
> Килер башымга йөз төрлүк мәламәт,
> Ки хакан илидин тартгым әһанәт[5].

Ул йөзләрдә Идел — Кама тирәләрен яулап алып, шунда хан итеп куелган кешеләр үзләрен Чыңгыз нәселеннән килгән ак сөяк, югары раса санады лар, әмма бу «югары раса» кешеләр аз була, һәм тиз арада алар җирле төрки халыклары тәэсирендә калалар, җирле халык әкренләп властька килә. Таһирның атасы Баһирның Бабаханга вәзир булуы, ә Бабаханның аңа һаман да кара сөяк, түбән раса итеп каравы әсәрдә бик ачык чагыла.

Классик әдәбиятта бик күп бәхетсезлек һәм конфликтларга сәбәп итеп күрсәтелгән менә шул каста аермасы Таһир белән Зөһрә арасындагы саф һәм керсез мәхәббәтнең бәхетсезлек һәм һәлакәт белән тәмамлануына сәбәп була.

Бабаханның кызы Зөһрә, вәзир Баһирның улы Таһир чиксез саф күңелле һәм бер-берсен чын күңелдән сөйгән, бер чакта да бер-берсенә хыянәт итмәүче гашыйклар итеп сурәтләнәләр. Бабахан Таһирны эзәрлекли, аны сандыкка салып, суга агызып җибәрә. Ул Бәгъдад патшасы сараена барып чыга. Бәгъдад патшасының кызы Маһым аңа гашыйк була. Җанын саклау өчен, Таһир аңа өйләнә, әмма аның ире булмый: бер урынга ятсалар да, арага кылычын куеп ята. Ә Зөһрәдән хәбәр алу белән, коры сахралар, биек ташлы таулар аркылы, төрле куркыныч һәм юлбасарларга очрыйочрый, үзенең Зөһрәсе янына кайта.

Зөһрә дә шулай ук: ул да, Таһир агызып җибәрелү белән, дөнья кызыкларын ташлый, ниһаять, Таһирны эзләргә кеше җибәрә. Тик Таһир

---

[1] Каан (хакан) — өлкән хан мәгънәсендә.

[1] Шаһ мин.
[2] Иде.
[3] Килешми.
[4] Борчылса.
[5] Хур булырмын.

әйләнеп кайткач кына тагын җанланып китә.

Әсәрдән күренгәнчә, Таһирны яклап илдәге бөтен халык күтәрелә. Халык җыелып Бабаханга килә. Ни теләсәң шуны: бөтен байлыгыбызны, алтыннарыбызны ал, әмма Таһирны исән калдыр, диләр. Әмма деспот хан халыкның бу үтенечен кире кага, Таһирның башын кистерә. Әгәр халыкның бу соравын үтәсәм, ул башка таләпләр дә куя башлар, дип курка Бабахан. Ләкин бу җинаять ханга кыйбатка төшә: ул үзенең бердәнбер кызын — Зөһрәсен югалта. Зөһрә Таһир кабере өстендә үзүзен үтерә.

Шагыйрь монда да мәхәббәтнең үлемнән көчле икәнен әйтә. Таһир һәм Зөһрә үлгәч тә бу ике гашыйк каберләре өстенә үскән гөлләр, чәчәкләр һәм аларга кунып сайраган кошлар аркылы, алар арасындагы мәхәббәтнең дәвам итүен аеруча матур һәм көчле итеп сурәтли.

Әсәрдә геройларның исемнәре очраклы сайланмаган, бәлки символлаштырып алынган. Мәсәлән, Таһир — пакь, саф кеше дигән сүз. Зөһрә — безнең халык арасында шигъри хисләрне иң күп уята торган Зөһрә йолдыз исеме. Әсәрдә Бабахан кызына бу исемне халык үзе җыелып биргәне әйтелә, һәм Зөһрә үзе дә, халыкка, ярлы һәм мескеннәргә ярдәмче итеп сурәтләнә. Таһирның анасы Шаһ Хубан дип йөртелә (матурлык патшасы дигән сүз). Бәгъдад патшасы Гадел шаһ, ә кызы — «Маһым» дип исемләнә (Маһ — ай).

Әсәрнең теле чуар. Монда борынгы төрки сүзләр дә, гарәп һәм фарсы сүзләре дә күп. Ләкин бу чуарлык безне гаҗәпләндермәскә тиеш. Ул хәл безнең XVI йөз шагыйре Мөхәммәдъяр, XVII, XVIII, XIX йөз шагыйрьләре Мәүлә Колый, Утыз Имәни һ. б. да бар. «Дастан»ның теле Мөхәммәдъяр теленә бик якын. Әмма ул төрекчәдән дә, үзбәкчәдән дә аерыла.

Һәрбер әдәби әсәрнең билгеле тарихи җирлеге бар. Без әсәрне, андагы ситуацияләрне, беренче карашта әһәмияте аз булган детальләрне дә игътибар белән күзәткәч, аның тарихи җирлеге — XIII — XIV йөзләрдә Идел — Кама тирәсендә яшәгән һәм хәзерге татарларның бабалары булган болгарлар һәм бүтән төрки халыклары иле икәнен күрәбез. Ул йөзләрдә бу ил үзәге Кара-Корымда булган Чыңгыз империясенең бер өлеше саналган. Шуңа күрә көчле һәм күп гаскәрле Бабаханның Таһир-Зөһрә мөнәсәбәте мәсьәләсен чишкәндә дә, югарыда күрелгәнчә, өлкән хан (каан) сараендагы фикер белән хисаплашуы очраклы түгел.

«Таһир-Зөһрә» темасына язылган әсәрләр төрки телендә сөйләшүче халыкларның һәммәсендә диярлек бар. Аларның барысында да сүз татар иле һәм татар халкы турында бара. Хәтта XIX йөздә шушы темага зур роман язган төркмән шагыйре Молланепес та Бабаханны татар ханы, Таһирны татар дип атый. Тик Молланепес әсәренә сүз башы язган Аман Кекилов иптәш кенә аны 1799—1834 еллардагы Иран шаһы Фәтх Алинең әдәби образы дип уйлый.

Әсәрдә Бәгъдадка мөнәсәбәтнең дә зур әһәмияте бар. Мәгълүм ки, Бәгъдад белән Идел — Кама буйларында яшәүче халыклар арасында бәйләнеш X йөзләрдә үк башланып китә, һәм бу бәйләнеш сугышлар, басып алулар аркылы түгел, бәлки сәүдә һәм культура юлы белән бара. Менә шул җылы дуслык мөнәсәбәте әсәрдә бик ачык гәүдәләнә. Бу илләр арасында сәүдә кәрваннары йөри. Ике ил халыклары бер-берсенең телләрен дә аңлыйлар. Татар иленнән барган Таһир һич кыенлыксыз Бәгъдад патшасы сараена кабул ителә. Таһирны эзләргә җибәрелгән кеше дә үзеңең җыры аркылы Таһирны эзләп таба. Патшаның икенче кызы Шәһри белән дә бик тиз аңлаша һәм аңа өйләнә дә.

Шуны да истә тотарга кирәк: Бәгъдадның көче, төзеклеге XIII йөзләргә чаклы гына бара. Чыңгыз хан улының улы Һәлакү гаскәрләре Бәгъдадны тар-мар иткәч, аның инде элекке шөһрәте сүнүгә йөз тота. Бу факт та әсәрнең XIV йөздән дә соң языла алмавын күрсәтә. Борынгы әдәбиятыбызны озак еллар тикшергән мәрхүм Б. Яфа-

ров та аның язылу датасын шул чорга кайтара.

Шул рәвешчә, шагыйрь Бәгъдад патшасын гадел шаһ итеп күрсәтеп, шул гаделлеге буенча, аны деспот шаһ Бабаханга каршы тип итеп ала. Бу — урта гасыр әдәбияты өчен хас сыйфат. Урта гасырның алдынгы кешеләре феодаль таркаулык һәм шул нигездә туган үзара бәрелеш-ызгышларны гаепләгәннәр, патшалар, корольләр әнә шул феодаль таркаулыктан килгән кыенлыкларны җиңеләйтүче үзәк булганнар. Ләкин моның өчен аларның гадел һәм ил халкына яхшы мөнәсәбәттә булулары зарур саналган. Гадел патшаны, корольне, ханны әдип һәм шагыйрьләрнең идеал итүенең сәбәбе шунда. Аларга әле бүтән төрле гаделлек билгеле дә булмаган, аның өчен кирәкле шартлар да ул дәвердә өлгермәгәннәр.

Гаделлек мәсьәләсе кешелек җәмгыяте белән бергә туган. Аны һәрбер намуслы кеше яклый. Ләкин гаделлек төшенчәсе чорга, чордагы социаль-экономик, политик шартларга карап үзгәрә. Шуңа күрә без гаделлекне яклаган Сайяди, Нәвои кебек борынгы әдәбият вәкилләрен ихтирам итәбез, әмма алардагы *гадел монарх* идеясен шул килеш бүгенге чорыбызга күчерә алмыйбыз.

Әсәрдәге аерым детальләр дә аның җирлегенең кайда икәненә ишарә итәләр. Мәсәлән, Таһир өчен эшләнгән сандыкны, Зөһрәнең кушуы буенча, су үтмәсен дип, бик нык мумлап (балавызлап) әзерлиләр. Бал һәм балавыз — Идел — Кама буйлары, гомумән, хәзерге төньяк Россия җирләре өчен характерлы әйбер. Без моны X йөз башында Бәгъдадтан Болгарга килгән Ибн Фадланның сәяхәтнамәсендә дә бик ачык күрәбез.

Шагыйрь күп сулы елгаларны да биек агачлы урманнар арасыннан ага итеп күз алдына китерә, Таһир салынган сандык та шундый куе урман арасыннан ага. Таһир Бәгъдадтан кайтканда биек, ташлы таулар арасыннан үтә.

Бу әсәрне татар әдәбияты җөмләсеннән санау белән, бу темага язылган күп төрле әсәрләрнең башка төрки халыкларында да булганлыгын без һич тә инкарь итмибез. Тик шунысы бар: аларның берсендә дә бу әсәр «Дастан Бабахан» дип исемләнми. Әсәрләрнең темалары бер булса да, текстлары төрлечә. Бу төрлелек кайберләрендә бик ерак, кайберләре (мәсәлән, үзбәкләрнеке) безнең дастанга якын тора.

Әсәрнең авторы Сайяди — нечкә хисле, тирән кичерешле шагыйрь. Ул үзенең геройлары белән бергә яши, алар кичергән кайгы-хәсрәтләрне үз йөрәге аркылы үткәреп кәгазьгә төшерә. Әсәргә язган керешендә үк, кеше өчен баланың чиксез кадерле икәнен әйтеп, үзенең баласы юклыктан зарлана. Кешенең җимеше бала икән, ә минем балам юк, шуңа күрә мин коры тән, минем җаным юк, минем көнем төн кебек караңгы, юлымны яктыртучы аем юк, ди. Шуның белән ул Бабахан җинаятенең, Таһирның анасы Шаһ Хубан хәсрәтенең ни дәрәҗәдә көчле булырга тиешлеген алдан ук сиздереп куя, әсәр дә шул планда җәелдерелә. Геройларның лирик кичерешләре рәвешендә китерелгән газәлләрне дә ул шул ук газәл тонында үз кичерешләре белән тәгәлләп бара.

Шагыйрь Сайяди үз чорында көнчыгышта билгеле булган Йосыф-Зөләйха, Ләйлә-Мәҗнүн, Фәрһад-Ширин кебек төп чыгышлары белән борынгы яһүд, кытай һәм гарәп хикәяләренә тоташкан халык иҗаты әсәрләре белән дә таныш булган һәм аларны үз әсәрендә телгә алып киткән. Аңа IX йөз ахырында Бәгъдадта реакцион руханилар таләбе буенча үтерелгән Мансур Хәлаҗ исемле Иран шагыйре дә билгеле.

Әсәрне безгә китереп җиткерергә сәбәпче булган, аның тулы күчермәсен калдырган Биби Ганбәр мелла Юсыф кызы да илебезнең төрле почмакларына таралган Куян авылларының берсендә туган. Соңыннан ул элекке Казан өязе Кавал һәм Мулла иле авылларына, аннан Казанга килеп чыккан. 1817 елда икенче ире Шәфигулла исемле кеше белән тау ягына (Казаннан көньякта) күчеп киткән. Үзе укымышлы, әдәбият сөюче ханым булган. Аның китапханәсендә заманының мәшһүр

әсәрләре «Мөхәммәдия», «Әмали» һ. б. китаплар булып, Биби Ганбәр аларны төпләтеп, саклап тоткан. «Дастан Бабахан»ның кырыйларында шул Биби Ганбәр кулы белән язылган икешәр юллы шигырьләр, тарихи фактлар, гарәп һәм фарсы телләрендә кыска-кыска текстлар бар. Мәсәлән, 198 биттә мондый белешмә бар: «Александр Павл углы, Павл Битыр углы, Битыр Фидыр углы, Кстантин Павл углы». (1801—1825 елларда Россиядә патша Александр 1 турындагы бу язуын үзенчә алдык.) 148 биттә:

Бакчаңа бадиан игәем,
Куйныңа җофар сибәем,
Сагынуыңны беләмен,
Кайтып кына булмый, нишләем.

102 биттә:

Кил, и Дилбәр[1], йөзең ачкыл,
Тәсаддыкдыр бу җан[2] имди;
Фиракың һәҗридә һәрдәм[3]
Көяр бу остехан[4] имди.

160 биттә:

Көлле гыйльмин Ләйсә фил-кыйртаси заг;
Көлле сиррин җавәзәл-иснәйни шаг.
(Кәгазьгә язылмаган һәрбер гыйлем югала;
Ике кешедән артыкка билгеле һәр сер фаш була.)

160 биттә:

Фәләк, сән худ ирерсән, би вафа,
Тапмадым мин һәр гиз яуме сафа.
(Язмыш, син начар, вәгъдәсез;
Бер чакта да мин рәхәт көн тапмадым.)

Менә болар Биби Ганбәрнең гади бер хатын-кыз гына түгел, бәлки үз заманында бик сирәк очрый торган аңлы бер ханым икәнен күрсәтә. Безгә әле әсәрнең авторы Сәйяди турында да, аны күчерүче Биби Ганбәр турында да бик аз нәрсә мәгълүм. Киләчәк, бәлки, тагын күп нәрсә ачар.
Биби Ганбәр «Дастан»ны да шигырь белән тәмамлый:

Гыйнаять кыйлды тәнре бирде һиммәт,
Җомга көн булды тәммәт, —

ди һәм «Куян авылында Мелла Йосыф кызы Биби Ганбәр бетедем» («яздым» дигән сүз) дип кул куя.

Югары художестволы итеп, саф дөньяви темага язылуы, деспотизмны, каста аерымлыгын гаепләп, деспот хан белән халык арасындагы каршылыкны ачуы, гуманизм һәм гаделлеккә, саф мәхәббәткә дан җырлавы белән әсәр безнең әдәбият тарихыбызда зур урын тота. Шуны исәпкә алып, бу әсәрнең зур бер өлеше, С. Исәнбаев иптәш эшкәртүендә, «Борынгы әдәбият» дәреслегенә кертелде. Хәзер аның тулы тексты, рус теленә юлга-юл тәрҗемәсе дә әзерләнә.

*Х. Хисмәтуллин.*

[1] Гүзәл кыз.
[2] Бу җан сиңа сәдака (синең өчен).
[3] Синнән аерылу хәсрәтендә һаман.
[4] Сөяк, гәүдә, тән.

# ДИНГӘ КАРШЫ ӘКИЯТЛӘР

## БУТАШЧЫ

*Русчадан*

Бер карт белән карчык кызларын кияүгә бирәләр. Өч ел гомер үтә, оныклары һаман юк та юк.

— Бар, карчык, попны күр, гыйбадәт кылдырырга кирәк. Бәлки, поп оныклар тудыра торган дога әйтер, — ди карт.

Карчык, попка сәдакага-бүләккә бер чүлмәк май, бер бөтен тавык һәм бер дистә йомырка китереп биреп, үзенең кайгысын әйтә:

— Өлкән кызыбыз өч ел ирдә инде, һаман да бала тапканы юк,— ди.

— Бер тәңкәлек шәм сатып ал һәм шуны изге Николай хөрмәтенә кабызып яндыр, ә мин дога укырмын, — ди поп.

Бер ел үткәч, карчык попны яңадан очрата һәм, үпкә белдереп, әйтә:

— Былтыр үзеңә күпме бүләк китергән идем, Миколага бер тәңкәлек шәм куйган идем, син дога укыдың һәм Сез Микола белән икегез дә буташчы булып чыктыгыз: баланы ирдәге кызыбыз түгел, ә кияүгә чыкмаганы тапты!

## КЕМ АЛЛАСЫ ЯХШЫРАК?

*Русчадан*

Рус побы белән еврей раввины бәхәсләшәләр: кемнең, кайсы диннең алласы халыкка файдалырак? Берсен берсе ничек тә ышандыра алмагач һәм аңлашып булмагач, берәр кешене очратып сорарга булалар.

Менә каршыларына бер узгынчы килеп чыга. Руханилар аны туктатып сорыйлар. Теге кеше җавап урынына болай ди:

— Минем туганнарымның кәҗә тәкәләре бар иде. Әтием шуны сатарга ниятли, ә әнкәм саттырырга теләми: бик күп сөт биргәне өчен, тәкәне бик кызгана ул...

— Нәрсә лыгырдыйсың син баш катырып? Кәҗә тәкәсенең сөт биргәнен кемнең күргәне бар!

— Ә алланың кемгә дә булса булышканын, кешегә ярдәм иткәнен кемнең күргәне бар? Сез күрсәгез генә! — ди узгынчы.

## МӘРЬЯМ АНА ҺӘМ ИЗГЕ НИКОЛАЙ

*Украинчадан*

Берчакны шулай ике кода бергәләп шәһәрдән кайтып киләләр. Алар базарда булганнар, тегене-моны, шул җөмләдән, изге сурәтләр дә сатып алганнар. Берсенең олавында Мәрьям ана, икенчесенекендә изге Николай икән.

Кайталар шулай. Ә юл өстендә пивной бар. Тукталмыйча узып буламы соң!

— Ничек, кода, әллә кереп чыгыйкмы?

— Керүен керәбез. Тик менә атларны кем карар?

— Берни дә булмас атларга. Ә изгеләр, аллалар нигә? Шулар карарлар.

— Чыннан да шулай бит!

Менә алар пивной янына килеп туктыйлар, берсе үз арбасына Мәрьям ананы бастырып куя, ә икенчесе — Николайны.

— Саклагыз безнең олауларны! — диләр.

Үзләре пивнойга кереп утыралар, эчәләр. Әйләнеп чыксалар — ни күрсеннәр: атлары да, олаулары да юк, җирдә изге сурәтләр генә аунап ята.

Кодалар аптырашып бот чабалар, аннары берсе үзенең Николаена әйтә:

— Ярый, тегең, Мәрьямең, балалы ди инде, шуңа күрә атларга күз-колак була алмагандыр, ә син үзең, карт тәкә, нәрсә карадың? — ди.

## АЛЛА ДА БЕР, КАМЫТ ТА...

*Белорусчадан*

Көннәрнең берендә авылга архирей килә, крестьяннар белән гәпләшкәндә сорап куя:

— Ә беләсезме сез, җәмәгать, алланың изге өч сурәте нәрсә ул?—ди.

Халык дәшми. Кешеләр нинди җавап әйтергә белмиләр. Шуңа күрә архирей үзе аңлата башлый:

— Аллаһы тәгалә үзе берәү генә, ләкин ул берьюлы өч сурәттә яши. Әйтик, мисалга, камытны алырга мөмкин. Аңарда агач та, киез дә һәм күн дә бар, ә исеме бер генә — камыт. Аңлашылдымы? — ди.

— Аңлашыла, аңлашыла! — диләр.

Икенче елны архирей яңадан шул якларга килеп чыга. Гыйбадәттән соң халык белән гәпләшә башлый:

— Я, хәзер ничек, алланың изге өч сурәте нәрсә икәнен беләсезме инде? — дип сорый.

— Беләбез, беләбез! Алла камыт кебек ул, икесе дә бер үк нәрсә — алла да, камыт та бер! — диләр кешеләр.

## ҖӘЯҮЛЕ ГЕОРГИЙ

*Украинчадан*

Күптән булган хәл бу.

Бер авылга иконнар сатучы килгән.

Бер карчык аңардан җиңүче Георгий дигән изге сурәтен алырга тели.

Ләкин икон сатучының андый иконы юк икән, шунлыктан әбигә ул Пантелеймон иконын күрсәтә.

— Георгий түгелдер бу? Георгий һәрвакытта да атка атланган була, — ди карчык.

Икон сатучы башын чайкап куя һәм әбине яхшырак ышандырырга тырышкан кыяфәт белән:

— Ахмакланма, әбекәй. Бер нәрсә дә аңламыйсың икән. Хәзер базарларда солы бик кыйбат тора, шуңа күрә Георгий үзенең атын сатты инде һәм күптән җәяү йөри, — ди.

Карчык моңа чын күңелдән ышанып, Георгий урынына Пантелеймонны сатып ала.

## ГӨНАҺЛЫ МУЖИК

*Белорусчадан*

Бервакыт бер ярлы мужик поп янына килә һәм әйтә тегеңә:

— Хатыным авырып ята, мине тәүбә итеп кайтырга дип сезгә җибәрде, ләкин нинди тәүбә әйтергә кирәген белмим — чөнки минем бертөрле дә гөнаһым юк, — ди.

— Кеше үтермәдеңме? — ди поп.

— Юк.

— Әйбер урлаганың бармы?

— Юк.

— Кеше хатыннары артыннан йөргәнең юкмы?

— Йөрмәдем.

Поп аптырый һәм ачулана башлый:

— Аллага ышанасыңмы, дога кыласыңмы?

— Юк.

— Аллага ышанмагач һәм дога кылмагач — ничек гөнаһсыз буласың инде син? Шуның җәзасы итеп, өч көн рәттән дога укып кына торырга кушам, — ди.

Мужик шулай эшли дә. Дүртенче көнне поп аны тагын очрата һәм сорый:

— Я, эшләрең ничек? — ди.

— Бик начар, гөнаһлы булдым, — дип җавап бирә мужик.

— Ничек ул алай?

— Булды шул инде! Миңа арыш урырга кирәк иде, ә мин, юләр, өч көнемне дога укуга әрәм иттем, — дигән мужик.

## ПОП ҺӘМ АУЧЫ

*Ингушчадан*

Поп үзенең ялчысын ауга җибәргән. Ялчы бер нәрсә дә тотмыйча кайткан.

— Гыйбадәт кыла белмисең, дин тотмыйсың,— ди поп,— шуңа күрә сиңа бер җәнлек тә эләкми. Эшне аны чукынудан, дога укып башларга кирәк иде.

— Мин нәкъ шулай эшләдем дә, — дип җавап кайтара ялчы. — Әйтик, як-ягыма каранып бара идем, кинәт каяндыр сикереп куян килеп чыкты. Мин мылтыгымны агачка сөяп куйдым да чукына, дога укый башладым, тик шуннан соң гына мылтыктан аттым.

— Һәм юләр булгансың! — ди аңа поп.

# БЕЗ СЕЗНЕҢ АРТТАН

*Төркмәнчәдән*

Халыктан күбрәк сәдака җыяр өчен, Эрали ишан вәгазьне бик озын сөйли, доганы бик озак укый икән.

— Исегездә тотыгыз, мөселманнар! Тәмуг бик хәтәр нәрсә ул. Аның каравы, җәннәттә бик рәхәт! Әмма анда эләгүләре бик кыен — кылдан да нечкә, кылычтан да үткен сыйрат күпере аша чыкмак кирәк. Җир мәшәкатьләрен онытып, тәңрегә табынып яшәгән кешеләр генә үтә аны... Инде рәхәт тә соң җәннәткә керсәң! Бөтен төшен чәчәк күмгән, хуш исләр аңкып тора, ризыкның чиге юк...

— Тәкъсир, — дип бүлдерә аны шунда Кимәнә, — әгәр җәннәттә шулай рәхәт икән, эш нәрсәдә соң, тынгысыз бу дөньяда мәшәкатьләнгәнче, тотыгыз да җәннәткә китегез!.. Без дә сезнең арттан шунда ашыгырбыз, — ди.

# ИШАНГА ОХШАГАН

*Төркмәнчәдән*

Бер бай үлгәч, аның мирасын бүлешергә барганда Эрали ишан үзенә бик яхшы аргамак иярләтә, ә шәкерте Кимәнәне бик начар атка атландыра.

Баралар. Юлда ишан күзенә хәтсез зур ризык кисәге өстерәгән тирес коңгызы чалына. Үзеннән еш кына көлгәне өчен үч алырга теләп, ишан әйтә шунда:

— Кара әле, Кимәнә, бу коңгыз бер капчык ипи сыныгы күтәреп кайткан Текин хәерчесенә охшамаганмы?

Кимәнә коңгызга тиз генә чыбык очы белән төртә һәм коңгыз, йөген ташлап, ал аякларын күтәргән килеш басып кала.

— Минемчә, тәкъсир, бу коңгыз ишанга охшыйрак төшә. Әнә күрегез, дога кылган булып кулларын нәкъ ишанча күтәргән, — ди.

# БЕР БАКЧАДА

*Азербайҗанчадан*

Бер бакчада мулла йөри икән. Шунда ук бер аю да килеп керә. Бакча хуҗасы боларның икесен дә күреп алып, мулланы кыйнарга тотына. Мулла дигәнең моңа аптырап кала:

— Каян алып миңа ябыштың әле, аюны ник кыйнамыйсың? — ди мулла.

Бакча хуҗасы әйтә:

— Аю ул ашап туя да чыгып китә, ә син ашап күбенгәннән соң да кесәләрең белән куеннарыңа ризык тутырасың, — ди.

# ЭТ ҮЛГӘЧ

*Азербайҗанчадан*

Бик бай бер хаҗиның куй көтүләрен саклый торган эте үлә. Бик яраткан эте булганга, ул аны кәфенләп, зурлап, муллалардан корьән нәр укытып күмдерә.

Моны ишеткәч, имам хәзрәте акылыннан язардай булып ачулана, дин мәсхәрәләп этне мөселман йолалары белән күмүчене үлемгә хөкем итәргә җыена. Һәм атына атланып хаҗи янына китә.

Имам киләсен хаҗи алдан белә, аңа бирергә үз көтүеннән бик симез илле сарык аерып куя һәм башын бик түбән иеп әйтә аңа:

— Олуг хәзрәтем! Хода бәндәнең кайгылары чиксез-чамасыз бит әле. Дошманнарымны куркытып, көтүләремне саклаган этем вафат булды. Мөселманның да мөселманы иде ул — муллалар белән имамнар турында гына уйлап яшәде акыллым. Үләр көнендә миңа синңа да чат симезләрен генә сайлап илле сарык бирергә васыять әйткән иде. Әнә ул синең сарыкларың! — ди.

— Ә нигә син аны эт диеп кимсетәсең! Аны бит минем кардәш-туганым дияргә була! — ди имам чиксез шатланып. — Кая дустымның кабере, күрсәт тизрәк, мин үзем корьән чыгам аның өстендә, — ди имам.

# ЗИРӘКЛЕК

*Башкортчадан*

Бер ярлының бик зирәк малае була. Ә шул авылның мулласы бөтен тирә-юньдә иң акыллы кеше дип үзен сөйләп йөри икән. Малай турында ишеткәч, мулла аның атасын очратып сораштыра һәм әйтә ди:

— Имеш, малаең бик зирәк синең. Кара син аны, бик күпне белеп кыланмасын, тыеп тот үзен. Яшьли зирәк булган зат олыгайгач тинтәкләнә ул.

Хәзрәтнең бу сүзләрен малай да тыңлап тора һәм болай ди икән:

— Мулла абзый, яшь чагында син бик томана булгансың диләр бит, картайгач ник зирәкләнмәдең соң? — ди.

# СЫЕРСЫЗ КАЛУ

*Көнчыгыш әкиятләреннән*

Бер кин күңелле ярлы кешенең инде эшкә ярамый торган чамасыз карт һәм бик арык ишәге була. Бернинди йөк ташырга ярамый, ә үзен ашатырга кирәк. Шул ук хуҗаның бик симез, бик матур һәм бик күп сөт бирә торган сыеры да бар икән. Кичләрнең берендә бу кеше ходайга ялвара:

— И тәңрем! Ал зинһар шул ишәкне миннән, үлсен ул! Юкка азык әрәм иттермә, шуны карый-карый туеп беттем инде, — ди.

Иртән торгач абзарга чыгып караса, хуҗаның исләре китә: яшь-яшь сыеры үлгән, ә карт ишәге исән.

Ул, ачуыннан нишләргә белмичә, башын күтәреп күкләргә карый һәм кычкырып зарын түгә:

— Әй, тәңрем! Шул күкләрдә мин бар дип күпмедән бирле утырган буласың, җир-күктәге барча нәрсә белән идарә итәсең, ә шушы көнгә хәтле сыерны ишәктән аера белмисең икән! Мин бит ишәгемне үтер дип сорадым, ә син мине сыерсыз иттең! — ди.

## ИКЕ ИШӘК ЙӨГЕ

*Кыргызчадан*

Көннәрнең берендә бер мулла үзенең улын ияртеп аугa китә һәм бергә йөрергә дип тапкыр, зирәк Әпәндене дә ала. Әпәнде җәяү бара икән, ә тегеләре атка атланганнар.

Көн бик эссе була. Мулла җиләнен сала һәм, тотып бар дип, Әпәндегә бирә. Моны күргәч, мулланың малае да җиләнен салып Әпәндегә тоттыра.

Юл шактый озын булганга, Әпәнде, тирләп-пешеп, арый башлый.

Мулла аңардан көлеп әйтә икән:

— Әй, Әпәнде, син бер ишәк йөртерлек йөк күтәреп тә хәлдән тайдың бугай, — ди.

— Мин бит, хәзрәт, ике ишәкнең йөген күтәреп барам, — дип җавап бирә Әпәнде.

Сайлап тәрҗемә итүче: Зәки Нури.

## *Латыш халык мәзәкләре*

### ЯХШЫНЫ ГЫНА ЭШЛӘҮ

Кызының кияүгә чыгарга ашыкмавын теләгән бер агай әйтә икән:

— Кызыкаем минем! Иргә чыгып кеше, әлбәттә, яхшы эшли. Әмма кияүгә чыкмау — аннан да яхшырак.

Кызы аңа болай дип җавап бирә:

— Алайса, әтием, мин яхшыны гына эшлим инде. Аннан да яхшырагы бүтәннәргә калсын.

### СЫЕР ҮЛГӘЧ

Борын-борын заманда бер крестьянның хатыны үлә. Кайгырып-сагышланып яши дә тол ир, ниһаять, тынычлана. Бераз вакыт үтүгә, моның башына тагын бәла килә бит: сыеры егылып үлә. Кайгысы акылдан язарлык була крестьянның. Бик озак вакытлар һич тынычлана алмый газаплана.

Көннәрнең берендә аңа күршесе керә дә шулай дип сорый:

— Хатының үлгәч бу хәтле үк хәсрәт кичермәгән идең бит, ә сыерсыз калгач — үзең үләрлек хәлгә җиттең. Ни хикмәт соң бу?

Крестьян җавап бирә:

— Хатыным үлгәч миңа бүтән егермеләп хатын тәкъдим иткәннәр иде. Ә хәзер исә миңа беркемнең дә сыер бирергә теләгәне юк.

### ЭШТӘН КАЙТКАЧ

Беркөнне хуҗа яңгырда баштанаяк чыланып, бик соң гына эштән кайта. Хатыны бик шатланып әйтә иренә:

— Синең, картым, өстең-башың барыбер юеш инде, бар әле, су да алып кер миңа.

Ире чиләк алып чыгып китә, су кайтара, аннары шул суны хатын өстенә сибә дә әйтә:

— Менә хәзер син дә юеш инде, бар, су алып кайт!

# Яңа китаплар



**И. Нуруллин**

**«ОБРАЗЛАР ДӨНЬЯСЫНДА»**

Бу китапка тупланган тәнкыйть мәкаләләре бүгенге әдәбиятыбызның актуаль проблемаларына багышланган. Мәсәлән, җыентыкка беренче булып урнаштырылган «Оста кулга — үткен корал» исемле мәкаләсендә тәнкыйтьче әдәбият дөньясындагы иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булган уңай герой проблемасы турында яза.

Язучылар, әдәбиятчылар арасында бу мәсьәлә буенча ике төрле караш яши: берәүләр «кимчелексез» уңай геройны яклыйлар, икенчеләре: «мондый караш схематизмга алып бара» дип, аларга каршы төшәләр. Мәкалә авторы уңай герой проблемасына карата болай дип яза: «Кимчелексез» герой, әйдә, түрдән узсын. Кешедә табылырга мөмкин булган иң гүзәл сыйфатларны үзендә туплый бирсен. Тик бер шарты бар: ышандырсын ул, ясалма булмасын!» И. Нуруллин бу фикерен дәлилләү өчен күп кенә язучыларның әсәрләрен анализлый, ул әсәрләрдә сурәтләнгән геройларга характеристика бирә, совет әдәбияты тарихына күз ташлый һәм, шул күзлектән карап, кайбер әсәрләрне тәнкыйтьли.

Китап авторы тәнкыйть мәкаләләрен укучыларны инде туйдырып бетергән коры «фән теле»ндә язмаган, фикерләрен һәркемгә аңлаешлы итеп, гади телдә, популяр стильдә укучыларга җиткерә, шул максаттан чыгып, төрле алымнардан файдалана. Менә аның «Комедияме, драмамы?» исемле мәкаләсе. Бу мәкалә хат формасында язылган. Ләкин бу кешенең көндәлек тормышындагы вак-төякләр турындагы хат түгел. Монда әдәбиятның, драматургиянең иң җитди мәсьәләләре турында сүз бара: комедия белән драма нәрсәсе белән бер-берсеннән аерыла? Әлбәттә, автор мәкаләнең башында ук бу сорауга турыдан-туры җавап бирми. Башта классик рус һәм татар драматургиясенә мөрәҗәгать итә. Классикларның әсәрләрендә сурәтләнгән катлаулы чынбарлык күренешләренең үзләре өчен анык жанр таләп итүләрен исбатлый, жанры анык булмаган сәхнә әсәрләренең, гадәттә, тамашачы күңелен яулап ала алмауларын конкрет мисаллар нигезендә күрсәтә.

И. Нуруллин әсәрләрнең төрле сыйфатлары, әдәбиятның төрле жанрлары турында яза. «Кече жанрда зур эчтәлек» исемле мәкаләдә драматург Юныс Әминовның «Бер пәрдәлек пьесалар» исемле җыентыгы турында сүз барса, «Тормышчан сюжетны яклап» мәкаләсендә, исеме үк әйтеп торганча, төрле жанрда язылган әсәрләрдә беренче планда идея тирәнлеге кирәклеген, сюжетның «ниндидер абсолют, беренчел компонент» түгеллеген, укучыны сюжет трюклары белән шаккатырырга тырышу белән генә чын сәнгать әсәренең тумавын конкрет мисаллар белән күрсәтә, идея-проблематик эчтәлекне тулы гәүдәләндерүгә хезмәт итә торган сюжетның гына тормышчан булуы мөмкинлеген әйтә.

«Кыскалык турында» исемле мәкалә, кайбер бәхәсле фикерләре булуга карамастан, шунысы белән әһәмиятле: автор биредә әсәрнең кыскалыгын яки озынлыгын «файдалы эш коэффициенты» белән билгеләнүен исбатлый, моны дәлилләү өчен татар һәм рус язучыларының күп кенә әсәрләреннән мисаллар, аларның сүзләрен китерә.

Китапка кергән «Иллюстрациядән проблемага» дигән мәкалә дә кызыклы гына. Бу мәкалә әдәби бәхәс формасында язылган. Тәнкыйтьче «А» белән тәнкыйтьче «Б» Ә. Еникинең «Саз чәчәге» повесте турында бәхәсләшәләр. Автор бу алымны повестьны бәяләүдәге фикер каршылыкларын тулырак чагылдыру теләге белән файдаланган. Ә китапның ахырына урнаштырылган «Язучының уйланулары» мәкаләсен тәнкыйть турында тәнкыйть дияргә була. Анда автор Фатих Хөснинең Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «Уйланулар» исемле тәнкыйть мәкаләләре җыентыгын рецензияли, әсәрләр турында фикер йөрткәндә, тәҗрибәле язучының һәр художникка хас бизәк һәм оттенокларны, җемелдәүләрне нечкәләп күрсәтеп бирүен уңай яктан бәяли.

Китап (күләме 144 бит, бәясе 26 тиен) киң катлау әдәбият сөючеләр, укучылар, укытучылар, язучылар һәм журналистлар арасында зур кызыксыну уятыр дип ышанасы килә.

Г. Иделле

## «ЯЗУЧЫ ҺӘМ АНЫҢ КИТАБЫ»

Китап «Әдәбият — тәрбия коралы, көрәш коралы» дип исемләнгән кереш сүз белән башланып китә. «Коммунизмның материаль-техник базасын булдыру өчен тарихи көрәш алып барган совет кешесен рухи азык белән тәэмин итү, аны тәрбияләү, үстерү, хисләрен баету — әдәбият һәм сәнгатьнең төп һәм изге бурычы шул», — ди автор китапка язган кереш сүзендә. Аннары ул хәзерге татар әдәбиятына кыскача күзәтү ясый.

Китап ике бүлектән тора: Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов, Ибраһим Гази, Риза Ишморат, Гариф Галиев, Абдулла Әхмәт һәм Хәй Вахит кебек язучыларның тормышлары, иҗади эшчәнлекләре турындагы хезмәтләр «Замандашларым иҗаты» дигән баш астына тупланган; ә икенче бүлектә автор Барлас Камаловның «Үр меңгәндә», Аяз Гыйлажевның «Качак» хикәяләрендә сурәтләнгән геройлар турында сөйли, Малик Хәмитов очеркларын анализлый, илленче еллардагы башлап язучыларның иҗатларына күзәтү ясый.

Гомәр Бәширов иҗаты турында моңа кадәр дә күп язылды инде. Аның иҗаты турында укучылар дәреслекләрдән дә укып беләләр, газета-журнал битләрендә дә аңа багышланган материаллар еш чыгып тора. Г. Иделленең Г. Бәширов турындагы бу китапка кергән хезмәте шуның белән әһәмиятле: ул иҗади портрет төсендә, очерк формасында язылган һәм анда язучының тормышы, иҗади-иҗтимагый эшчәнлеге берберсенә үрелеп бирелгән. Танылган язучының катлаулы тормыш юлы да, күпкырлы иҗади эшчәнлеге дә шактый тулы булып күз алдына килеп баса.

Мирсәй Әмиргә багышланган мәкаләсендә автор аның иҗатында төп, нигез урынны алып торган темаларга, аны язучы буларак характерлый торган әсәрләргә туктала. Шул күзлектән чыгып, М. Әмирнең хикәяләрен, повестьларын, романнарын анализлый, аларда сурәтләнгән геройларга хас характер сыйфатларын күрсәтә, язучының кырык елга якын вакыт эчендә иҗади үсеш процессын гәүдәләндерә.

Иҗат активлыгы белән танылган һәм заман темасына язылган әсәрләрендә чынбарлыгыбызның актуаль мәсьәләләрен күтәргән популяр язучыларыбызның берсе — Габдрахман Әпсәләмов иҗаты турындагы мәкаләләр дә, И. Газиның хикәяләренә, «Гади кешеләр», «Онытылмас еллар» романнарына карата язылган хезмәтләр дә, китапка кергән башка әсәрләр дә укучылар арасында үзенең хикәяләре, пьесалары белән киң танылган Г. Иделленең әдәбият белеме, тәнкыйть өлкәсендә дә каләме очлы икәнен әйтеп торалар.

Аның яшьләр иҗатына карата игътибарлы булуы, аларның әсәрләрен кат-кат укып чыгып, уңышлы һәм кимчелекле якларын җитди итеп анализлап бирүе, киңәшләре аеруча әһәмиятле. Чөнки алар тәнкыйтькә, тәҗрибәле каләм осталарының киңәшләренә бигрәк тә мохтаҗ булалар бит.

Г. Иделле А. Гыйлаҗевның «Качак» хикәясендәге Тәнзиләне, Б. Камаловның «Үр меңгәндә» хикәясендәге Илсурны аларга хас характер сыйфатларын, үзенчәлекләрен һәр яклап ачып бирә һәм икесе ике стильдә язучы бу ике яшь авторның иҗади алымнарына да киң туктала.

Безнең әдәбиятта очерк жанры турында тикшеренүләр, бу жанр турында тәнкыйть әйберләре бөтенләй юк диярлек. Булганнары да очраклы гына һәм бик өстән язылганнар. Г. Иделленең бу китапка кергән «Кешеләр, аларның эшләре» мәкаләсен мондыйлар рәтенә куеп булмый. Автор яшь очеркист М. Хәмитов әсәрләрен бик төпле итеп, җитди итеп тикшерә, уңышлы якларны да, кимчелекләрне дә ачык, конкрет итеп әйтә, бүгенге көн кешеләренең уй-тойгыларын, бүгенге тормышыбызның сулышын сурәтләүдә очерк жанрының әһәмиятен дә нигезле итеп укучыларга җиткерә.

Бу китапның бүгенге язучыларыбызның әсәрләрен пропагандалауда, идея-художество чараларын, аларга хас үзенчәлекләрне анализлап укучыларга җиткерүдә, укучыларның әдәби-эстетик зәвыкларын тәрбияләүдә роле зур. Күләме 196 бит, бәясе 50 тиен. 3 мең данә тираж белән басылган.

# ӘДӘБИЯТ һәм СӘНГАТЬ яңалыклары

### ЛЕНИН ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин премияләре комитеты 1965 елда сәнгать һәм журналистика өлкәсендә күренекле казанышлары өчен режиссер Ю. А. Завадскийга һәм Моссовет исемендәге академия театрында «Маскарад» спектаклендәге Арбенин ролен башкаручы Н. Д. Мордвиновка; концерт-башкару эшчәнлеге өчен — (1962—1964 еллар программалары) Л. Б. Коганга; режиссер Г. М. Козинцевка һәм «Гамлет» нәфис фильмындагы Гамлет ролен башкаручы И. М. Смоктуновскийга; «Правда» газетасында һәм «Крокодил» журналында басылган политик карикатуралар сериясе өчен — М. В. Куприяновка, П. Н. Крыловка һәм Н. А. Соколовка (Кукрыниксілар); «Брест крепосте» китабы өчен С. С. Смирновка Ленин премиясе бирү турында карар кабул итте.

### ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ

Республикабыз хезмәт ияләре фашистлар Германиясен җиңүгә 20 ел тулу көнен тантаналы төстә бәйрәм иттеләр.

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында 8 май көнне тантаналы җыелыш үткәрелде. Җыелышлар шулай ук шәһәрнең Киров һәм Ленин районнарында да үткәрелде. Барлык предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм уку йортларында хезмәт ияләре геройлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, партизаннар хәрәкәтенә катнашучылар белән очраштылар.

9 майда иртәнге сәгать уннан Ирек мәйданында хәрбиләштерелгән спорт эстафетасы башланып китте. Эстафетада җиңүчеләргә Советлар Союзы Герое, безнең якташыбыз, сынаучы-очучы Г. Қ. Мосолов исемендәге приз тапшырылды.

Шул ук көнне В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Үзәк стадионда үткәрелгән бәйрәм дә кызыклы булды. Программага тантаналы сугышчылар маршы, «Бу көннәрнең даны югалмас» дигән театраль күренеш, бәйрәм концерты, танцалар, уеннар, фейерверк ату кертелгән иде. Монда ДОСААФ техникасы һәм хәрби техника күргәзмәләре эшләде. Татарстан дәүләт музее фондыннан экспозицияләр күрсәтелде.

М. Горький исемендәге Культура һәм ял паркында, шәһәрнең башка паркларында массовой ял итүләр, геройлар белән очрашулар, концертлар «Җиңү бәйрәме» девизы астында үтте.

Казан мәйданнарында 9 майда җиңүнең 20 еллыгына багышланган кинофильмнар күрсәтелде. «Дружба», «Родина», «Татарстан», «Вузовец», «Мир» кино-театрларында хәрби фильмнар фестивален тамашачылар гаять җылы каршыладылар. Алар «Курск дугасында», «Нормандия-Неман», «Қорбаннар гаепли», «Хәбәрсез югалган», «Рядовой Александр Матросов», «Солдат турында баллада», «Бер кем дә һәм бер нәрсә дә онытылмады», «Қаберләр хәтерли» һәм башка кинофильмнар карадылар.

Татарстан дәүләт музеенда «Совет халкының Бөек Ватан сугышы» дигән күргәзмә тамашачылар өчен һәрвакыт ачык торды. Татарстан сынлы сәнгате музеенда фронтовик художниклар әсәрләреннән күргәзмә оештырылган иде.

Күргәзмәдә 180 нән артык каралама, эскиз һәм рәсемнәр тупланган. Аларны сугыш елларында фронтта булган художниклар Х. Якупов, М. Усманов, Х. Қазаков, А. Хуторов, Л. Фәттахов, М. Семенов, В. Куделькин, Б. Әльменов, С. Лывин, Ж. Булат, А. Родионов, М. Зуев, тылда яшәгән художниклар Қ. Максимов, Б. Урманчы, Г. Рахманкулова һәм башкалар иҗат иткәннәр.

Күргәзмәгә куелган әсәрләр дәһшәтле сугыш еллары турында — фашистлар тарафыннан җимерелгән шәһәрләр, яндырылган авыллар, гитлерчыларның ерткычлыгы һәм совет солдатларының, офицерларының батырлыклары турында сөйлиләр.

Күргәзмә ачылгач, аны караучылар Бөек Ватан сугышында катнашкан художниклар белән очраштылар. Сәнгать осталары аларга сугыш шартларында ничек иҗат итүләре турында сөйләделәр.

### ФРОНТОВИК ЯЗУЧЫЛАР ИСТӘЛЕГЕНӘ

Қазанда, Матбугат йортында, Ватан сугышында һәлак булган язучыларга һәм журналистларга мемориаль такта ачуга багышланган митингны Татарстан АССР Журналистлар союзы правлениесе председателе Ш. Хамматов ачты. Аннары ялкынлы сүз белән дә, корал белән дә олы җиңүгә зур өлеш кертеп, сугыш кырында ятып калган каһарман язучылар һәм журналистларның хезмәттәшләре, каләмдәшләре һәм көрәштәшләре чыгып сөйләделәр.

СССР Верховный Советы депутаты, Татарстан Язучылар союзы правлениесе председателе урынбасары, фронтовик язучы Габдрахман Әпсәләмов тыңлаучыларга үзенең ялкынлы сүзе белән мөрәҗәгать итте. Ул чыгышында болай диде:

— Бүген без Бөек Ватан сугышында һәлак булган якын дусларыбызның, каләмдәшләребезнең үлмәс батырлыгына баш иярга, аларга тагын бер тапкыр чиксез рәхмәтебезне белдерергә җыелдык. Ил аларны

онытмый һәм бер кайчан да онытачак түгел. Мәңгелек дан корбан булган батырларга!

Ләкин алар инде безнең бу сүзләрне ишетмиләр. Алар инде үзләренә бер нәрсә дә дауламыйлар, чөнки алар дан өчен корбан булмадылар. Үлгәннәрнең данын исәннәр яшәтә. Исәннәр аларның истәлеге каршында түләп бетергесез бурычлы.

Алар безнең кебек тормышны яраталар иде, алар безнең кебек үк яшәргә телиләр иде, аларның да, безнеке кебек, җаннан артык ата-аналары, хатыннары, бала-чагалары, сөйгән ярлары бар иде. Алар иң зур, иң якты, иң бәхетле иҗат хыяллары белән яналар иде. Менә шушы баскычлардан алар күңел җимешләре — язган шигырьләре, хикәяләре белән, беренче тапкыр, курка-курка, өскә, редакцияләргә күтәрелделәр. Аннары, беренче китапларын сөенеч белән тулы күкрәкләренә кысып, йөгерә-йөгерә киң тормыш дәръясына ташландылар. Сугышка китәр алдыннан саубуллашырга кергәндә дә алар шушы баскычлардан менделәр, ә киткәндә монда якын дусларын гына түгел, ә өметләрен, язылмаган китапларын һәм хыялларын да калдырып киттеләр. Фронтларда ут-төтен эчендә йөргәндә дә алар күңелләре белән менә шушы якты бинаны — Матбугат йортын күрделәр һәм окопларда, блиндажларда язган әсәрләрен монда юлладылар. Җырлары кайтты, ә үзләре... кайта алмады.

Менә ике якта ике мәрмәр такта. Берсендә фронтта һәлак булган журналистларыбызның, икенчесендә язучыларыбызның исемнәре, мәрмәргә уеп, алтын белән язылган. Тормышта журналистлар белән язучылар һәрвакыт бергә булган шикелле, истәлек тактасында да алар янәшә торалар.

Һәлак булган язучыларыбызның һәр берсе турында бүген аерым-аерым сөйләп тормыйм, аларның барысы да безнең һәр беребезгә билгеле, аларның бераүләре, зур һәм катлаулы тормыш һәм иҗат юлы үтеп, әдәбиятыбызның алтын фондына шигъри җәүһәрләр калдырган булса, икенчеләре, әле яңа яфрак яра башлаган яшь агачлар шикелле, беренче җырларын гына әйтергә өлгергән яшь талантлар иде. Ләкин кеше гомере — өлкәннәренең дә, яшьләренең дә — бер генә. Менә шушы бердән-бер газиз гомерләрен алар, ил солдатлары буларак, кызганмыйча Ватан-анага бирделәр. Аларның һәр берсе герой шагыйрь Муса Җәлил белән бергә:

**Бар җырымны илгә багышладым,**
**Гомеремне дә бирәм халкыма, —**

дип әйтергә хаклы. Шуңа күрә, корбан булган язучыларны барысын бергә күз алдына китергәндә, аларны Муса йолдызлары төркеме дип атыйсы килә. Бу якты йолдызлык безнең Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятыбызда тирән эз калдырды, әдәбиятыбыз тарихында аның хөрмәткә лаеклы үз урыны бар. Әле бүген дә, егерме елдан соң да, аларның җырлары көрәшчеләр сафында кешелеккә иң зур бәхетне — Тынычлыкны яулашуда катнашалар. Үлемсез җырлар алар.

Безнең әдәбиятыбызның Бөек Ватан сугышы чоры, кызганычка каршы, ныклап өйрәнелмәгән әле. Киләчәктә бу эш, һичшиксез, эшләнер, бүген әле онытылыбрак торган язучыларның да әсәрләре киң мәйдан алырлар.

Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан совет язучылары, өлкәннәреннән һәм авыруларыннан кала, барсы да диярлек фронтта иде. Алар кулларына корал тотып та, каләм тотып та дошманга каршы сугыштылар, каннарын койдылар. Утыз язучыбыз әйләнеп кайта алмады. Бүген аларның исемнәре, мәңгегә сакланыр өчен, мәрмәргә уелган...»

Аннары митингта күренекле галим, филология фәннәре докторы М. Гайнуллин, шагыйрь З. Нури, шагыйрь Хәсән Туфан, өлкән журналист, фронтовик Б. Корбанов, К. Иванов иптәшләр, чыгыш ясап, каләмдәшләренең ил алдындагы батыр эшләре турында горурланып сөйләделәр, алардан алган эстафетаны горур йөртергә чакырдылар.

Митингта катнашучылар мәрхүм Гадел Кутуйның тормыш иптәше Г. Кутуеваның дулкынланулы чыгышын игътибар белән тыңладылар. Ул, Ватан хакына һәлак булганнарның якты истәлеген изге итеп саклаулары өчен, Коммунистлар партиясенә һәм совет халкына зур рәхмәт белдерде. Чыгышын ул шундый сүзләр белән тәгәлләде: «Мин, иң тыныч профессия вәкиле — врач буларак, тагын шуны әйтергә телим: җир йөзендә сугышлар беркайчан да булмасын, тол, ятимнәр калмасын өчен көчләребезне аямыйк. Җирдә тыныч, ямьле тормыш өчен көрәшик».

...Хәзер Матбугат йортының икенче катында һәркемнең күзенә күренерлек урында мемориаль такта тора. Мәрмәр ташка сугышта һәлак булган язучыларның һәм журналистларның исемнәре уеп язылган. Язучылар: Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян, Рахман Ильяс, Мөхәммәт Әблиев, Демьян Фәтхи, Мөҗәй Хәйретдинов, Ал. Бендецкий, Мифтах Вәдут, Айтзак Аитов, Хабра Рахман, Кәшфи Басыйров, Мөсәгыйт Мостафин, Шамил Гәрәй, Мансур Гаяз, Әгъзам Камал, Әхмәт Гыймадов, Исхак Закиров, Исмәгыйл Шәфиев, Хәмит Кави, Касыйм Вахит, Макс Гатау, Мөхәмммәтша Мамин, Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Габдулла Галиев, Сөләйман Мөлеков, Лотфи Вәли, Әхтәм Әминов; журналистлар: У. Г. Әхметов, Рим Баһау, И. М. Белков, Ким Биков, Гали Галиев, А. Зөбәеров, Гаяз Кәтиев, Д. С. Лагутин, В. Н. Никольский, Рәхим Саттар, Г. К. Сәитов, Т. Сәләхетдинов, Ф. И. Суходеев, А. Я. Тупоногов, Г. Хәбибуллин, К. В. Хәснимәрдәнов, Ш. Абдуллин, Г. Мөбәрәкшин, А. К. Михайлов.

## М. ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕ КОМИССИЯСЕ

1966 елның февралендә Советлар Союзы Герое шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулу бөтен илебездә киң күләмдә билгеләп үтеләчәк. СССР Язучылар союзы каршында Константин Симонов председательлегендә юбилей комиссиясе оештырылды. Аның составына М. М. Әмиров, А. А. Ахматова, Р. Н. Бабаджан, Р. Г. Бикмөхәметов, С. А. Васильев, Г. И. Владыкин, П. Н. Воронько, Р. Г. Гамзатов, А. С. Жә-

мил, Ю. В. Друнина, Нәҗип Җиһанов, М. С. Кәримов, М. С. Кашафетдинов, Б. М. Кербабаев, Алим Кешоков, А. М. Крючкин, Д. Н. Кугультинов, К. Кулиев, М. Д. Львов, Д. Е. Ляшкевич, Э. Б. Межелайтис, Ж. Мулдагалиев, С. С. Орлов, П. Е. Панченко, К. И. Поздняев, Р. И. Рождественский, А. Н. Салахян, И. Л. Сельвинский, С. В. Смирнов, Ю. И. Суровцев, Ф. А. Табеев, А. А. Тарковский, Ф. Н. Таурин, М. Т. Турсун-задә, Сибгат Хәким, П. П. Хузангай, Һ. Г. Хөсәенова, С. Э. Эралиев керде.

Комиссия юбилейны үткәрү планын төзеде.

Юбилей алдыннан бер группа язучылар шагыйрьнең туган ягына, Оренбург өлкәсенең Мостафа авылына һәм Җәлил шәһәренә барачаклар. Фәнни конференциягә әзерлек алып барыла. Конференциядә Казан һәм Мәскәү университетлары, А. М. Горький исемендәге Бөтендөнья әдәбияты институты, СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты, СССР, РСФСР һәм Татарстан Язучылар союзлары катнашачак. М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры М. Җәлил либреттосы буенча эшләнгән «Алтынчәч» операсын һәм «Җәлил» операсын Кремль театрында күрсәтәчәк.

М. Җәлил туган көндә Чайковский исемендәге залда герой шагыйрь истәлегенә багышланган тантаналы кичә үткәреләчәк. Аннары шундый ук кичәләр Ленинградта, Оренбургта, союздаш һәм автономияле республикаларның башкалаларында үткәреләчәк. Юбилей тантаналары Татарстан башкаласында тәмамланачак.

Мәскәүдә һәм Казанда М. Җәлилнең иҗатына һәм батырлыгына багышланган күргәзмәләр оештырыла.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Казан дәүләт педагогия институты студентлары бер төркем язучыларны бөек шагыйрь Габдулла Тукай истәлегенә багышланган әдәби-музыкаль кичәгә чакырдылар. Кичәне институтның ректоры иптәш Туишев ачты. Күренекле шагыйрь, Сибгат Хәким бөек шагыйрьгә багышланган ялкынлы чыгышы белән кичәне башлап җибәрде. Аннары шагыйрьләрдән З. Нури, Ә. Давыдов, Г. Латыйп, Н. Гайсин, Ә. Бикчәнтәева, Ш. Галиев, И. Юзиев, Ә. Баянов, Р. Әхмәтҗанов, М. Фәйзуллина һ. б. үзләренең шигырьләрен укыдылар. Өлкән музыкант И. Һилалов Тукай турында истәлек сөйләде. Кичәгә шулай ук күренекле язучы Габдрахман Әпсәләмов та килгән иде.

Соңыннан Татарстанның атказанган артисты Илһам Шакиров, Татар дәүләт опера һәм балет театры солисткасы Хәдичә Гыйниятова һәм башка артистлар катнашында концерт күрсәтелде.

## ШАГЫЙРЬ БӘЙРӘМЕ

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының актлар залында 13 май көнне шагыйрь Әхмәт Исхакка 60 яшь тулуга багышланган кичә үткәрелде. Кичәне шагыйрьнең әдәбиятта тоткан урынына карата кереш сүз белән язучы Габдрахман Әпсәләмов ачты. Ә. Исхакның күпьеллык иҗат эшчәнлеге турындагы докладны шагыйрь Сибгат Хәким ясады.

Аннары күп иҗади оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр, партия һәм совет органнары исеменнән юбилярны котлаулар булды. Аерым алганда, Татарстан Язучылары союзы һәм «Казан утлары» журналы редакциясе исеменнән шагыйрь Зәки Нури, КПССның Бауман райкомы исеменнән райкомның беренче секретаре Хәбибуллина, Татарстан Культура министрлыгы исеменнән И. Илялова, Казан тел, әдәбият һәм тарих институтыннан — филология фәннәре докторы М. Гайнуллин, Татарстан китап нәшрияты һәм ТАССР Министрлар советы каршындагы матбугат идарәсе исеменнән нәшрият директоры Г. Камалиев, «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталарының берләштерелгән редакциясеннән — редактор урынбасары Р. Тимергалин, Казан дәүләт университеты исеменнән филология фәннәре докторы Х. Госман, Татарстан Композиторлар союзыннан — Җәүдәт Фәйзи һәм башка иптәшләр чыгыш ясадылар, адреслар бирделәр. Юбилярга шулай ук күп кенә бәяле бүләкләр дә тапшырылды.

Шагыйрьне 60 яше белән котлап, РСФСР Язучылар союзы правлениесеннән, Башкортстан, Мордовия, Мари, Чувашия, Якутия, Удмуртия автономияле республикалары язучылары союзларыннан, Үзбәкстан, Төркмәнстан, Азербайҗан язучыларыннан, «Литературная газета»дан, «Крокодил» журнал редакциясеннән һәм башка оешмалардан, аерым кешеләрдән күп санлы телеграммалар килгән иде.

Фойэда Ә. Исхак әсәрләре күргәзмәсе һәм китап сәүдәсе оештырылган иде.

Бәйрәм шагыйрь иҗатына багышланган концерт белән тәмамланды.

## ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР СЕКЦИЯСЕ УТЫРЫШЫ

10 май көнне тәнкыйтьчеләр секциясендә филология фәннәре кандидаты И. Нуруллинның «Тукай иҗатын өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре» дигән доклады укып тикшерелде. Утырышта язучы Ф. Хөсни, әдәбият белгечләре А. Сайганов, Ж. Вәзиева, Б. Гыйззәт, Н. Юзиев, журналист М. Бәдәйли һәм башка иптәшләр И. Нуруллин докладында кирәкле, кызыклы фактлар җыелганлыгын, Тукай иҗатын фәнни өйрәнүдәге күп кенә кимчелекләрнең дөрес билгеләнгәнен күрсәтеп үттеләр. Шагыйрьне тар рамкаларга кертергә, матурларга тырышу, аны иҗтимагый күренеш буларак күрсәтә алмау — әдәбият фәнебезнең җитди кимчелеге. Докладта бу фикер ышандырырлык дәлилләнгән. Шул ук вакытта анда кайбер бәхәсле һәм өстәнрәк яктыртылган урыннар да бар. Тикшерүдә катнашучы иптәшләр бу кимчелектән арыну өчен авторга киңәшләр бирделәр, классик язучылар иҗадын өйрәнү һәм нәшриятта бастырып чыгару буенча кайбер тәкъдимнәр әйттеләр.

## Алдагы саннарда:

Ш. Маннур. **Муса.** Роман. Дәвамы.

Ф. Хөсни. **Ике агроном, бер овчарка.** Хикәя.

С. Баттал, З. Мансур, Г. Хуҗи шигырьләре, яңа тәрҗемәләр.

Г. Кашшаф. **Партия җитәкчесе.** Очерк.

Ж. Мостафин. **Казан батыры.** Очучы-сынаучы якташыбыз Советлар Союзы Герое Г. К. Мосолов турында очерк.

М. Мостафин. **Барыр юлыбыз.** КПСС Үзәк Комитетының март Пленумы карарлары ачкан киң мөмкинлекләр турында публицистик мәкалә.

Р. Мостафин. **Алга барышлый.** Хәсән Туфанның иҗат портреты.

М. Госманов. **Яңа табылган ярлык.**

Яңа китапларга рецензияләр.

Укучылар сүзе.

Җырлар.

Җаваплы редактор өчен **Әхсән Баянов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 10/V-1965 ел. Басарга кул куелды 18/VI-1965 ел. ПФ 08121. Кәгазь форматы $70\times108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 13,49. Басма табак 10(14). Тираж 20 300 экз. Заказ Л-671.
Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1965 ел.

# *ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!*

**„КАЗАН УТЛАРЫ“ журналына елның теләсә кайсы аенда язылырга мөмкин.**

**Ул — Бөтенсоюз каталогына кертелгән журнал. Аңа Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә, „Союзпечатьның барлык бүлекләрендә чикләүсез язылырга мөмкин.**

Журналга түбәндәге адрес белән дә язылып була:

*Казань, ул. Куйбышева, 17/25, областной отдел „Союзпечати“.*

Урыннарда нинди дә булса сылтау белән журналга язмасалар, турыдан-туры редакциягә хәбәр итүегезне үтенәбез.

Безнең адрес:

*Казань, Баумана, 19, Дом печати, редакция журнала „Казан утлары“.*

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп

Индекс
73367

*Ежемесячный литературно-художественный*
*и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Советская литература)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ